# 2022 елга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының эшчәнлек нәтиҗәләре турында ХИСАП

Казан 2023

**ЭЧТӘЛЕК**

СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ ТОТРЫКЛЫЛЫКНЫ ТӘЭМИН ИТҮГӘ ЮНӘЛТЕЛГӘН ЧАРАЛАРНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ………………………………… 3
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ИЛКҮЛӘМ ПРОЕКТЛАРНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ........................................................................................................ 5
БЮДЖЕТ СӘЯСӘТЕ.......................................................................................... 8
ТӨП СОЦИАЛЬ КҮРСӘТКЕЧЛӘР.................................................................. 13
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН......................................................................................... 15
СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ.................................................................................. 26
ХЕЗМӘТ, МӘШГУЛЬЛЕК ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ.................................... 32
ФИЗИК КУЛЬТУРА ҺӘМ СПОРТ.................................................................... 39
ЯШЬЛӘР СӘЯСӘТЕ........................................................................................... 43
МӘДӘНИЯТ........................................................................................................ 50
КОММЕРЦИЯЧЕЛ БУЛМАГАН ОЕШМАЛАРГА ЯРДӘМ ИТҮ ИНФРАСТРУКТУРАСЫН ҮСТЕРҮ........................................................................ 59
МӘДӘНИЯТ, СОЦИАЛЬ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ, СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ ҺӘМ МӘГАРИФ ӨЛКӘСЕНДӘ ОЕШМАЛАР ТАРАФЫННАН КҮРСӘТЕЛГӘН ХЕЗМӘТЛӘРНЕҢ СЫЙФАТЫНА БӘЙСЕЗ БӘЯ БИРҮ........................................... 63
ТУРИСТЛЫК........................................................................................................ 65
ЭКОЛОГИЯ.......................................................................................................... 68
ТӨП ИКЪТИСАДЫЙ КҮРСӘТКЕЧЛӘР........................................................... 78
СӘНӘГАТЬ.......................................................................................................... 84
- Нефть-газ-химия комплексы.......................................................................... 84
- Энергетика комплексы.................................................................................... 87
- Газлаштыру һәм газ белән тәэмин итү............................................................ 89
- Машина төзелеше комплексы.......................................................................... 89
- Оборона-сәнәгать комплексы.......................................................................... 92
- Урман эшкәртү сәнәгате.................................................................................. 92
- Җиңел сәнәгать................................................................................................ 93
- Эчемлекләр җитештерү.................................................................................... 95
- «Хезмәт җитештерүчәнлеге» илкүләм проекты............................................... 95
- «Халыкара кооперация һәм экспорт» илкүләм проекты.................................. 96

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ............................................................................................. 98
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ.............................................................. 104
ТӨЗЕЛЕШ ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫК................................... 109
ИНВЕСТИЦИЯ ЭШЧӘНЛЕГЕ........................................................................... 115
КЕЧЕ ҺӘМ УРТА ЭШКУАРЛЫК..................................................................... 125
ЦИФРЛЫ ТРАНСФОРМАЦИЯЛӘҮ................................................................. 134
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КОМИТЕТЛАРЫННАН ҺӘМ ДЕПУТАТ БЕРЛӘШМӘЛӘРЕННӘН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАШКАРМА ХАКИМИЯТЕ ОРГАННАРЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТУРЫНДА СОРАУЛАР ИСЕМЛЕГЕ БУЕНЧА МӘГЪЛҮМАТ.......................................... 140

## СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ ТОТРЫКЛЫЛЫКНЫ ТӘЭМИН ИТҮГӘ ЮНӘЛТЕЛГӘН ЧАРАЛАРНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ

География белән бәйле сәясәт факторларына кагылышлы рәвештә яшәештәге билгесезлекнең югары дәрәҗәгә җитүе шартларында 2022 ел ил өчен җитди сынау чоры булды. Тиңдәшсез чикләүләр кертелү Татарстан Республикасы икътисады үсешенә сизелерлек йогынты ясады:

тышкы сәүдә эшчәнлегендәге чикләүләр һәм транспорт йөрешенә киртә куелу экспорт-импорт операцияләрендә чагылыш таба; технологик чикләүләр инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга йогынты ясый;

товарларны сатуга тәкъдим итү белән аларга ихтыяҗ арасындагы тигезлекнең юкка чыгуы шартларында инфляция басымы, нефтькә бәяләрнең һәм рубль курсының үзгәреп торуы эш алып бару активлыгына йогынты ясый;

Россия компанияләренең һәм банкларының гомум финанс системасы белән бәйләнешенә киртәләр корылу чит ил контрагентлары белән түләүләр уздырганда байтак кыенлыкларга һәм чыгымнарга китерә;

төрле гуманитар тыюлар кешеләрнең төрле илләргә чыгуында, мәгариф, мәдәният һәм спорт өлкәләрендә чаралар уздыруда кыенлыклар китереп чыгара.

Чикләүләр кертү аша басым ясалу шартларында республиканың предприятиеләре һәм оешмалары кооперация өлкәсендә яңа элемтәләр урнаштыру, логистика багланышларын үзгәртеп кору, товар сату өчен яңа базарлар эзләү, чит ил товарларын алмаштыру эшен тиз арада оештыра алдылар. Татарстан Республикасы икътисадын тотрыклы үстерү максатларында түбәндәгеләр булдырылды:

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов рәислегендә Татарстан Республикасының социаль-икътисадый тотрыклылыгын тәэмин итү буенча оператив штаб (Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 29 мартындагы 125 номерлы боерыгы);

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры җитәкчелегендә Татарстан Республикасы икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итү буенча эш төркеме (алга таба – эш төркеме) (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2022 елның 18 мартындагы 96 номерлы боерыгы), төркемгә республиканың министрлыклары, ведомстволары, федераль хакимият органнарының территориаль органнары, муниципаль берәмлекләр, иҗтимагый оешмалар вәкилләре кертелде;

тармак һәм муниципаль штаблар.

Татарстан Республикасы икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итү буенча төп чаралар планы кабул ителде һәм гамәлгә ашырыла (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге 387-р номерлы карары). Планның үтәлеше барышына кагылышлы мәсьәләләр Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы киңәшмәләрдә даими рәвештә карап тикшерелә.

Эш төркеме яңа коронавирус йогышлы чире таралу белән бәйле рәвештә вазгыять начараю, нефть бәяләре һәм доллар курсы үзгәреп тору шартларында 2020 елда төзелгән эш төркеме кысаларында эшләнгән механизмнарга таянып эш итә. 2022 елда эш төркеме Татарстан Республикасы икътисадының тотрыклы

үсешен тәэмин итү чараларының үтәлүенә оператив мониторинг ясап торды һәм аларны контрольдә тотты, түбәндәге төп юнәлешләр буенча тиешле йогынты чаралары күрелде:

халыкны социаль әһәмияткә ия булган төп товарлар белән, кулланылышның запастагы товарлар күләменнән артык яисә ким булу дәрәҗәсен исәпкә алып, аларны сатып алып кайтарту өлешендә тәэмин итү;

халыкның эш белән тәэмин ителешен саклап калу, шул исәптән предприятиеләр һәм оешмаларның тиешле ярдәм чараларын күрсәтүдә катнашуы;

система тәшкил итә торган оешмаларның өзлексез эшләве, килеп туган кыенлыкларны хәл итү буенча тәгаен чаралар күрү, шул исәптән Республика маркетинг үзәге (чит ил товарларына алмашка товарлар җитештерү), Горький һәм Куйбышев тимер юллары (логистика мәсьәләләре), Татарстан таможнясы (чит илләрдә җитештерелгән комплектлау эшләнмәләрен сатып алып кайту) катнашында;

Татарстан Республикасы территориясендә федераль һәм республика күләмендәге ярдәм чаралары комплексын, федераль дәрәҗәдә ташламалы кредит бирү, республика күләмендә ташламалы микрозаймнар, поручительлек һәм турыдан-туры булмаган финанс ярдәме чараларын, шулай ук индустриаль сәнәгать паркларын үстерүне дә кертеп, гамәлгә ашыру хисабына кече һәм урта эшкуарлык субъектларын яңа шартларга җайлаштыру;

инвестицияләр кертү активлыгы артуына ярдәм итү.

Эш төркеме утырышлары кысаларында шулай ук өлешчә мобилиция белән бәйле рәвештә каралган ярдәм чараларын үтәүне мониторинглау уздырылды. Ул барлык потенциаль акча алучыларның ярдәм чараларыннан файдалана алуы мөмкинлеген тәэмин итүгә юнәлтелгән.

Эш төркеменең 59 утырышы узды.

Татарстан Республикасы икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итүгә юнәлтелгән эш 2023 елда да дәвам иттереләчәк. Татарстан Республикасының 2023 елда социаль-икътисадый тотрыклылыгын тәэмин итү һәм икътисадын үстерү буенча чаралар планы (юл картасы) эшләнде. Аның төп юнәлешләре түбәндәгеләр:

барлык тармак предприятиеләренең өзлексез һәм нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү, шул исәптән предприятиеләрнең чимал, материаллар һәм компонентлар белән тәэмин ителеше, җиһазларның куркынычсызлыгын саклау һәм тотрыклы эшен тәэмин итү; нәтиҗәле логистика төзү; гамәлдәге товар сату базарларын үстерү һәм яңаларын булдыру; хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү;

инвестиция активлыгына этәргеч бирү;

кече һәм урта эшкуарлык үсеше тизлеген тиешле дәрәҗәдә саклау;

муниципаль берәмлекләрне бертигез үстерү;

илкүләм проектларны һәм дәүләт программаларын нәтиҗәле гамәлгә ашыруны дәвам иттерү.

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ИЛКҮЛӘМ ПРОЕКТЛАРНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ

**Илкүләм проектлар**

Татарстан 2019 елдан Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы һәм «2030 елга кадәр Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы указларын үтәүгә юнәлтелгән илкүләм проектларны гамәлгә ашыруда катнаша.

Илкүләм проектлар чараларын үтәү социаль әһәмияткә ия булган объектлар төзү, учреждениеләр һәм оешмаларның матди-техник базасын яхшырту, шулай ук дәүләт тарафыннан халыкка һәм бизнеска төрле ярдәм күрсәтелү нәтиҗәсендә татарстанлыларның тормыш сыйфатын яхшыртырга мөмкинлек бирде. 2022 елда республикада 49 төбәк проектының 13 илкүләм проекты максатларына ирешүгә юнәлтелгән чаралары гамәлгә ашырылды, аларны финанслау күләме 43 728,5 млн сум тәшкил итте, шул исәптән федераль бюджеттан – 32 477,1 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 11 251,4 млн сум. Акчаны касса аша уздыру күләме 99,8 % тәшкил итте (Идел буе федераль округы субъектлары арасында 1 нче урын).

Илкүләм проектларны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә 2022 елда республиканың барлык муниципаль берәмлекләрендә социаль әһәмияткә ия булган объектлар төзелде, шул исәптән:

Чаллы шәһәренең 69 микрорайонында 1 501 урынлык мәктәп төзелде;

Апас һәм Баулы муниципаль районнарындагы гомуми белем бирү учреждениеләрендә 2 спорт залы капиталь төзекләндерелде;

Казан шәһәрендә балалар бакчасы һәм Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авылында гомуми белем бирү мәктәбе төзелә башлады;

34 парк һәм сквер төзекләндерелде;

сәламәтлек саклау өлкәсенең башлангыч звеносы объектларының 34 е яңа төзелде, ә 15 е капиталь төзекләндерелде, шул исәптән фельдшер-акушерлык пунктлары, табиблык амбулаторияләре һәм поликлиникалар;

Алексеевск муниципаль районында ясалма бозлы, түбәле шугалак төзү тәмамланды;

Казан шәһәрендә канализациянең биологик чистарту корылмаларын яңартып кору һәм биологик чистарту корылмаларының ләмле кырларын файдаланырга яраклы хәлгә китерү эшләре дәвам иттерелде, Түбән Кама сусаклагычы акваториясендәге Озерный чыганагының эшләми торган торбаүткәргечләрен сүтү эшләре башланды;

Мишә (Лаеш муниципаль районы) һәм Нократ (Мамадыш шәһәре) елгаларының уң кушылдыкларын, шулай ук Державино авылы күлен (Лаеш муниципаль районы) чистарту төгәлләнде, Берсут елгасы кушылдыгын чистарту башланды;

мәдәният өлкәсендә 3 яңа авыл мәдәният йорты төзелде һәм 2 се капиталь төзекләндерелде, Буа шәһәрендә район мәдәният йортын яңартып кору башланды, Чүпрәле районының Иске Задор авылында күпфункцияле үзәк, Мамадыш

районының Катмыш авылында мәдәният-ял итү үзәге төзелде, Алабуга һәм Яшел Үзән шәһәрләрендә мәдәни үсеш үзәкләрен төзү төгәлләнде, Түбән Кама шәһәрендә Яшь тамашачы театры һәм Арча шәһәрендә сәнгать мәктәбе яңартып корылды, шулай ук Лаеш шәһәрендә музейга капиталь төзекләндерү уздырылды;

Тәтеш муниципаль районында «Түбәтәй Тауэр» туристлык объекты территориясе төзекләндерелде һәм инфраструктурасы булдырылды;

Казан шәһәрендә Несмелов урамыннан М-7 трассасына кадәр федераль әһәмияттәге автомобиль юлын, Зур Казан боҗрасын үстерү кысаларында Техническая урамын, Вознесенская трактын төзү дәвам иттерелде.

2022 елдан республикада (илдәге бердәнбер төбәктә) «Фән һәм университетлар» илкүләм проектының «Фәнни тикшеренүләр һәм кадрлар әзерләү өчен инфраструктураны үстерү» төбәк проекты гамәлгә ашырыла, аның кысаларында «Иннополис» университетының торак комплексында студентлар һәм яшь галимнәр өчен 3 торак корпус төзелде.

Моннан тыш, мәгариф һәм медицина учреждениеләренең матди-техник базасын яхшырту өчен җиһазлар сатып алынды. Эшкуарларга ярдәм күрсәтелде, балалы гаиләләргә социаль түләүләр бирелде, гражданнарның төрле категорияләре яңа һөнәрләр үзләштерде.

«Кече һәм урта эшкуарлык һәм шәхси эшкуарлык башлангычларына ярдәм күрсәтү» илкүләм милли проекты кысаларында яшь эшкуарларга бизнес-проектлар гамәлгә ашыру өчен 100 меңнән 500 меңгә кадәр грантлар, ташламалы микрозаймнар һәм поручительлекләр бирелде. Акчалата булмаган ярдәм чаралары күрсәтелде, боларга шул исәптән җитештерелгән продукциягә сертификат, патент алу, аларны маркетплейсларда урнаштыру керә.

«Туристлык һәм кунакчыллык өлкәсе» илкүләм проектының «Туристлык өлкәсен үстерү» төбәк проекты кысаларында эшкуарларның кемпинглар булдыру һәм туристлык инфраструктурасын үстерү башлангычларына ярдәм күрсәтелде.

Тыюлар кертү басымы нәтиҗәсендә килеп чыккан чикләүләргә карамастан, 2022 елда республикада планлаштырылган чаралар гамәлгә ашырылды һәм 162 күрсәткечнең максатчан барлык күрсәткечләренә ирешелде, шул исәптән түбәндәгеләрнең үсеше тәэмин ителде:

1,5 яшьтән алып 3 яшькәчә балаларның мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеге дәрәҗәсе – 100 процентка кадәр;

5 яшьтән 18 яшькәчә балаларның якынча 85,35 проценты өстәмә белем ала;

гражданнарның спорт корылмалары белән тәэмин ителү дәрәҗәсе – 71,5 процентка кадәр;

республикада яшәүчеләр өчен уңайлыклы җәмәгать урыннары саны – 233 кә кадәр;

кешеләрне тузган торактан башка торакка күчерү күләме – 16,15 мең кв. метрга кадәр;

нормативларга яраклы хәлдә булган шәһәр агломерацияләре юл челтәре өлеше – 83,19 процентка кадәр;

республика халкының үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системасыннан сыйфатлы эчәр су белән тәэмин ителгән өлеше – 94,2 процентка кадәр.

Илкүләм проектлар гамәлгә ашырылган 4 ел эчендә икътисад тармакларына,


эшкуарларга һәм гражданнарга зур ярдәм күрсәтелде. Республика өчен инфраструктура төзелеше, халыкка социаль ярдәм күрсәтү һәм җитештерү өлкәсен үстерү белән бәйле проектлар элеккечә әһәмиятле булып кала. Моннан тыш, балалар тәрбиясенә, яшьләр сәясәтенә һәм цифрлаштыруга зур игътибар бирелә.

**БЮДЖЕТ СӘЯСӘТЕ**

*Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре өлешендә.*

2022 елда Татарстан Республикасы бюджетына салым һәм салым булмаган керемнәр 366,6 млрд сум күләмендә җыелды, план күрсәткечләренең 101,9 процентын тәшкил итте, бу исә 2021 ел күрсәткечләреннән 86,4 млрд сумга яисә 30,8 процентка артыграк.

**2022 елда Татарстан Республикасы бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәре структурасы**




Республика бюджетына керемнәрне арттыру өчен даими төстә Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының үз керемнәрен үстерүне тәэмин итү буенча ведомствоара комиссиясе эшли (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 30 апрелендәге 687-р номерлы карары кысаларында), аның эшчәнлеге кысаларында түбәндәгеләр башкарылды:

керемгә салым түләүгә ай саен мониторинг уздырылды, нәтиҗәдә алдагы елның шул ук чоры белән чагыштырганда түләүләре кимегән оешмалар ачыкланды. Мондый оешмаларның исемлеге квартал саен аналитик эш белән шөгыльләнүче тармак министрлыгына җиткерелеп торды, алар баланс комиссияләре эшчәнлеге кысаларында салымнар түләүнең кимүе сәбәпләрен һәм барлык дәрәҗәдәге бюджетларга түләүләр буенча бурычы булган оешмалар эшчәнлеген тикшерделәр. Уртак эш йомгаклары буенча тармак министрлыклары тарафыннан үз карамакларындагы оешмаларның житештерү рентабельлеген арттыру һәм керем алу дәрәҗәсенә чыгу, шулай ук бюджетка түләүләр буенча бурычны киметү буенча тәкъдимнәр эшләнде;

физик затларның керемнәренә салым салу өлешендә яшерен хезмәт хакын легальләштерү, конвертта акча түләүне һәм салым түләүдән читләшүнең башка схемаларын ачыклау эшчәнлеге алып барылды, учреждение хезмәткәрләренә

хезмәткә түләүнең федераль законнарда билгеләнгән иң түбән күләменнән азрак булмаган күләмдә хезмәт хакы түләү контрольдә тотылды, шулай ук әлеге салымны түләүне киметкән салым түләүчеләргә мониторинг уздырылды;

продукция җитештерү һәм сату күләмнәренә, акцизга караган продукцияне төп җитештерүчеләрнең акциз салымын түләүнең план биремнәренә ирешүенә мониторинг уздыру буенча акцизларга караган продукция җитештерүчеләр белән даими эш алып барылды;

салым түләүче физик затларның милеккә салым түләүләре үз вакытында һәм тулысынча башкарылуын тәэмин итү максатларында зур предприятиеләр, дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, муниципаль берәмлекләр белән салымнарны законнарда билгеләнгән срокларда түләү буенча хезмәттәшлек ителде. Шулай ук салым түләүчеләргә салым түләү турында хәбәрнамәләрне җиткерү, кредит оешмалары һәм почта бүлекчәләре тарафыннан түләүләрне өзлексез кабул итү эше оештырылды, шулай ук киң колачлы мәгълүмати эш, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында да, җәелдерелде;

салым булмаган керемнәр өлешендә Татарстан Республикасы бюджетына һәм муниципаль районнар һәм шәһәр округларының берләштерелгән бюджетларына керә торган керемнәрне анализлау һәм фаразлана торган керемнәрне бәяләү башкарылды, керем базасын арттыру һәм түләүләр буенча бурычларны киметү максатларында салым булмаган керемнәр администраторлары белән уртак эш алып барылды;

Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына салым бурычларын киметү буенча (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 15 июлендәге 1493-р номерлы карары белән төзелгән Ведомствоара комиссия (штаб) эше кысаларында). Ай саен муниципаль районнарга һәм шәһәр округларына Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белешмәләреннән чыгып, бурычлары булган салым түләүчеләр турында мәгълүмат юлланды. Муниципаль берәмлекләрнең ведомствоара комиссияләре эшенең йомгаклары Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе вәкилләре катнашында видеоконференция режимында уздырылган киңәшмәләрендә каралды. Бурычлары булган затлар белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары карамагындагы икътисадый эшчәнлек төрләре буенча эш уздырылды. Федераль һәм төбәк законнарына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына бурычны киметүгә юнәлтелгән шартлар булдыру өлешендә үзгәрешләр кертү зарурлыгы турында тәкъдимнәр бирелде.

Моннан тыш, бюджетка керемне арттыру максатларында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан республиканың зур күләмдә салым түләүчеләр белән эш уздырылды, шул исәптән түләүләрне анализлау һәм фаразлана торган түләүләрне бәяләү, түләүләр кимүе сәбәпләрен ачыклау, шулай ук бюджетка түләүләрне арттыру өчен чаралар күрү.

Салым сәясәтен гамәлгә ашыру кысаларында керемгә салым һәм оешмалар милкенә салым буенча ташламалар рәвешендә яисә алгарышлы үсеш

территорияләре резидентлары составына кертелүгә дәгъва кылган инвестиция эшчәнлеге субъектларының инвестиция проектларына экспертиза ясалды.

Инвестиция эшчәнлеге субъектларының республиканың берләштерелгән бюджетына инвестиция проектларын гамәлгә ашыру турында тиешле килешүләр гамәлдә булган чор эчендә салымнар һәм җыемнар түләүне ел саен тәэмин итү буенча йөкләмәләрен үтәүләренә мониторинг уздырылды һәм бәя бирелде.

Кабул ителә торган үзгәрешләрнең Татарстан Республикасы икътисадына һәм берләштерелгән бюджетына мөмкин булган йогынтыларга кагылышлы тиз арада идарәчел карарлар кабул итү максатында федераль закон проектлары даими нигездә анализланды. 2022 елда салымнар һәм җыемнар турындагы законнарга үзгәрешләр кертү буенча закон инициативаларына 50дән артык бәяләмә әзерләнде. Алар арасында этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне җитештерү һәм аның әйләнеше өлкәсендә федераль законнарны камилләштерү буенча закон проектлары да бар.

2023 елда Татарстан Республикасы бюджетының керем өлешен формалаштыру һәм үтәү кысаларында аның тотрыклылыгын һәм балансланган булуын тәэмин итү максатларында системалы эш дәвам иттереләчәк.

*Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары өлешендә.*

2022 елда Татарстан Республикасында 34 дәүләт программасын гамәлгә ашыру тәэмин ителде, аларны үтәүгә 430,6 млрд сум тотылды, шулардан федераль бюджеттан – 73,1 млрд сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 357,5 млрд сум.

Тулаем алганда, Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары 463,2 млрд сум күләмендә башкарылган, шулардан иң зур күләмдәгеләре мәгарифкә – 93,0 млрд сум, социаль сәясәткә – 56,0 млрд сум, сәламәтлек саклауга – 43,1 млрд сум, юл хуҗалыгына – 82,9 млрд сум, авыл хуҗалыгына – 18,2 млрд сум, мәдәнияткә – 15,0 млрд сум.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы муниципаль берәмлекләр белән берлектә, бюджетны үтәүнең казначылык системасын файдаланып, хезмәт хакын, социаль түләүләрне вакытында түләүне, бюджет учреждениеләре мәнфәгатьләрен канәгатьләндерүне һәм инвестиция проектларына ярдәм күрсәтүне контрольдә тотты.

Эчке дәүләт финанс контроле буенча кысаларында 255 контроль чара уздырды, аларның йомгаклары буенча бюджет акчасының 170,9 млн сумга нәтиҗәсез файдаланылуы ачыкланды. Ачыкланган хокук бозуларны бетерү чараларын күрү өчен учреждениеләр җитәкчеләренә кисәтүләр юлланды. Тикшерүләр актлары Татарстан Республикасы Прокуратурасына юлланды.

Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы, «2012–2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә кылынган гамәлләрнең илкүләм стратегиясе турында» 2012 елның 1 июнендәге 761 номерлы, «Балаларны, ятимнәрне һәм ата-аналар тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруның кайбер чаралары турында» 2012 елның 28 декабрендәге 1688 номерлы указларын гамәлгә ашыру эше дәвам иттерелде.

2022 ел йомгаклары буенча Россия Федерациясе Президентының 2019 елның 27 февралендәге Пр-294 номерлы йөкләмәсендә билгеләнгән аерым категория хезмәткәрләргә түләү күрсәткечләре әлеге категория хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү дәрәҗәсе белән төбәктәге уртача алынган хезмәт хакы дәрәҗәсе арасындагы тигезлекне саклау тулы күләмендә үтәлде.

Әлеге категория хезмәткәрләргә эш хакы түләүгә 171,6 млрд сум тотылган (ихтыяҗның 100 %), шул исәптән федераль бюджеттан – 4,4 млрд сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 119,7 млрд сум, Мәҗбүри медицина иминләштерүе фонды акчалары хисабыннан – 36,1 млрд сум, бюджеттан тыш акчалар хисабыннан – 11,4 млрд сум.

Һәр квартал саен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салым һәм финанслар комитеты утырышларында Татарстан Республикасы бюджетына керемнәр туплау һәм бюджет акчаларын нәтиҗәле куллану мәсьәләләре каралды. 2022 елның июлендә, октябрендә һәм декабрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан 2022 елга Татарстан Республикасы бюджетына үзгәрешләр кертү буенча эш башкарылды.

2022 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт финансларын банкротлыктан саклау чаралары планы, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 25 мартындагы 664-р номерлы карары нигезендә 2020-2022 елларга керемнәрне арттыру, чыгымнарны бетерү һәм Татарстан Республикасының бурычлар белән бәйле сәясәтен камилләштерү буенча чаралар планын гамәлгә ашыру дәвам иттерелде.

*Татарстан Республикасының дәүләт бурычы белән идарә итү өлешендә.*

Ел дәвамында республика дәүләт бурычын йөкләмәләрне үтәү графиклары нигезендә исәпкә алу, рәсмиләштерү, вакытында түләү һәм хезмәт күрсәтү мәсьәләләре белән бәйләнгән чараларның тулы бер комплексы уздырылды. Дәүләт бурычын киметү буенча чаралар планы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 14 гыйнварындагы 10-р номерлы боерыгы) 2022 елга үтәлде. Бу эшне башкарганда республика бюджеты дефицитын финанслау максатында коммерциячел оешмалардан акча алуга куелган чикләүләр бозылмады.

Инфраструктур проектларны гамәлгә ашыруны финанслар белән тәэмин итүгә 2022 елда федераль бюджеттан 14,3 млрд сумга бюджет кредиты алынды.

2022 елда Татарстан Республикасы федераль бюджет алдындагы бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычны түләүдән азат ителүгә һәм 2017 елның декабрендә һәм 2021 елда реструктуризацияләнгән кредитлар буенча әлеге түләүне 2029 елга күчерүгә федераль дәрәҗәдә бирелгән мөмкинлектән файдаланды. Федераль дәрәҗәдә кабул ителгән карар нигезендә Татарстан Республикасының бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе алдындагы бурычының бер өлеше 2021 елда яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашырудан федераль бюджетка салым керемнәренең тулы суммасына 1,7 млрд сумлык гомуми күләменнән чигерелде.

Ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасы дәүләт бурычының тулаем күләме (дәүләт гарантияләре буенча йөкләмәләрне исәпкә алып) 103,5 млрд сум тәшкил итте. Татарстан Республикасы бюджетының бурыч йөкләмәсе дәрәҗәсе

(салым һәм салым булмаган керемнәрнең еллык күләменә дәүләт бурычы күләменең нисбәте) 28,2 % процент тәшкил итте (2021 ел йомгаклары буенча – 34,5 %). Моңа дәүләтнең бурычка акча алуына югарыда әйтелгән консерватив караш һәм Татарстан Республикасы керем базасын эзлекле арттыруны тәэмин итү кысаларында уздырылган эш нәтиҗәсендә ирешелде.


Россиянең «Аналитика Кредит Рейтинг Агентлыгы» һәм «Эксперт РА» рейтинг агентлыклары Татарстан Республикасының кредит рейтингы Россия Федерациясендә иң югары дәрәҗәсенә җитте дигән бәя бирде.

# ТӨП СОЦИАЛЬ КҮРСӘТКЕЧЛӘР

## Тормыш дәрәҗәсе

Республика предприятиеләрендә һәм оешмаларында, кече эшмәкәрлек субъектларын да кертеп, уртача исәпләп чыгарылган хезмәт хакы 2022 елда 52 088,6 сум тәшкил итте һәм 2021 ел белән чагыштырганда 15,9 процентка артты. Товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә куллану бәяләре индексын исәпкә алып хисапланган реаль хезмәт хакы 101,6 % тәшкил итте.

**Татарстан Республикасында айлык уртача хезмәт хакы**




Уртача исәпләп чыгарылган хезмәт хакы күләме буенча Идел буе федераль округы төбәкләре арасында рэнкингта Татарстан 1 нче урында тора.

Республикада югары хезмәт хаклары икътисадый эшчәнлекнең түбәндәге төрләрендә күзәтелде: файдалы казылмалар чыгару – 82,2 мең сум; мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә эшчәнлек – 78,4 мең сум; финанс һәм иминиятләштерү эшчәнлеге – 74,7 мең сум; һөнәри, фәнни һәм техник эшчәнлек – 69,1 мең сум; электр энергиясе, газ һәм пар белән тәэмин итү; һава әйләнешен булдыру – 65,5 мең сум; эшкәртү производстволары – 59,8 мең сум.

Мәгариф өлкәсендә хезмәткәрләрнең уртача айлык хезмәт хакы 42,1 мең сум, сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә – 47,4 мең сум, мәдәният, спорт, ял һәм күңел ачуны оештыру өлкәсендә 54,6 мең сум тәшкил итте.

Бюджеттан тыш сектор оешмаларында һәм юридик зат буларак теркәлмичә генә эшләүче шәхси эшкуарлар хезмәтенә түләүнең минималь күләмен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе, Татарстан Республикасы Эшкуарлар берләшмәләренең координация советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында даими рәвештә айлык хезмәт хакының минималь күләме турында килешүләр (алга таба – Килешү) төзелә.


Шул рәвешчә, 2023 елның 1 гыйнварыннан 2022 елның 22 декабрендәге Килешү нигезендә минималь хезмәт хакы аена 19 565 сум күләмендә билгеләнде, бу исә 2022 елның III кварталы өчен Татарстан Республикасы буенча тулаем минималь куллану бюджеты бәяләр күләменең 93 процентын тәшкил итә.

Бурычлы предприятиеләр белән эшләү республикада Халыкның тормыш дәрәҗәсен яхшырту, хезмәт, Татарстан Республикасында чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе, шулай ук Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өчьяклы республика комиссиясе каршындагы Хезмәткә түләү, керемнәр һәм халыкның тормыш дәрәҗәсе буенча координация советы эшчәнлеге кысаларында муниципаль берәмлекләрдәге территориаль комиссияләр, тармак министрлыклары, контроль күзәтчелек һәм салым органнары, республиканың һөнәри берлекләре һәм эш бирүчеләре берләшмәләре белән тыгыз хезмәттәшлектә алып барыла.

**Хезмәт базары**

Россия Федерациясендә һәм Татарстан Республикасында халыкка һәм бизнеска ярдәм чаралары күрелү нәтиҗәсендә чикләүләрнең зарарлы нәтиҗәләренең артуына, хезмәткәрләрне күпләп эштән җибәрүгә һәм халыкның эш белән тәэмин ителгәнлегенең кимүенә юл куелмады.

**Эшсезлек дәрәҗәсенең динамикасы**




Халыкара хезмәт оешмасы методологиясе буенча исәпләнгән халыкның эш белән тәэмин ителгәнлек дәрәҗәсе 2022 елда Татарстан Республикасында 62,8 процент тәшкил итте.

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен, Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт хезмәте эшчәнлеген камилләштерү кысаларында «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законына дәүләт хезмәтләре күрсәтү һәм «Россиядә эш» цифрлы нигезгә корылган бердәм платформа ярдәмендә халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү һәм дәүләт функцияләрен үтәү өлешендә үзгәрешләр кертелде. 2023 елның 1 гыйнварына халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә эшсезләр сыйфатында 7,5 мең кеше, ягъни эшчеләр санының 0,37 проценты теркәлгән.

**МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН**

Республикада 1 984 мәктәпкәчә мәгариф оешмасы эшли, аларда мәктәп яшенә җитмәгән 210,1 мең бала тәрбияләнә.

2022 елда 485 урынга исәпләнгән 3 мәктәпкәчә мәгариф оешмасы төзелде, шул исәптән:

Буа һәм Биектау муниципаль районнарында 165 урынлык 2 балалар бакчасы (Буа муниципаль районында Алших авылында 25 урынлык балалар бакчасы, Биектау муниципаль районының Чернышевка авылында 140 урынлык балалар бакчасы) – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары нигезендә;

Түбән Кама шәһәренең 34 нче микрорайонында 320 урынлык 1 балалар бакчасы – финанслауның бюджеттан тыш чыганаклары хисабына.

«Демография» илкүләм проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә:

мәктәпкәчә белем бирү мөмкинлеге белән төрле яшьтәге барлык балалар 100 процентка тәэмин ителде;

Казан шәһәренең 59 нчы кварталында 220 урынга балалар бакчасы төзелә башлады.

2022/2023 уку елында республикада 1 410 гомуми белем бирү оешмасы эшли:

1 292 гомуми белем бирү мәктәбе (шуларның 426 сы авылдагы урта мәктәпләр) һәм 27 мәктәп-интернат;

сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 23 мәктәп һәм 30 мәктәп-интернат;

2 шифаханә-мәктәп-интернат;

девиант тәртипле балалар өчен 1 мәктәп;

10 кичке гомуми белем бирү мәктәбе;

дәүләтнеке булмаган 23 мәктәп;

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы карамагындагы 2 гомуми белем бирү мәктәбе.

Уку елы башында республиканың гомуми белем бирү оешмаларында 486 615 кеше (шуларның авылдагы урта мәктәпләрдә – 69 638 бала) белем алды, педагогик кадрларның саны 36 меңнән артып китте, шуларның 32 меңе – укытучылар.

2022 елда 7 218 урынга 9 гомуми белем бирү мәктәбе төзелде, шул исәптән:

Россия Федерациясенең «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» дәүләт программасының «Авыл территорияләренең заманча йөзе» федераль программасы кысаларында 515 урынга 2 мәктәп (Саба муниципаль районының Байлар Сабасы штп., Кукмара муниципаль районының Балыклы п.) төзелде;

5753 урынга 6 мәктәп, 20 урынга балалар бакчасы белән – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карары буенча (Әлмәт муниципаль районында «Адымнар – белемгә һәм татулыкка юл» –2 мәктәп (1224 укучыга) һәм Түбән Кама муниципаль районында (1224 укучыга), Биектау муниципаль районында 500 урынга мәктәп, Биектау районы Алат авылында 80 урынга мәктәп һәм 20 урынга балалар бакчасы, Зеленодольск шәһәренең Мирный

микрорайонында 1224 урынга мәктәп, Чаллы шәһәренең 69 микрорайонында 1501 урынга мәктәп);

Түбән Каманың 34 микрорайонында бюджеттан тыш финанслау чыганакларыннан тотылган акчага 950 урынга 1 мәктәп.

Түбәндәгеләр капиталь төзекләндерелде:

29 дәүләт, 23 муниципаль, шулай ук 22 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы – 1 769,9 млн сумга, мәктәпләрне төзекләндерү буенча федераль программа кысаларында – 67 гомуми белем бирү оешмасы 3 833,8 млн сумга, шуларның 2 300,3 млн сумы – федераль бюджет акчасы хисабыннан, 1 533,5 млн сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы хисабыннан;

526,0 млн сумга – һөнәри белем бирү оешмалары (ресурс үзәкләре ) – 10 объект һәм һөнәри белем бирү оешмаларының 6 тулай торагы бинасы 198,3 млн сумга;

167 гомуми белем бирү оешмаларының азык әзерләү блоклары – 1,0 млрд сумга.

Республикада түбәндәге гомуми белем бирү оешмалары эшли:

871 – рус телендә белем бирелә торган, шуларның 21е – 2 нче сыйныфтан алып 11 нче сыйныфка кадәр рус теле һәм мәдәнияте тирәнтен өйрәнелә торган, 432 се – 5 нче сыйныфтан алып 11 нче сыйныфка кадәр рус телен өйрәнү сәгатьләре арттырылган мәктәпләр;

татар телендә белем бирелә һәм аерым фәннәр рус телендә өйрәтелә торган 610 гомуми белем бирү оешмасы (филиаллары белән);

белем бирүдә чуваш этномәдәни компоненты кулланылган, чуваш теле өйрәтелә торган 87 гомуми белем бирү оешмасы (филиаллары белән);

белем бирүдә удмурт этномәдәни компоненты кулланылган, удмурт теле өйрәтелә торган 22 гомуми белем бирү оешмасы (филиаллары белән);

белем бирүдә мари этномәдәни компоненты кулланылган, мари теле өйрәтелә торган 16 гомуми белем бирү оешмасы (филиаллары белән);

мордва теле өйрәтелә торган 3 гомуми белем бирү оешмасы (филиаллары белән);

яһүд теле өйрәтелә торган 1 гомуми белем бирү оешмасы.

Сыйныф җитәкчеләренә ай саен бер сыйныфка 550 сум һәм һәрбер укучы өчен 80 сум түләнә. Федераль бюджеттан сыйныф җитәкчеләренә өстәмә рәвештә ай саен 5 000 сум түләү каралган.

Күпмилләтле якшәмбе мәктәпләренең 110 бүлекчәсендә 25 милләтнең (азәрбайҗан, әрмән, таҗик, үзбәк, немец, грузин, корея, бурят, гарәп, якут, кыргыз, әфган, украин, башкорт һәм башкалар) теле һәм мәдәнияте өйрәнелә. 1 788 бала укытыла.

Федераль исемлеккә татар теле һәм әдәбияты буенча 60 дәреслек кертелде.

2022/2023 уку елында 465 128 укучы кайнар ризык белән тәэмин ителде, шулардан 222 489 бала 1–4 сыйныф һәм 242 639 бала 5–11 сыйныф укучылары. Өстәвенә кече сыйныф укучыларының күпчелеге көненә 2 тапкыр ашатыла (туклану белән тәэмин ителгән әлеге яшьтәге балалар саныннан 69 %), урта һәм өлкән сыйныф укучыларының күпчелеге бер тапкыр туклана (туклану белән тәэмин ителгән 5–11 сыйныф укучыларының 70 %). 1–4 сыйныф укучыларын 2022

елда түләүсез туклану белән тәэмин итүгә 1 395,5 млн сум тотылды, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле бюджетлардан – 930,3 млн сум млн сум.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясе субъектлары һәм чит илләрдән килгән балалар өчен тел өйрәнү буенча профильле лагерьлар оештырылды. 2022 елда бу лагерьларда Россия Федерациясенең 25 субъектыннан 835 бала ял итте. Профильле сменалар эшчәнлеге барышында иҗат кичәләре, конкурслар, татар теле дәресләре, татар халкы тарихына багышланган дәресләр, осталык дәресләре, язучылар, республиканың талантлы яшьләре белән очрашулар оештырылды.

2022 елда 2 278 мәгариф оешмасында, 153 муниципаль оешманы да кертеп, балаларга өстәмә белем бирү программасы эшләде. Өстәмә белем бирү программасы буенча шөгыльләнә торган 5 тән алып 18 яшькәчә балалар өлеше бу санда 85,3 % тәшкил итә.

Республикада 99 урта һөнәри белем бирү учреждениесе (87 дәүләтнеке һәм 12 дәүләтнеке булмаган) эшли. Аларда 74 200 студент белем ала. Һөнәри белем бирү эшчәнлеген 45 югары белем бирү мәгариф оешмасы башкара, шул исәптән 26 сы – төп мәгариф оешмасы (16сы – дәүләтнеке, 10 сы – дәүләтнеке (шуларның 3 се дини) булмаган оешмалар), 19 югары белем бирү мәгариф оешмасы филиалы (12се – дәүләтнеке, 7се – дәүләтнеке булмаган оешмалар). Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе субъектлары югары уку йортларының 6 филиалы эшли: 4 филиал дәүләт оешмаларыныкы, 2 се – хосусый оешмаларныкы. Республиканың югары уку йортларында барлыгы 143 711 студент белем ала.

2022/2023 уку елы кабул итү кампаниясе йомгаклары буенча югары белем бирү программалары буенча белем алуга 43499 кеше алынды, аларның 50,3 проценты – көндезге уку бүлекләрендә белем ала.

2022 елда 28 944 кеше югары уку йортларын тәмамлады, шул исәптән көндезге уку бүлекләрендә – 18 389 кеше, кичке уку бүлекләрендә – 904 кеше, читтән торып белем алу бүлекләрендә – 9 651 кеше.

Республикада 20860 чит ил студенты укый, шул исәптән 14 якын һәм 110 ерак чит илдән.

Конкурслар йомгаклары буенча федераль бюджеттан алдынгы инженерлык мәктәпләрен булдыруга һәм аларга ярдәм итүгә субсидия рәвешендә 84,56 млн сумга грантны түбәндәге югары белем бирү мәгариф оешмалары алды:

«Казан (Идел буе) федераль университеты» ФДАМУ – «Казан (Идел буе) федераль университеты» ФДАМУ Чаллы институты (филиалы) базасында «Кибер Авто тех» машина төзү өлкәсендә алдынгы инженерлык мәктәбе (алга таба – К(И) ФУ инженерлык мәктәбе);

«Казан милли тикшеренү технология университеты» ФДБМУ – «Сәнәгать химия технологияләре» алдынгы инженерлык мәктәбе;

«Иннополис университеты» ЮБ АКБО – «Россия программ тәэминатын тизләтелгән эшләү һәм файдалануга тапшыру буенча ИТ-инженерларның яңа буыны» алдынгы инженерлык мәктәбе (алга таба – Иннополис университеты).

К(И) ФУ һәм Иннополис университеты инженерлык мәктәпләренең һәрберсенә 84,56 млн сум бүлеп бирелде.

Төбәкләрнең фәнни-технологик үсеше илкүләм рейтингында Татарстан 5 нче урынны алды.

**«Мәгариф» илкүләм проекты.**

2022 елда Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проектының төбәк өлешләре кысаларында түбәндәге чаралар гамәлгә ашырылды:

*«Һәр баланың уңышы» төбәк проекты:*

Апас муниципаль районының «Апасның аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган гомуми белем бирү урта мәктәбе» МБМУ һәм Баулы муниципаль районының «Покров–Урыстамак урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ спорт залларында капиталь төзекләндерү уздырылды;

*«Заманча мәктәп» төбәк проекты:*

Чаллы шәһәрендә 1 501 урынга 1 мәктәп төзелде һәм ачылды;

Тукай муниципаль районының Шилнәбаш авылында 100 урынга мәктәп төзелә башлады;

республиканың кече шәһәрләрендә һәм авыл җирлекләрендә мәгариф оешмаларында 117 «Үсеш ноктасы» үзәге төзелде;

Бөгелмә муниципаль районы 2 нче лицее базасында «Кванториум» техника паркы ачылды;

2 коррекция мәктәбенең матди-техник базасы яхшыртылды: «Казанның сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 1 номерлы мәктәп-интернаты» ДБМУ һәм «Әгерҗенең сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен мәктәп-интернаты» ДБМУ;

10 укытучыга «Земство укытучысы» программасы кысаларында 1 млн сум түләнде.

*«Цифрлы нигездә белем бирү мохите» төбәк проекты:*

52 мәгариф оешмасында, 46 мәктәпне һәм 6 һөнәри белем бирү оешмасын да кертеп, компьютер җиһазлары яңартылды;

«Алабуга» махсус икътисадый сәнәгать-җитештерү тибындагы зонасы» АҖ базасында «ИТ-клуб» цифрлы белем үзәге төзелде.

*«Яшь һөнәр ияләре» төбәк проекты:*

6 һөнәри белем бирү оешмасы базасында түбәндәге юнәлешләр буенча 12 остаханә ачылды: «Транспортны эшләтү һәм логистика», «Сәнәгать һәм инженерлык технологияләре», «Мәгълүмат һәм коммуникация технологияләре», «Социаль даирә»;

*«Россия Федерациясе гражданнарында ватанпәрвәрлек тәрбияләү» төбәк проекты:*

республиканың мәгариф оешмалары укучыларына тәрбия бирү буенча чаралар уздырылды, эш программалары куллануга кертелде;

190 меңнән артык кеше ватанпәрвәрлек тәрбияләү юнәлешендәге социаль актив эшчәнлеккә һәм чараларда катнашуга җәлеп ителде.

***Мәгарифне цифрлы нигезгә күчерү.***

Республика Россия Федерациясе субъектлары арасында «Мәгариф» тармагы буенча цифрлы өлкәдә белемнәрнең камиллеге күрсәткечләре буенча 6 нчы урынны алды.

Татарстан Республикасы расланган «Цифрлы мәктәп» стандарты нигезендә

дәүләт (муниципаль) мәгариф оешмаларында биналарда дәүләт, муниципаль һәм башка мәгълүмат системаларыннан, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән куркыныч тудырмыйча файдалану өчен ИТ-инфраструктура булдыруга юнәлтелгән федераль проектны гамәлгә ашыру кысаларында түбәндәге чаралар уздырылды:

биналарда дәүләт, муниципаль һәм башка мәгълүмат системаларыннан, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән куркыныч тудырмыйча файдалану 124 мәгариф оешмасы (мәктәп биналары) базасында (Әлмәт, Бөгелмә, Буа, Алабуга, Зеленодольск, Түбән Кама, Тәтеш, Теләче муниципаль районнары, Казан шәһәре һәм Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлекләре мәгариф объектлары) Wi-Fi челтәре белән тоташтыру, видеокүзәтү камераларын урнаштыру һәм тоташтыру буенча инфраструктураны яңартып кору өчен төзелеш-монтаж эшләре башкарылды;

1702 мәгариф объекты (мәктәпләр һәм урта һөнәри белем бирү оешмалары) Бердәм мәгълүмат тапшыру челтәренә тоташтырылды.

«Мәгариф» илкүләм проектының «Цифрлы нигезгә корылган мәгариф өлкәсе» федераль проектын гамәлгә ашыру барышында 52 мәгариф оешмасы (46 мәктәп һәм 6 урта һөнәри белем бирү оешмасы) мәгълүмат-коммуникация җиһазлары белән тәэмин ителде (ноутбуклар, күпфункцияле җайланмалар). Педагоглар өчен 12 мең ноутбук сатып алынды һәм тапшырылды.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигезгә коруны үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән берлектә «Иннополис» университеты һәм «АйСиЭл Техно» мәктәп укытучылары арасында «Цифрлы мәгариф контенты» онлайн-платформадан иң яхшы файдаланучы» дигән конкурс уздырылды. Аның йомгаклары буенча 50 иң яхшы педагогка «АйСиЭл Техно» ААҖ акчасына сатып алынган ноутбуклар бирелде.

2022 елның мартыннан декабренә кадәр гомуми белем бирү оешмаларында һәм савыктыру лагерьларында 10 Цифрлы дәрес уздырылды. Анда 1,7 млн укучы һәм 66 мең педагог катнашты.

Федераль «Мәктәбем» мәгълүмати системасына 1382 дәүләт һәм муниципаль мәктәп тоташтырылды. «Яндекс Академиясе лицее» мәгариф проекты кысаларында 148 укучы Python телендә программалаштыру буенча ике еллык курсларны тәмамлады.

Ел ахырында 3 меңнән артык мәктәп укучысы «Киләчәк коды» федераль программасы кысаларында заманча программалаштыру ысулларына өйрәнү өчен сынауны уңышлы узып, укырга керештеләр.

1 ноябрьдән 25 декабрьгә кадәр «Мин – мәктәп укучысы» мобиль кушымтасы базасында юл куркынычсызлыгы буенча конкурс уздырылды, анда 10 меңнән артык 7 – 11 сыйныф укучысы катнашты. Җиңүчеләргә кыйммәтле бүләкләр тапшырылды.

**Укучыларның төп казанышлары.**

Бердәм дәүләт имтиханы йомгаклары буенча (алга таба – БДИ) 2022 елда йөз балл җыю очраклары – 218, шулардан 14 укучы ике предметтан 100 балл

җыйды. Математика, рус теле һәм ирекле сайлап алынган фән буенча БДИ йомгаклары республикада Россиядәге уртача күрсәткечләрдән югарырак.

2021/2022 уку елында 237 укучы бөтенроссия мәктәп укчылары олимпиадасының йомгаклау этабында призлы урыннар яулап алды. Олимпиадада катнашу нәтиҗәлелеге ягыннан Татарстан Мәскәү шәһәреннән генә калышып, 2 нче урынны яулады.

Ташкент шәһәрендә узган Укучыларның химия буенча 56 нчы Менделеев халыкара олимпиадасында Казан шәһәренең Вахитов районы «131 нче лицей» укучысы Никита Петров алтын медаль яулады.

Онлайн форматта Венгриядә узган Математика буенча хатын-кызларның Европа олимпиадасында шушы ук лицей укучылары Галия Шәрәфетдинова һәм Ралина Йосыпова 2 алтын медаль алды.

Беларусь Республикасында узган X Экспериментал физика буенча олимпиадада 2022 елда Иннополис лицее укучылары Глеб Бороухин һәм Артемий Матвеев бронза медальләр алды.

Болгариянең Шумен шәһәрендә узган XIV Информатика буенча халыкара көзге турнирда Татарстан Республикасы укучылары төрле дәрәҗәдәге 10 медальгә лаек булдылар.

Санкт-Петербургта узган Укучыларның программалаштыру буенча XXIII Бөтенроссия команда олимпиадасында республика укучылары 1 алтын һәм 1 бронза медаль, 2 нче дәрәҗә 2 диплом һәм 3 нче дәрәҗә 3 диплом алды.

«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Байлар Сабасы штп гимназиясе» МБМУ «Комета» мәктәп спорт клубы «Бөтенроссия «Смена» балалар үзәге» ФДБМУ базасында узган Мәктәп спорт клублары бөтенроссия спорт уеннарының Бөтенроссия этабында 2 урынны яулады (Краснодар крае, Анапа районы, Сукко авылы).

Кукмара муниципаль районы Яшүсмерләр командасы Мәскәү шәһәрендәге «КЭС-БАСКЕТ» Беренче Халыкара Суперкубогында җиңеп чыкты.

Республиканың 11 муниципаль берәмлегеннән (Казан, Чаллы шәһәрләре, Түбән Кама, Минзәлә, Арча, Саба, Кукмара, Тукай, Буа, Балтач, Бөгелмә муниципаль районнары) мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүче балалар II BabySkills халыкара чемпионатында актив катнаштылар.

«Яшь һөнәр ияләре – 2022» X милли чемпионатында Россия Федерациясе төбәкләре арасында гомуми медальләр зачетында Татарстан 2 нче урынны яулады. Республика җыелма командасы 2021/2022 еллар «Яшь һөнәр ияләре» чемпионат циклында 111 медаль алды: 34 алтын, 39 көмеш һәм 38 бронза медаль, шулай ук һөнәри осталык өчен 55 медальон.

Туган (татар) телдә белем бирүче мәгариф оешмаларына һәм педагогларга грант ярдәме күрсәтелде. 200 мәктәпкә туган телләрне үстерүгә юнәлтелгән проектларны гамәлгә ашыруга 500 әр мең сум, 100 укытучыга милли мәгариф өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыруга 50 шәр мең сум бирелде.

2022 елда «Ел укытучысы» бөтенроссия конкурсына 30 ел тулды. «Ел укытучысы» номинациясендә Казан шәһәренең Мәскәү районы 2 нче лицей-интернатының тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы И.Р. Җиһаншин җиңеп чыкты; «Педагогик дебют» номинациясендә – Нурлат шәһәренең Советлар Союзы

Герое М.Е. Сергеев исемендәге гимназиянең физик культура укытучысы И.Р. Әмиров җиңүче дип табылды. И.Р. Җиһаншин конкурс лауреаты булды һәм Россиянең иң яхшы 15 укытучы арасында урын алды.

«Иң яхшы туган тел һәм туган әдәбият укытучысы» бөтенроссия һөнәри конкурсы лауреаты буларак Казан шәһәренең Вахитов районы Советлар Союзы Герое А.С. Умеркин исемендәге 116 лицей укытучысы З.А. Габдинова танылды.

**Фәнне һәм фәнни тикшеренүләрне үстерү**

Фәнни-техник мөмкинлекләренең зур булуы Татарстанның конкурентлык өстенлегенең иң әһәмиятлеләреннән берсе булып тора. Университетларның, фәнни оешмаларның, реаль сектор предприятиеләренең һәм фәнни һәм инновация структуралары объектларының үзара тыгыз бәйләнеше – республика икътисады үсеше резервларының берсе һәм аның конкурентлык өстенлеге факторы.

Татарстанда 16 меңнән артык кеше тикшеренүләр алып бара һәм ачышлар белән шөгыльләнә. Республикада 127 фәнни оешма эшли, шуларның 33 е – академик профильле фәнни-тикшеренү оешмалары, 7 се – проектлау-конструкторлык оешмалары, 38 е – югары белем бирү мәгариф оешмасы, 23 е – сәнәгать предприятиеләрендә фәнни-тикшеренү институтлары һәм конструкторлык бюролары, 26 сы – башка төр фәнни оешмалар.

Фәнни-мәгариф комплексының үзеге ролен югары белем бирү өлкәсендә әйдәп баручы мәгариф оешмалары үти, алар арасында бер федераль һәм ике милли тикшеренү университеты аерым урын били.

Моннан тыш, Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге эшчәнлек алып бара, ул 7 эре тикшеренү бүлекчәсен берләштергән тикшеренү платформасы булып тора.

Зур төбәк фәнни учреждениесе – Татарстан Фәннәр академиясе республиканың күпмилләтле халкы мәдәни кодын һәм бай тарихи мирасын саклау буенча эшчәнлеген дәвам иттерә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 22 февралендәге 110 номерлы карары нигезендә «2014–2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы расланды, аның кысаларында «2014–2025 елларга Татарстан Республикасында фәнне һәм фәнни тикшеренүләрне үстерү» ярдәмче программасы гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсеше» (2030 елга кадәр) дәүләт программасы проекты эшләнде һәм аны раслауга әзерлек эшләре бара.

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы мәгариф һәм фән советы дәүләт органнары, иҗтимагый оешмалар, мәгариф һәм фән оешмаларының мәгариф һәм фәнни-техник үсеш өлкәсендә дәүләт сәясәтенең актуаль мәсьәләләре буенча хезмәттәшлеген тәэмин итә. Совет Татарстанның фәнни-техник дәүләт сәясәте гамәлгә ашыруга кагылышлы стратегик һәм оператив-техник мәсьәләләр буенча ачык фикер алышу өчен эксперт мәйданчыгы ролен үти.

Дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан фәнни һәм фәнни-техник эшчәнлекне популярлаштыруга, төрле адреслы кызыксындыру ысуллары, аларның фәнни тикшеренүләренә ярдәм итү механизмнары аша яшьләрнең инновацияләргә кагылышлы һәм тикшеренү активлыгын арттыруга юнәлтелгән

киң колачлы эш алып барыла. Болар – конкурслар, фәнни премияләр, грантлар һәм стипендия программалары. Алар арасында: Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендиясе, Татарстан Республикасының яшь галимнәргә дәүләт ярдәме күрсәтүгә грантлары һәм премияләре, «Мәгариф өлкәсендә инновацияләр» һәм «Перспектива» номинацияләрендә «Илле иң яхшы инновацион идея» республика конкурсы, «Татарстан Республикасының иң яхшы яшь галиме», Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең стипендиясе, студентлар һәм аспирантлар арасында Казан шәһәре мэры исеменнән түләнә торган стипендия алуга конкурс.

Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгы 2022 елда бастырып чыгарган Төбәкләрнең фәнни-технологик үсеше илкүләм рейтингында Татарстан 5 нче урынны били.

**«Фән һәм университетлар» илкүләм проектларын гамәлгә ашыру.**

«Фән һәм университетлар» илкүләм проектлары кысаларында Татарстанда «Фәнни тикшеренүләр һәм кадрлар әзерләү өчен инфраструктураны үстерү» төбәк проекты гамәлгә ашырыла, аны гамәлгә ашыруга 2022 елда федераль бюджеттан 2 546,6 млн сум бүлеп бирелде. Әлеге акчага Иннополис университетының 3 торак корпусы (5, 6-1, 6-2 номерлы) төзелә. Аларны файдалануга тапшыру 2023 елда булачак дип планлаштырыла.

*«Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы.*

«Өстенлек – 2030» стратегик академик лидерлык программасының 2021 елда уздырылган беренче сайлап алу этабы йомгаклары нигезендә республиканың 5 вузы («Казан (Идел буе) федераль университеты», «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ», «Казан милли тикшеренү технология университеты», «Казан дәүләт энергетика университеты», Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениеләре) грантның 100 млн сум күләмендәге база өлешен алуга иреште.

«Казан (Идел буе) федераль университеты» ФДАМУ югары белем бирү оешмалары – грантның «Төбәк һәм тартмак лидерлыгы» юнәлеше буенча махсус өлешен алучыларның берсе булды. 2 елга финанслау күләме (2021 – 2022 еллар) 1 млрд сум тәшкил итте.

Программаларны яклау йомгаклары буенча 2022 елның декабрендә программага кертелгән югары белем бирү мәгариф оешмаларының барысы да югары бәя һәм 2023 елда аны гамәлгә ашыру хокукы алды.

*Алдынгы тикшеренүләр өлкәсе*.

Казан (Идел буе) федераль университеты җитәкчелегендәге консорциум базасында илне фәнни-техник үстерүнең өстенлекле юнәлешләренең берсе – «Планетаның сыек углеводородларын нәтиҗәле файдалану» буенча дөнья күләм танылган фәнни үзәк эшли. Проект гамәлгә ашырыла торган чорга үзәкне төзү һәм булдыру программасын бюджеттан финанслау күләме 2,5 млрд сумлык булачак.

Инновация үсеше өчен югары квалификацияле кадрларны башлангыч әзерләү буенча махсус укыту-фәнни үзәкләре челтәрләрен үстерү өчен грантлар бирүгә сайлап алуның өченче этабы йомгаклары буенча 2021 елда «Казан (Идел буе) федераль университеты», «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» җиңүчеләр булды. 2021 – 2023 елларда әлеге

үзәкләрне үстерүгә гомуми суммасы тиешенчә 600 млн сум һәм 245,5 млн сум булган федераль субсидияләр каралды. Татарстан – «Фән һәм университетлар» илкүләм проекты кысаларында шундый объектлар булдыруга хокуклы булган бердәнбер төбәк.

2020 ел конкурсы йомгаклары буенча Казан дәүләт мәдәният институты инжиниринг үзәкләре төзүгә грант алды. 2021 – 2023 елларга грант 105 млн сум тәшкил итте, шул исәптән 2022 елга – 37,5 млн сум.

Моннан тыш, Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге агросәнәгать комплексында үз эшләнмәләренә нигезләнеп заманча технологияләр булдыру һәм кулланууга кертү өчен субсидияләр бирүгә сайлап алуда җиңеп чыкты. Грант 4 елга бирелә. Федераль бюджеттан финанслау 140 млн сум тәшкил итәчәк, шул исәптән 2022 елда – 50 млн сумга кадәр.

Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәгендә фәннең приборлар базасын яңарту, үзгәртеп кору һәм техник җиһазлау чаралары дәвам иттерелде. Федераль бюджеттан бу максатларда 203,7 млн сум тотылды.

*«Университет технология эшкуарлыгы платформасы» федераль проекты.*

Югары белем бирү мәгариф оешмаларының укучыларында һәм профессор-укытучылар составында эшкуарлык күнекмәләре һәм белемнәрен алдан ук булдыру максатында «Университет технология эшкуарлыгы платформасы» киң колачлы проекты эшли башлады. Аның кысаларында кызыксынган югары белем бирү һәм реаль сектор оешмалары консорциумы җитәкчелегендә Казан (Идел буе) федераль университеты стартап-студия төзү хокукы алды. Проектның федераль операторы – Инфраструктура һәм мәгариф программалары фонды өч ел дәвамында программаны үстерү өчен 3 ел буенча һәр ел саен 100 млн сум грант бүлеп бирәчәк. Стартап-студиянең индустриаль партнеры – «КАМАЗ» ГАҖ.

«Университет технология эшкуарлыгы платформасы» проектын гамәлгә ашыруга юнәлтелгән тагын бер проект – «Студентлар стартапы». Аның йомгаклары буенча 2022 елда бөтен ил буйлап 1030 стартап федераль ярдәм алу хокукына ия булды. Республика вәкилләре грантлар саны буенча Мәскәүдән кала Россия Федерациясе төбәкләре арасында 2 нче урынны алды. Грантның күләме – һәр проектка 1 млн сум.

**Интеллектуаль милек өлкәсен үстерү.**

Интеллектуаль милек буенча федераль хезмәт белешмәләренә караганда, Татарстанның предприятиеләре һәм оешмаларына 2022 елда интеллектуаль милеккә патент алу өчен 1205 гариза бирелде һәм 1058 патент алынды. Шул исәптән 625 патент – уйлап табуга, 372 патент – файдалы модельгә, 61 патент – сәнәгать өлгесенә.

Ел саен товарларны хосусыйлаштыруны теркәүгә бирелгән гаризалар саны арта. 2022 елда республикада яшәүчеләр товар билгеләрен теркәүгә 2037 гариза биргән, 1313 теркәү таныклыгы бирелгән.

«Татпатент» Татарстан Республикасының интеллектуаль мөмкинлекләре» белешмәләр банкы» автоматлаштырылган мәгълүмати-аналитик системасы яңартып корылды. Бу система – кече һәм урта эшкуарлык предприятиеләре, шәхси эшкуарлар, уйлап табучылар өчен фәнни-технологик үсеш инновация проектларын

гамәлгә ашырганда инноваторларга һәм бизнеска ярдәм күрсәтү өчен цифрлы нигезгә корылган платформа.

Проект 2018 елда гамәлгә ашырыла башлады. «Татарстан Республикасы икътисадый үсеше һәм инновация икътисады» дәүләт программасы «2016–2022 елларга Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерү» ярдәмче программасы кысаларында гамәлгә ашырыла. Платформаның операторы – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы карамагындагы «Татарстан фәнни-техник мәгълүмат үзәге» ДУП.

Системаны яңартып кору төп ярдәмче системаларның эшләвен нәтиҗәлерәк итүгә, шулай ук системаның тышкы даирә белән бәйләнешләре өчен яңа кушымталар өстәүгә юнәлтелгән. Аерым алганда, ул интеллектуаль милекнең нәтиҗәсен (уйлап табылган эшләнмә, файдалы модель, сәнәгать өлгесе, ЭВМ өчен программа, белешмәләр базасы, товар билгесе һ.б.) Интеллектуаль милек буенча федераль хезмәттә дәүләт теркәвенә бирелгән гаризалар белән эшләүнең тулы циклына юнәлтелгән. Бу исә мәсьәләләрне хәл итү һәм карарлар кабул итү, документларны, карарлар кабул итү органнары арасында белешмәләр алмашуның куркынычсыз каналлары ярдәмендә хисаплар һәм теркәүгә гаризалар тутыру процессын тизләтергә тиеш.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 17 гыйнварындагы 15 номерлы «Татарстан Республикасында инновация сәясәте нәтиҗәлелеген арттыру чаралары турында» карары кысаларында 2022 елда фәнни-техник үсеш инновация ресурслары республика фондын формалаштыру дәвам иттерелде. Ул инновация эшчәнлеге институтларын, икътисадның реаль секторы предприятиеләрен һәм оешмаларын, Татарстан Республикасының фәнни һәм мәгариф оешмаларын мәгълүмати тәэмин итү максатында гамәлгә ашырыла. Аның базасында түбәндәгеләр эшләнә:

республиканың предприятиеләренә һәм оешмаларына фәнни-мәгълүмати, патент һәм норматив-техник хезмәт күрсәтелә;

патент белән бәйле вазгыятьне анализлау һәм интеллектуаль милекне саклау;

икътисадый эшчәнлек субъектының мәгълүмати ихтыяҗларын исәпкә алуны анализлау;

Финанслау Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән башкарыла торган граждан билгеләнешендәге фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр нәтиҗәләрен (алга таба – НИОКР) дәүләт исәбенә алу һәм саклау эше дәвам иттерелде (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 12 мартындагы 133 номерлы «Граждан билгеләнешендәге фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр нәтиҗәләрен дәүләт исәбенә алу һәм саклау буенча Татарстан Республикасы бердәм системасы турында нигезләмәне раслау турында» карары нигезендә). Бу НИОКР нәтиҗәләрен куллануны системалаштырырга һәм аларның нәтиҗәлелеген арттырырга. шулай ук Татарстанда интеллектуаль милек базары үсеше процессларын дәүләт җайга салуы системасын нәтиҗәлерәк итәргә мөмкинлек бирә.

2007 елдан 2022 елга кадәр Фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр нәтиҗәләрен дәүләт исәбенә алу һәм саклау буенча Татарстан Республикасы бердәм системасында 2 100,1 млн сумлык 2 361 НИОКР теркәлде,

шуларның 81,1 млн сумлык 67 се 2022 елда теркәлде.

2007 елдан 2022 елга кадәр дәүләт контрактлары кысаларында патент алган НИОКР лар 125 берәмлек булды, шуларның 3 се 2022 елда алынды. Патент алган теркәлгән эш нәтиҗәләренең күпчелеге Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе (46 %), Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (23 %), Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы (13 %) һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (7 %) уздырган НИОКРларга туры килә.

## СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ

Ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасында фаразланган гомер озынлыгы 74,58 ел тәшкил итте. Әлеге күрсәткеч буенча Татарстан Россия Федерациясе субъектлары арасында 11 нче урынны, ә Идел буе федераль округы субъектлары арасында 1 нче урынны били.

| Күрсәткеч | Күрсәткеч | Татарстан Республикасы тоткан урын | |
|---|---|---|---|
| | | Россия Федерациясендә | Идел буе федераль округында |
| Туу (1 000 кешегә) | 9,4 | 27 | 1 |
| Төрле сәбәпләрдән үлү (1 000 кешегә) | 11,5 | 16[1] | 1[1] |
| Сабыйларның үлеме (тере туган 1 000 балага) | 3,3 | 6[1] | 3[1] |

[1]Тоткан урыннар күрсәткечне арта бару тәртибендә бүлеп исәпләнде (беренче урын – иң түбән (иң яхшы) күрсәткеч, соңгысы – иң югары (иң начар)

2022 елда төрле сәбәпләр буенча халыкның үлеме күрсәткечләре динамикасы ( 2021 ел белән чагыштырып) (халык санынннан 100 мең кешегә исәпләп):

кан әйләнеше системасы авыруларыннан үлү очраклары 565,8 дән 530,7 очракка кадәр кимегән (6,2 %);

яман шешләрдән үлү 175,4 дән 172,8 очракка кадәр кимегән (1,5 %);

сулыш органнары авыруларыннан үлү 81,0 дән 51,1 очракка кадәр кимегән (36,9 %);

йогышлы чирләрдән һәм паразитлар китереп чыгарган авырулардан үлү 9,3 тән 7,8 очракка кадәр кимегән (16,1 %);

эчке секреция бизләре авыруларыннан үлү 67,3 тән 56,2 очракка кимегән (16,5 %);

психик авырулардан үлү 8,0 дән 5,9 очракка кадәр кимегән (26,3 %);

нерв системасы авыруларыннан үлү 52,6 дан 34,6 очракка кадәр кимегән (34,2 %);

бәвел-җенес органнары системасы авыруларыннан үлү 16,6 дан 15,7 очракка кадәр кимегән (5,4 %);

COVID-19 китереп чыгарган коронавирус инфекциясеннән үлү 280,5 тән 52,1 очракка кимегән (5,4 тапкырга);

аналарның үлеме 14,7 дән 8,2 очракка кимегән (44,2 %).

**«Сәламәтлек саклау» илкүләм проекты**

2022 елда Сәламәтлек саклау» илкүләм проектын гамәлгә ашыруга 4 324,8 млн сум бүлеп бирелде, шуларның 3 229,4 млн сумы – федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 1 095,4 млн сум. «Сәламәтлек саклау» илкүләм проектының төбәк проектлары кысаларында 2022 елда түбәндәге чаралар уздырылды:

*«Татарстан Республикасында башлангыч медицина-санитария ярдәме күрсәтү системасын үстерү» төбәк проекты:*

халыкка медицина ярдәме күрсәтү өчен авиация хезмәте белән тәэмин итү (168 очыш ясалган, 166 пациент эвакуацияләнгән);

Татарстан Республикасы гражданнарын профилактик тикшерүләр белән тәэмин итү.

диспансерлаштыру уздырганда 2153,2 мең кеше тикшерелгән;

мобиль комплекслар республиканың 23 районына чыккан (118 торак пункт), 28,1 мең кеше тикшерелгән, шуларның диспансерлаштыруның II этабы барышында – 5,8 мең кеше;

*«Йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәшү» төбәк проекты:*

дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениеләренең башлангыч кан тамырлары үзәкләрендә баш миендә кан әйләнеше бик нык бозылган авырулар өчен неврология бүлекчәләрен 357 берәмлек медицина җиһазлары белән тәэмин итү (шулардан 6 компьютер томографы) («Түбән Кама күппрофильле үзәк район хастаханәсе» ДАСУ, Казанның «Профессор К.Ш. Зыятдинов исемендәге 18 номерлы үзәк шәһәр клиник хастаханәсе», Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале», Казан шәһәренең «12 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе», «Арча район үзәк хастаханәсе», «Бөгелмә үзәк район хастаханәсе», «Әлмәт үзәк район хастаханәсе»);

йөрәк-кан тамырлары авырулары килеп чыгуны һәм диспансерда күзәтүдә торган, сәламәтлегенә аеруча зур куркыныч янаган авыруларда йөрәк-кан тамырлары авыруларының көчәеп китүен булдырмау өчен дарулар сатып алу (25,4 мең пациент тәэмин ителгән);

*«Онкология авыруларына каршы көрәшү» төбәк проекты:*

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор М.З. Сигал исемендәге Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, шул исәптән Әлмәттәге филиалы өчен 19 берәмлек махсуслаштырылган җиһаз, шулардан 7 се авыр җиһаз (1 бер фотонлы эмиссион компьютер томографы кушма системасы һәм компьютер томографы, 2 якын фокуслы рентген терапиясе аппараты, 1 ангиограф, 2 компьютер томографы, 1 позитрон-эмиссион томография/компьютер томографиясе) сатып алынды;

«Бөгелмә үзәк район хастаханәсе» ДАСУ һәм «Саба үзәк район хастаханәсе» ДАСУ базасында яман шешләрнең төп төрләре буенча комплекслы һәм тиз диагноз кую өчен ике Онкология ярдәме күрсәтү буенча амбулатория үзәге ачылды;

*«Балаларга медицина ярдәме күрсәтүнең заманча инфраструктурасын булдыруны да кертеп, балалар сәламәтлеген саклау өлкәсен үстерү» төбәк проекты:*

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» ДАСУ территориясендә Онкология, гематология һәм хирургия балалар үзәгендә 2 967 пациент дәваланды;

репродуктив сәламәтлекне саклау максатында 15–17 яшьтәге 85 187 балага профилактик медицина тикшерүе уздырылды (100 %);

17 яшькә кадәр 745 884 балага профилактик тикшерүләр уздырыла (107 %);

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» ФДБМУ симуляция үзәгендә перинатология, неонатология һәм педиатрия өлкәсендә 246 белгеч өйрәтелде (план – 229 белгеч);

бала тудыру вакытында һәм аннан соң 35 200 хатын-кызга медицина ярдәме күрсәтелде (100 % ).

*«Сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларын квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү» төбәк проекты:*

яшь белгечләр – табибларга хуҗалык шартларын җайга салу өчен бер тапкыр бирелә торган акча һәм беренче 3 елда өзлексез эшләгән чорында айлык өстәмә түләү рәвешендә социаль ярдәм чараларын финанслауны тәэмин итү. Республиканың сәламәтлек саклау учреждениеләренә эшкә алынган 327 яшь белгечкә (табибка) дәүләт ярдәме күрсәтелә, шуларның 99 ы бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве һәм беренче тапкыр айлык түләү алды.

Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алган табиб-белгечләргә, клиника-лабораториядә диагноз куючы табибларга дәүләт ярдәме чараларын финанслауны тәэмин итү. 100,0 млн сумга 125 грант бирелде;

медицина хезмәткәрләре арасында һөнәри осталык һәм профориентация конкурсларын уздыру;

Өстәмә рәвештә «Земство табибы» һәм «Земство фельдшеры» программалары гамәлгә ашырыла. Бер табибка бер тапкыр бирелә торган түләүнең күләме 1 дән 1,5 млн.га кадәр булды, фельдшерларга –500,0 дән 750,0 мең сумга кадәр. 2022 елда 104 медицина хезмәткәренә компенсация түләве бирелде, шул исәптән 83 табибка һәм 21 урта медицина персоналына.

*«Бердәм дәүләт мәгълүмати сәламәтлек саклау системасы (ЕГИСЗ) нигезендә сәламәтлек саклау өлкәсендә бердәм цифрлы контур булдыру» төбәк проекты:*

сәламәтлек саклау өлкәсендә цифрлы контурны булдыру һәм программа белән тәэмин итүне яңартып кору өчен автоматлаштырылган эш урыннары, оештыру техникасы, сервер җиһазлары сатып алынды;

*«Медицина хезмәтләре экспортын үстерү» төбәк проекты:*

Татарстан Республикасы территориясендә 150 илдән килгән 192 117 чит ил гражданына медицина ярдәме күрсәтелде. Проектны гамәлгә ашыруда 65 медицина оешмасы катнашты, шуларның 57се – дәүләт милекчелеге рәвешендә, 8е – хосусый милекчелек рәвешендә;

Мәскәүдә узган «Россия сәламәтлек саклау» халыкара фәнни-гамәли форумы кысаларында декабрьдә республиканың 2 медимедицина ешмасы («Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор М.З. Сигал исемендәге Республика клиник онкология диспансеры» ДАСУ һәм «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Далалар клиник хастаханәсе» ДАСУ) «Сәламәтлек саклау» илкүләм проектының «Медицина хезмәтләре экспортын үстерү» төбәк проекты кысаларында җиңүче дип табылды.

*«Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасының башлангыч звеносын яңартып кору» төбәк проекты:*

2 835 берәмлек медицина җиһазы, шул исәптән 13 компьютер томографы, 18 флюорограф, 16 маммограф, 16 стационар рентген-аппараты сатып алынды;

32 сәламәтлек саклау объекты төзелде (29 фельдшер-акушерлык пункты, Әлмәт шәһәрендә гомуми практика табибы һәм педиатр үзәге, «Лениногорск үзәк район хастаханәсе» ДАСУ Иске Куак табиблык амбулаториясе, ДАСУ «Питрәч үзәк район хастаханәсе» табиблык амбулаториясе);

15 медицина оешмасы бинасына һәм аларның аерымланган структур бүлекчәләренә, шул исәптән авыл җирлегендә, һәм эшчеләр поселокларында, шәһәр тибындагы поселокларда һәм халык саны 50 мең кешегә җитмәгән кече шәһәрләрдә дә, капиталь төзекләндерү уздырылды (14 поликлиника, 1 табиблык амбулаториясе);

башлангыч медицина ярдәме күрсәтелә торган медицина оешмаларына, шул исәптән авыл җирлегендә һәм эшчеләр поселокларында, шәһәр тибындагы поселокларда һәм халык саны 50 мең кешегә җитмәгән кече шәһәрләрдә дә, медицина оешмаларына пациентлар китерү, медицина хезмәткәрләрен пациентларның өенә алып килү, шулай ук тикшеренүләр уздыру өчен биологик материаллар китерү, ерак районнарда яшәүчеләргә дарулар алып килү өчен 22 берәмлек автомобиль транспорты сатып алынды.

**«Сәламәтлек саклау» буенча республика программалары һәм проектлары.**

*«2025 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү» дәүләт программасының «Сәламәтлекне яхшырту өчен оптималь медицина тернәкләндерүе» федераль проекты төбәк программасы.*

2022 елда 3 медицина оешмасына өстәмә рәвештә 176 заманча тернәкләндерү җиһазлары (248,6 млн сумга) («7 номерлы шәһәр поликлиникасы» ДАСУ (Чаллы), «Кама балалар медицина үзәге» ДАСУ (Чаллы), «Медицина тернәкләндерүе балалар үзәге» (Түбән Кама).

*2020–2021 елга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау өлкәсенең стационар учреждениеләрен капиталь төзекләндерү программасы.*

2022 елда 25 сәламәтлек саклау объекты төзелде:

23 фельдшерлык-акушерлык пункты (146,6 млн сум);

1 патологоанатомия бүлекчәсе (16,5 млн сум);

гомуми практика табибының 1 офисы (62, 2 млн сум).

*«Стационарларны төзү һәм капиталь төзекләндерү» республика программасы кысаларында 2 объект төзелде:*

«Чистай үзәк район хастаханәсе» (Чистай шәһәре) ДАСУ кабул итү-диагностика бүлекчәләре;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» ДАСУ бинасына янкорма (А дәвалау корпусы), Казан шәһәре (магнит-резонанс томографиясен урнаштыру өчен).

Барлыгы 83 сәламәтлек саклау объекты төзелде.

**COVID-19 яңа коронавирус йогышлы чире белән авырган пациентларны медицина тернәкләндерүе**

COVID-19 яңа коронавирус йогышлы чире белән авырган пациентларны тернәкләндерү;

гражданнарның тиз арада терелүе һәм социаль тормышка, хезмәткә һәм һөнәри эшчәнлеккә керешүен тәэмин итү өчен тернәкләндерү өч этапта уздырылды:

I этап – яңа коронавирус йогышлы чире белән авырган барлык пациентларны дәвалау вакытлы инфекция госпитальләре шартларында уздырылды (7 015 пациент);

II этап – тәүлек әйләнәсендә эшли торган стационарлар буларак 2 медицина оешмасы: Казан шәһәренең «7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» һәм «Нехама» шифаханәсе» ҖЧҖ (385 пациент);

III этап – көндезге стационарлар буларак 5 медицина оешмасы: Казан шәһәренең « 21 номерлы шәһәр поликлиникасы» ДАСУ, Чаллының «Сугыш ветераннары госпитале» ДАСУ, Чаллының «7 номерлы шәһәр поликлиникасы» ДАСУ, «Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» ДАСУ, «3 номерлы Әлмәт шәһәр поликлиникасы» ДАСУ (4 271 пациент).

**Медицина ярдәме күрсәтү сыйфатын яхшырту**

Медицина ярдәме сыйфатын яхшырту юнәлешләренең берсе – медицина оешмаларында ISO 9000, EFQM халыкара сыйфат менеджменты стандартларын куллануга кертү. Бу системаны куллана башлаган медицина оешмалары республиканың барлык медицина оешмаларының гомуми саныннан 51,3 % тәшкил итте. Сертификат алган медицина оешмалары өлеше – 18,6 %.

Сәламәтлек саклау учреждениеләре Европа сыйфат менеджменты кысаларында ISO 9001:2015 ирекле сертификатлаштыру, Россия Федерациясе Сәламәтлек өлкәсенә күзәтчелек оешмасының «Медицина эшчәнлегенең сыйфаты һәм куркынычсызлыгы» ирекле сертификатлаштыру системасы таләпләренә туры килү сертификатын, пациентның һәм персоналның иминлеге системасы халыкара сертификатын (JCI) алды:

республиканың 21 сәламәтлек саклау учреждениесе ISO халыкара сертификатына ия;

7 сәламәтлек саклау учреждениесе Европа сыйфат менеджменты фондының (EFQM) «Танылган камиллек» халыкара сертификатына ия булды;

9 сәламәтлек саклау учреждениесе Россия Федерациясе Сәламәтлек өлкәсенә күзәтчелек оешмасының «Медицина эшчәнлегенең сыйфаты һәм куркынычсызлыгы» ирекле сертификатлаштыру системасы таләпләренә туры килү сертификатын, пациентның һәм персоналның иминлеге системасы халыкара сертификатын алды;

1 сәламәтлек саклау учреждениесе JCI халыкара иминлек стандартына туры килә – Чаллының «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе»;

1 учреждениенең Cert International (Словакия) халыкара сертификатына ия – «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» ДАСУ.

Хәзерге вакытта 58 медицина оешмасы медицина эшчәнлегенең сыйфаты менеджменты заманча принципларын куллана башлауларын конкурсларда катнашу аша расладылар. 2022 елда 10 медицина оешмасы «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» конкурсы лауреаты

булдылар. «Татарстанның сыйфат алдынгысы» дигән иң зур бүләгенә Казан шәһәренең «7 номеры шәһәр клиник хастаханәсе» ДАСУ лаек булды.

## ХЕЗМӘТ, МӘШГУЛЬЛЕКҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ

**Хезмәт һәм мәшгульлек.**

2022 елда Татарстан Республикасында 15 тән алып шуннан өлкәнрәк яшьтәге эшчеләр саны 2 028,1 мең кеше тәшкил итте, шулардан 1 981,8 мең кеше икътисад өлкәсендә эшләде һәм 46,3 мең кешенең (яки эшче көчләрнең гомуми санынннан 2,3 %) эше булмады, әмма алар актив төстә эш эзләде (Халыкара хезмәт оешмасы методологиясе нигезендә алар эшсез дип танылa).

2002 елда эшкә урнаштыру хезмәте органнарына 122,7 мең кеше төрле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать иткән, шул исәптән 66,9 мең кеше эш эзләүчеләр сыйфатында исәпкә алынган. Шушы чор эчендә 44,4 мең кешегә эш бирелгән, шуларның 27,1 меңе – эшсез граждан.

2023 елның 1 гыйнварына халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә эшсезләр сыйфатында 7,5 мең кеше теркәлде. Теркәлә торган эшсезлек дәрәҗәсе республика эшчеләр санының 0,37 процентын тәшкил итә (2022 елның 1 гыйнварына – 0,56 %).

2022 ел башы белән чагыштырганда эшсезләр составында түбәндәге үзгәрешләр килеп чыкты:

югары һәм урта белемле гражданнар саны 68,67 проценттан 78,18 процентка, хатын-кызлар өлеше –64,79 проценттан 68,49 процентка, авыл җирлегендә яшәүчеләр өлеше 24,74 проценттан 27,27 процент кадәр артты;

пенсия яшендәге гражданнар өлеше 20,02 проценттан 18,39 процентка, үз теләге белән эштән киткән гражданнар өлеше – 74,91 проценттан 71,48 процентка, 16−29 яшькәчә яшьләр өлеше – 13,17 проценттан 11,66 процентка, беренче тапкыр эшкә урнашкан гражданнар өлеше – 4,97 % проценттан 3,94 процентка, яңадан эшкә урнашырга теләүчеләр өлеше –7,82 процент 7,34 процентка, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче ата-аналар өлеше –37,79 проценттан 35,24 процентка, инвалидлар өлеше – 6,36 проценттан 6,06 процентка кимеде.

Республика буенча эшсезлек уртача 3,88 ай дәвам итте. Республика буенча эшсезлек чорының уртача күрсәткеченнән түбәнрәк күрсәткечләр түбәндәге категорияләрдә күзәтелде: «16−29 яшьлек яшьләр» (2,97 ай), «авылда яшәүчеләр» (3,74 ай), «монопрофильле шәһәрләрдә яшәүчеләр» (3,84 ай). «Хатын-кызлар» категориясендә эшсезлек республика буенча уртача күрсәткечне тәшкил итте – 3,88 ай. «Инвалидлар» категориясендә эшсезлекнең дәвамлылыгы республикадагы уртача күрсәткечтән югары (4,2 ай).

2023 елның 1 гыйнварына, эш бирүчеләр мәгълүматына караганда, республикада 42,3 мең вакансия исәпләнгән. Аларның күпчелеге сәнәгать җитештерүе өлкәсендә (15,5 мең эш урыны), төзелеш һәм күчемсез милек өлкәсендә (3,9 мең эш урыны), транспортта (3,2 мең эш урыны), сәламәтлек саклау өлкәсендә (2,6 мең эш урыны), мәгариф һәм фән өлкәсендә (2,2 мең эш урыны), товар сату һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү өлкәсендә (2,2 мең эш урыны), консалтингта (1,4 мең эш урыны).

Аеруча кирәкле һөнәрләр һәм белгечлекләр дип түбәндәгеләр танылды: автомобиль йөртүче, җитештерү һәм хезмәт күрсәтү биналарын җыештыручы, пешекче, электр һәм газ белән эретеп ябыштыручы, кондуктор, механик җыю

эшләре слесаре, эшче, электр җиһазларын төзекләндерүче электромонтер, слесарь-ремонтчы, йөк төяүче, конвейер линиясе операторы, арматурачы, инженер, урам себерүче, троллейбус йөртүче, тегүче, токарь, аш пешерүче, сак хезмәткәре, кече тәрбияче, тәрбияче, шәфкать туташы.

Хезмәт базарында киеренкелек коэффициенты 1 вакансиягә 0,18 кеше тәшкил итте.

2022 елда Татарстан хезмәт базарында киеренкелекне киметү буенча өстәмә чаралар гамәлгә ашыруда катнашты. Финанслау күләме 870,5 млн сум, шул исәптән федераль бюджеттан – 861,8 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 8,7 млн сум. Бу исә түбәндәгеләрне башкарырга мөмкинлек бирде:

эштән җибәрелү куркынычы булган 17,8 мең эшчегә вакытлы эш оештырып, аларның керем күләмен һәм мәшгульлеген саклап калырга;

1,2 мең эшсез граждан өчен җәмәгать эшләрен оештырырга;

14 сәнәгать предприятиесендә эшсез калу куркынычы янаган 3,8 мең эшчегә һөнәри һәм өстәмә һөнәри белем бирергә.

**Социаль ярдәм.**

Граждан һәм социаль яклау органы арасында гражданга авыр тормыш хәлен җиңеп чыгуда ярдәм итү максатында төзелгән килешү – социаль контракт ярлылыкны киметүнең бер чарасы булып тора. 2022 елда 7,3 мең социаль контракт төзелде, шуларның 93 проценты гражданнарның актив мәшгульлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

Хосусый эшкуарлык алып баруга социаль контракт төзегәндә түләү күләме 350 мең сумга кадәр ( 2021 елда – 150 мең сум), шәхси ярдәмче хуҗалык алып баруга 200 мең сумга кадәр (2021 елда – 75 мең сум) җиткерелде. Хосусый эшкуарлык алып баруга 2 227 контракт, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баруга152 контракт төзелде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 28 декабрендәге 2924-р карары белән 2022–2025 елларга Татарстан Республикасында гаилә һәм демография сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары планы расланды.

«Балалы гаиләләргә айлык түләүләр турында» 2017 елның 28 декабрендәге 418-ФЗ номерлы Федераль закон кысаларында 2018 елның 1 гыйнварыннан соң беренче бала туу (уллыкка яисә кызлыкка алу) белән бәйле рәвештә айлык түләү билгеләнә. 2020 елның 1 гыйнварыннан әлеге түләү, балага 3 яшь тулганчы, җан башына уртача кереме эшләргә сәләтле кешеләр өчен ике яшәү минимумыннан артык булмаган гаиләләргә түләнә. 2022 елда әлеге түләүне 35 мең кеше алды. Федераль бюджет акчалары хисабыннан 3,68 млрд сум бүлеп бирелде.

2018 елдан авыл җирендә даими яшәүче хатын-кызларга ярдәм йөзеннән Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә түләүләр кертелде, 25 яшькә кадәрге хатын-кызларга беренче баласы тугач – 50 мең сум, 29 яшькә кадәргеләргә – өченче һәм аннан соңгы һәр баласына – 100 мең сум. 2018–2022 елларда республикада әлеге түләүне 10,8 мең кеше, 2022 елда – 1,9 мең кеше (1604 кеше – беренче баласы тугач, 358 кеше – өченче һәм аннан да күбрәк баласы тугач). 2022 елда финанслау күләме 115,9 млн сум тәшкил итте.

Татарстан Республикасында балалы гаиләләр өчен социаль ярдәмнең өстәмә чаралары кертелде:

җан башына кереме яшәү минимумыннан түбәнрәк булган өч һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләргә балалар бакчасы өчен компенсациянең күләмен 100 процентка кадәр арттыру. 2022 елда 6,2 мең граждан әлеге түләүләрне алды;

җан башына кереме яшәү минимумыннан түбәнрәк булган гаиләләрдәге 3 яшькә кадәрге балаларга дарулар сатып алуга 10,0 мең сум күләмендә түләү. Әлеге түләүне 23,8 мең граждан алды;

җан башына кереме яшәү минимумыннан артык булмаган гаиләләргә яңа туган сабыйлары өчен кирәк-яраклардан бүләк комплекты. 3,1 мең бүләк комплекты тапшырылды;

18 яшькә кадәрле биш һәм аннан да күбрәк балалы, ата-ананың берсе яисә икесе дә һәм (яисә) балаларның берсе инвалид булган гаиләләргә айлык түләү. Әлеге түләү 1,2 мең гаилә әгъзасына бирелде.

Россия Федерациясе Президентының «Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» 2020 елның 10 мартындагы 199 номерлы Указын үтәү йөзеннән 2020 елның 1 гыйнварыннан җан башына кереме яшәү минимумыннан артык булмаган, 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге (7 яшьне кертеп) балалары булган гаиләләргә айлык түләү билгеләнде. 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга түләү балалар өчен төбәк яшәү минимумының 50 % (5 738 сум), 75 % (8 607 сум) яисә 100 % (11 476 сум) күләмендә дифференцияләнеп бирелә. 79,7 мең балага 6,4 млрд сум акча түләнде.

2000 елдан 5 һәм аннан күбрәк бала табып, аларга лаеклы тәрбия бирүче (тәрбия биргән) хатын-кызларны югары дәрәҗәдә бәяләү билгесе буларак, дәүләт бүләге – «Ана даны – Материнская слава» медале гамәлгә куелды. Соңгы 10 елда «Ана даны – Материнская слава» медале 1,5 мең анага бирелде, аларга 50 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк тапшырылды. 6 яисә аннан күбрәк бала тәрбияләп үстергән аналарга – бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк күләме алтынчы балага һәм аннан соң килә торган һәр балага хисаплап, бүләкләү көненә аларның өч яше тулган булу шарты үтәлгәндә, тиешенчә 10 мең сумга арта. 2022 елда «Ана даны – Материнская слава» медале белән 22 ана бүләкләнде.

Гаиләнең һәм ата-ана хезмәтенең абруен күтәрү максатларында Татарстан Республикасының яңа дәүләт бүләге – «Ата-ана фидакарьлеге» медале гамәлгә куелды, ул 7 һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүче яисә тәрбияләгән гаиләләргә биреләчәк. Әлеге медаль белән бүләкләнгән ата-ананың (уллыкка яисә кызлыкка алучының) берсенә 100 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк тапшырыла. 2022 елда 9 ата-ана бүләкләнде.

Күрелгән чаралар нәтиҗәсендә күпбалалаы гаиләләр саны 2012 елның 1 гыйнварындагы 24,8 меңнән 2023 елның 1 гыйнварына 42,2 меңгә артты.

**Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм күрсәтү**

2022 елда гражданлык җәмгыятенең һәм дәүләт органнарының уртак тырышлыгы махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның балаларына бер тапкыр акчалата түләү

биру турында» 2022 елның 16 ноябрендәге 1225 номерлы карары нигезендә махсус хәрби операциядә катнашучы гражданның 18 яшькә җитмәгән һәр баласына бер тапкыр 20 мең сум күләмендә акча түләнде, шул исәптән:

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә Татарстан Республикасы территориясендә мобилизация буенча хәрби хезмәткә алынган гражданның;

Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче һәм махсус хәрби операциядә катнашучының;

Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы һәм махсус хәрби операциядә катнашучының;

мобилизация буенча хәрби хезмәткә алынган көнгә Татарстан Республикасы территориясендә яшәгән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә Россия Федерациясенең башка субъекты территориясендә мобилизация буенча хәрби хезмәткә алынган, шулай ук махсус хәрби операция барышында ирекле рәвештә хәрби бурыч үтәүче гражданның (махсус хәрби операциядә ирекле рәвештә катнашуга контракт төзегән);

мобилизация буенча хәрби хезмәткә алынган көнгә Татарстан Республикасы территориясендә яшәмәгән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә Россия Федерациясенең башка субъекты территориясендә мобилизация буенча хәрби хезмәткә алынган, шулай ук махсус хәрби операция барышында ирекле рәвештә хәрби бурыч үтәүче гражданның (махсус хәрби операциядә ирекле рәвештә катнашуга контракт төзегән), гражданның мобилизация буенча хәрби хезмәткә алыну (махсус хәрби операциядә ирекле рәвештә катнашуга контракт төзү) көненә баласының Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәве шарты үтәлгән очракта;

Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының (Татарстан Республикасында эчке эшләр органнарының), Россия Федерациясе куркынычсызлык федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең махсус хәрби операция уздырылган зонага командировкага җибәрелгән хезмәткәренең.

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә алынган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә өстәмә ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның һәм махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак (вафат) булган гражданнарның гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карары кабул ителде. Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаилә әгъзаларына өстәмә ярдәм чарлары шул исәптән түбәндәгеләргә күрсәтелә:

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә алынган гражданнарга;

махсус хәрби операция барышында ирекле рәвештә хәрби бурычларын үтәүчеләргә;

Россия Федерациясе милли гвардиясендә, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хезмәт итүчеләргә;

махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе

Федераль Куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре.

Әлеге категория гражданнарның гаилә әгъзаларына, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә дәүләт ярдәменең түбәндәге өстәмә чаралары күрсәтелә:

гаиләнең  җан башына уртача керемен исәпкә алмыйча, яңа туган балалары булган гаиләләрне бала кирәк-яраклары булган бүләкләү комплектлары белән тәэмин итү;

гаилә әгъзалары – лаеклы ялда булган һәм 60 яше (ир-атлар) һәм 55 яше (хатын-кызлар) тулган гражданнарга санаторий-курорт дәвалануына путевкалар алуга беренчел хокук бирү;

гаилә әгъзалары – өлкән яшьтәге гражданнарга һәм I һәм II төркем инвалидларга бушлай өйдә социаль  хезмәт күрсәтү;

гаилә әгъзалары – өлкәннәр һәм инвалидлар өчен интернат-йортларга, психик тайпылышлары булган гражданнар өчен интернат-йортларга, мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренә социаль  хезмәт күрсәтүгә кабул итүдә беренчел хокук бирү;

гаилә әгъзалары – инвалид балаларга мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренә социаль  хезмәт күрсәтүгә кабул итүдә беренчел хокук бирү;

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы законның 3 статьясы 2 пункты нигезендә үзләре өчен кулай булган эш эзләү максатларында теркәлгән гаилә әгъзаларын, әгәр эш белән тәэмин итү хезмәтләре аларга кулай эш тәкъдим итү мөмкин булмаган очракта, кулай эш эзләүдә ярдәм итү мөрәҗәгате белән дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап гариза биргән көннән өч көннән дә соңга калмыйча, алар эшсез дип тану;

гаилә әгъзалары – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында урта буын белгечләре әзерләү программалары буенча көндезге уку бүлекләрендә укучы студентларны бер тапкыр бушлай кайнар ризык белән тәэмин итү;

гаилә әгъзалары – Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларында 1–11 сыйныфларда укучы мәктәп укучыларын ике тапкыр бушлай кайнар ризык (иртәнге һәм көндезге ашлар) белән тәэмин итү;

Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, 7 яшьтән алып 17 яшьлек балалары булган гаиләләрнең ялын оештыру өчен путевкалар белән тәэмин итүгә беренчел хокук бирү.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хезмәт итүчеләргә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне бирү тәртибен раслау турында» 2022 елның 11 июлендәге 663 номерлы карары нигезендә республикада төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хезмәт итүчеләргә  360,0 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирелде, шул исәптән:

65,0 мең сум – граждан хәрби хезмәт узу өчен хәрби часть исемлекләренә кертелгәннән соң, аннары атна саен 15,0 мең сум (барлыгы 110,0 мең сум);

250,0 мең сум – Россия Федерациясенең Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Херсон һәм Запорожье өлкәләрендә, Украина террторияләрендә «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт уза башлаганнан соң.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең һәм аларда хезмәт иткән затларның гаилә әгъзаларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү тәртибен раслау турында» 2022 елның 15 апрелендәге 357 номерлы карары нигезендә махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларына тигез өлешләргә бүлеп, 2,0 млн сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү бирелә:

хәрби хезмәткәрнең һәлак булган (вафат булган) көненә аның белән законлы рәвештә никахын теркәгән хатынына (иренә);

хәрби хезмәткәрнең ата-анасына (уллыкка алучыларга);

хәрби хезмәткәрнең ул балигъ булганчыга кадәр кимендә биш ел дәвамында опекуны (попечителе) булып торган затларга;

хәрби хезмәткәрнең балаларына.

**«Демография» илкүләм проекты.**

2022 елда «Демография» илкүләм проекты максатларына ирешүгә юнәлдерелгән төбәк проектлары кысаларында түбәндәге чаралар тормышка ашырылды:

*«Балалар туганнан соң гаиләләргә финанс ярдәме күрсәтү» төбәк проекты*:

34,9 мең кешегә 3,68 млрд сум күләмендә беренче баласы туу (уллыкка алу) белән бәйле рәвештә айлык түләүләр бирелде;

мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә компенсация бирелде;

республика территориясендәге авылларда, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга беренче, өченче һәм аннан соңгы балалар туу белән бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирелде;

өч һәм аннан күбрәк игезәк балалар тәрбияләүче гаиләләргә пособиеләр бирелде;

«Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләнгән аналарга, «Ата-ана фидакарьлеге» ордены белән бүләкләнгән ата-аналарга (уллыкка алучыларга) бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирелде;

уртача кереме Татарстан Республикасы территориясендә билгеләнгән җан башына туры килә торган яшәү минимумыннан артык булмаган гаиләләрдәге ясалма катнаш тукланууда булган һәм хроник авырулары булган 36 159 өч яшенә кадәр бала бушлай махсус балалар ризыгы белән тәэмин ителде;

1 909 экстракорпораль орлыкландыру процедурасы уздырылды.

*«Халыкка эшкә урнашуда ярдәм итү» төбәк проекты:*

федераль бюджет хисабыннан 9,2 мең кеше укырга җибәрелде, шул исәптән:

халыкны эш белән тәэмин итү органнарында теркәлгән, эштән азат итү куркынычы алдында калган гражданнар, пенсия алды яшендәге гражданнар һәм 50 яшь һәм аннан да өлкәнрәк булган 3 мең эшсез граждан;

баласына 3 яшь тулганчы бала карау буенча отпускта булган, хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаучы һәм 7 яшьне кертеп, мәктәпкәчә яшьтәге балалар тәрбияләүче 4,3 мең хатын-кыз;

35 яшьне кертеп, төрле категория яшьләр арасыннан 1,9 мең кеше.

Укыту хезмәт базарында ихтыяҗ булган профессияләр һәм белгечлекләр буенча, шул исәптән эшкә алу турында гарантия белән тәгаен эш бирүче заказы буенча алып барыла. Укытудан соң эшкә урнаша алу дәрәҗәсе 91 процент тәшкил итә.

*«Өлкән буын» төбәк проекты:*

озак вакытка исәпләнгән һәм гаиләдә тәрбияләүне үстерү системасы оештырылган. 2022 елда финанслау күләме 84 мең сум тәшкил итте, шул исәптән федераль бюджеттан – 68 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 16 млн сум. Уздырылган чаралар нәтиҗәсендә:

бушлай социаль пакет кысаларында 6,1 мең өлкән яшьтәге гражданга һәм инвалидка озак вакытка исәпләнгән тәрбиягә алу хезмәте, 302 өлкән яшьтәге гражданга (инвалидка) тәрбияче хезмәте күрсәтелде;

көндезге бүлекләрдәге (төркемнәрдәге) когнитив һәм менталь авырулары булган өлкән яшьтәге кешеләр һәм инвалидлар көндез эш белән тәэмин ителде;

3,0 мең гаилә әгъзасына гаиләдә тәрбияләү нигезләре өйрәтелде;

авылларда яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк булган 63,5 мең граждан медицина оешмаларына урнаштырылды, шул исәптән 38,3 мең кеше – диспансеризация һәм профилактик медицина тикшеренүләре узды;

65 яшьтән өлкәнрәк булган затларның пневмококк йогышлы авыруына каршы торучанлыгын арттыру максатларында вакцина эшләнде. 2022 елда 300 кешегә (планда 100 %) вакцина ясалды.

65 яшьлек һәм аннан өлкәнрәк булган затларга медицина-социаль хезмәте күрсәтүгә 10 хосусый медицина оешмасын җәлеп итү буенча пилот проектын тормышка ашыру дәвам итә. Пилот проекты кысаларында 314 кешегә медицина-социаль хезмәте күрсәтелде, шулардан 2022 елда – 97 кеше. Федераль бюджет хисабыннан финанслау күләме 8,43 млн сум тәшкил итте.

*«Җәмәгатьчелек сәламәтлеген ныгыту» төбәк проекты:*

республиканың 4 шәһәрендә җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы үзәкләре эшли (Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт шәһәрләрендә);

республиканың 37 муниципаль берәмлегендә халык арасында җәмәгать сәламәтлеген нытыгу муниципаль программалары расланды, алар сәламәт яшәү рәвешен, дөрес туклануны, алкоголь һәм тәмәкедән баш тартуны профилактикалау чараларын күздә тота;

Казан, Чаллы, Түбән Кама, Зеленодольск һәм Мөслим муниципаль районнарында предприятиеләрдә һәм оешмаларда эшләүчеләрнең сәламәтлеген ныгыту корпоратив программаларын гамәлгә кертү буенча 22 килешү төзелде.

**ФИЗИК КУЛЬТУРА ҺӘМ СПОРТ**

**Спорт инфраструктурасы.**

Татарстан – Россия Федерациясендә спорт объектлары белән тәэмин ителгән төбәкләр арасында лидерларның берсе. Республикада 11 651 спорт корылмасы эшли, 6 327 бер яссылыкта урнашкан спорт корылмасы, 2 061 спорт залы, 46 стадион, 54 ябык боз аренасы, 28 манеж (10 җиңел атлетика буенча, 18 футбол), 281 йөзү бассейны, 91 чаңгы базасы, 1 биатлон комплексы, 2 ишкәк ишү базы, 186 ату буенча спорт төрләре, 2 574 башка спорт корылмасы эшли.

2022 елда 197 спорт корылмасы төзелде.

Универсаль спорт мәйданчыклары төзү буенча республика программасы кысаларында түбәндәгеләр төзелде:

Биектау, Буа, Минзәлә, Нурлат, Мамадыш, Алабуга муниципаль районнарында каркас-тент капламы булган 6 ябык футбол манежы;

3 универсаль спорт мәйданчыгы;

1 блоклы модульле чаңгы базасы (Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогында).

Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслау нәтиҗәсендә Менделеевск шәһәрендә футбол стадионы, Лениногорск шәһәрендә боз сарае, Зеленодольск муниципаль районының Васильево шәһәр тибындагы поселогында йөзү бассены һәм Тәтеш муниципаль районында спорт комплексы булган 8 универсаль спорт мәйданчыгы файдалануга тапшырылды.

Гомуми суммасы 500,0 млн сумга 23 спорт объекты капиталь төзекләндерелде.

«Спорт – тормыш нормасы» төбәк проекты һәм «Бизнес-спринт (Мин спортны сайлыйм)» федераль проекты кысаларында түбәндәге чаралар тормышка ашырылды:

Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр тибындагы поселогында ясалма боз түшәлгән ябык шугалак;

Әлмәт, Югары Ослан, Кайбыч, Лениногорск, Балык Бистәсе һәм Тәтеш муниципаль районнарында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» мәйданчыклары өчен җиһазлар китертелде һәм урнаштырылды;

18 спорт мәктәбе өчен (8 республика һәм 10 муниципаль) җиһазлар һәм кирәк-яраклар сатып алынды;

Казан шәһәрендә «акыллы» спорт мәйданчыгы төзелде.

Бер үк вакытта спорт объектларында күпме кеше шөгыльләнә алу мөмкинлеген исәпкә алып, гражданнарның спорт корылмалары белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе, 71,5 % тәшкил итте (2021 елда – 70,4 %).

**Физик культура.**

2022 ел йомгаклары буенча республикада 1,9 млн кеше системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнә, бу исә 3 яшьтән алып 79 яшькә кадәрле кешеләрнең гомуми санынннан 52,9 процентны тәшкил итә (2020 елда – 51,3 %).

Халыкның физик активлыгы артуның уңай динамикасы, беренче чиратта, «Демография» илкүләм проектына керүче «Спорт – тормыш нормасы» дигән федераль проектны гамәлгә ашыру хисабына тәэмин ителә, анда барлык категория

гражданнарга физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар булдыру күздә тотыла.

Республика Бөтенроссия йөзү федерациясе тарафыннан уздырыла торган «Йөзү һәркем өчен» ведомствоара программасын тормышка ашыруның иң яхшы тәҗрибә бөтенроссия конкурсында җиңүче булды.

Кукмара муниципаль районы яшүсмерләре командасы «КЭС-Баскет» мәктәп баскетбол лигасы чемпионаты суперфиналында һәм мәктәп командалары арасында «КЭС-Баскет» халыкара суперкубогында җиңү яулады.

Казан шәһәренең «ЮНИТ» командасы «Күн туп» футбол буенча бөтенроссия ярышлары суперфиналында җиңүче булды.

Арча муниципаль районының «Арчаның 6 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе командасы «Регби мәктәп лигасы» бөтенроссия ярышларында җиңү яулады.

2030 елга кадәр «Йөзү һәркем өчен» республика программасы проекты эшләнде, аның кысаларында гомуми белем бирү учреждениеләрендә балаларны йөзүгә өйрәтү планлаштырыла.

Физик культураны һәм спортны популярлаштыру максатларында TIMERMAN спорт чаралары комплекслы программалары һәм «Яшел Фитнес» социаль-спорт проекты тормышка ашырыла. 2022 елда TIMERMAN спорт оешмасы тарафыннан Россиянең 18 төбәгеннән 25 кеше катнашында 10 спорт чарасыннан торган серия уздырылды (Казан, Әлмәт, Чаллы, Иннополис шәһәрләрендә, Свияжск утрау-шәһәрендә).

«Казан марафоны» ярышында йөгерү белән шөгыльләнүче 12 меңнән артык кеше катнашты.

**Спорт резервын әзерләү.**

Татарстанда 161 спорт мәктәбендә, шулардан 29 спорт мәктәбе «олимпия резервы» статусына ия, 78 спорт төре, шул исәптән 46 олимпия (шулардан 8 паралимпия һәм 5 сурдлимпия) һәм 32 олимпия төренә кермәгән (шулардан 3 дисциплина баш мие авырулары булган затлар өчен) укытыла.

Барлыгы спорт мәктәпләрендә 93 639 кеше шөгыльләнә, 2 982 тренер бар.

2022 елда спортта югары казанышларга ирешкән өчен 935 спортчы айлык стипендия ала. Югары спорт күрсәткечләренә ирешкән спортчылар әзерләгән өчен республиканың 111 тренерына өстәмә түләү билгеләнде.

2022 елда бик күп санда спорт дәрәҗәсе һәм разряд бирелде: 8 Россиянең атказанган спорт мастеры, 17 халыкара класслы Россия спорт мастеры, 229 Россия спорт мастеры һәм 1 559 спорт мастерына кандидат.

**Спорт казанышлары.**

Республикада 133 спорт федерациясе эшли, алар 136 спорт төрен үстерү өчен җаваплы.

Ел саен бөтенроссия һәм халыкара ярышларда яулап алынган медальләр санының уңай динамикасы күзәтелә. Россия Федерациясе җыелма командаларына Татарстаннан 907 спортчы кертелде, шулардан спортның олимпия төрләре буенча – 457 спортчы.

Татарстан спортчылары тарафыннан бөтенроссия һәм халыкара дәрәҗәдәге ярышларда 944 медаль яулады, шулардан 286 – алтын, 317 – көмеш, 341 – бронза.

2022 елда XXIV Кышкы олимпия уеннарында Пекин шәһәрендә Россия җыелма командасы составына Татарстан Республикасыннан спортның 5 төре буенча 8 спортчы керде, шулардан призлы урыннарны: чаңгыда трамплиннан сикерү буенча – Данил Садриев (көмеш медаль); фигуралы шууы буенча – Евгения Тарасова (көмеш медаль); хоккей – Дмитрий Воронков һәм Тимур Билялов (көмеш медальләр); сноубордта – Виктор Вайлд (бронза медале).

Татарстан спортның 35 база төре буенча җаваплы, шуларга 33 спортның олимпия төре керә, шул исәптән 27 индивидуаль (бадминтон, бокс, велосипед спорты, гольф, байдаркаларда һәм каноэда ишү, ишкәк ишү, дзюдо, җиңел атлетика, өстәл теннисы, йөзү, суга сикерү, ядрә белән ату, синхрон йөзү, спорт көрәше, спорт гимнастикасы, стендка ату, теннис, триатлон, тхэквондо, авыр атлетика, фехтование, фигуралы шуу, нәфис гимнастика, ике төрдә чаңгы ярышлары, чаңгы ярышлары, чаңгыда трамплиннан сикерү, сноуборд); 6 уен (су полосы, волейбол, регби, футбол, чирәмдә хоккей, хоккей), 2 паралимпия төре (терәк-хәрәкәтләнү аппараты зарарланган затлар өчен спорт), 1 сурдлимпия төре (сукырлар өчен спорт).

2022 елда

«КАМАЗ-мастер» командасы «Дакар» ралли-марафонында 19 нчы тапкыр җиңү яулады;

«Динамо-Ак Барс» чирәмдә хоккей буенча ир-ат командасы Россия чемпионатында 20 нче тапкыр җиңү яулады, «Ак Барс-Динамо» хатын-кызлар командасы шулай ук Россия чемпионатында җиңүгә иреште;

«Синтез» ир-атлар су полосы клубы 4 нче тапкыр һәм 3 нче сезон рәттән Россия чемпионатында җиңү яулады;

«Зенит-Казан» ир-атлар волейбол клубы 11 нче тапкыр Россия волейбол кубогын яулады.

**Спорт чаралары.**

Россия Федерациясенә карата чикләү чаралары кертелү белән бәйле рәвештә республика территориясендә узган ел 21 спорт чарасы уздырылмады. Ләкин шуңа да карамастан, альтернатив спорт проектлары тормышка ашырылды:

«Дуслык уеннары» йөзү, синхрон йөзү һәм суга сикерү буенча комплекслы халыкара ярышлар;

«Киләчәк уеннары» халыкара ярышларының тест ярышлары, аларны 2024 елның февралендә Казан шәһәрендә уздыру планлаштырыла һәм ул 16 гибрид дисциплинасы буенча проектны үз эченә ала;

спортчылар арасында Спортның җәйге төрле буенча бөтенроссия спартакиадасы;

2024 елда Париж шәһәрендә җәйге Олимпия уеннары программасына керәчәк, Россия субъектлары арасында 39 спорт төре буенча ярышларны үз эченә алган комплекслы чаралар (Татарстан Республикасы командалар арасында 4 нче урынны яулады).

2022 елда барлыгы республикада спортның 11 төре буенча (волейбол, ишү спорты, дзюдо, суга сикерү, спорт көрәше, спорт гимнастикасы, бию спорты, чирәмдә хоккей, ядрә белән ату, стендка ату, самбо) ярышлар булып узды.

**Физик культураны һәм спортны цифрлы нигезгә кору.**

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы «Россия спортын цифрлы нигезгә кору – 2022» физик культураны һәм спортны цифрлы нигезгә кору өлкәсендә II бөтенроссия конкурсында «Физик культура һәм спортка идарә итү буенча иң яхшы төбәк органы» номинациясендә җиңү яулады.

Республиканың барлык спорт мәктәпләрендә «Минем спорт» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы – спортчылар һәм аларның ата-аналары, тренерлар, спорт федерацияләре, спорт оешмалары һәм дәүләт хакимияте органнары өчен бердәм онлайн-платформа кертелде.

Әлеге мәгълүмат системасына аккредитацияләнгән спорт федерацияләрен кертү буенча актив эш алып барыла, ул электрон рәвештә спорт һәм физик культура чараларының календарь планы белән эшләргә һәм чаралар уздырырга мөмкинлек бирәчәк.

2022 елда 9 дәүләт хезмәтен электрон төргә күчерү эше төгәлләнде:

төбәк иҗтимагый оешмаларына һәм гомумроссия спорт федерациясе структур бүлекчәләренә (төбәк бүлекчәләренә), аларга төбәк спорт федерациясе статусы бирү максатыннан дәүләт аккредитациясе бирү;

спорт разрядлары бирү;

спорт судьяларына квалификация категорияләре бирү;

спорт әзерлеге программаларына язылу;

тренерларга, Татарстан Республикасы территориясендә физик культура һәм спорт өлкәсендә белгечләргә квалификация категорияләре бирү;

социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларга күрсәтелгән җәмгыять өчен файдалы хезмәтләрнең сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү;

белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыручы һәм Татарстан Республикасы карамагында булган оешмаларның педагогик хезмәткәрләренә, белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыручы муниципаль һәм хосусый оешмаларның педагогик хезмәткәрләренә аттестация уздыру;

каникуллар чорында балалар ялын оештыру;

урта һөнәри белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларында укуга гаризаларны кабул итү һәм теркәү.

## ЯШЬЛӘР СӘЯСӘТЕ

2022 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасында 384 яшьләр сәясәте учреждениесе исәпләнелә.

**Яшьләрнең ирекleләр хәрәкәте.**

Яшьләрнең ирекләләр хәрәкәтендә 138 мең кеше катнашты. «Мәгариф» илкүләм проектының «Социаль активлык» төбәк проекты кысаларында 6 юнәлеш буенча «Игелекле эшләр төбәге» федераль конкурсы чаралары уздырылды:

Like a Donor 2.0 («Казан (Идел буе) федераль университеты» ФДАМУ, Казан шәһәре);

«Үз кулың белән кылынган игелек» («Түбән Кама волонтерлык үзәге» АКБО, Түбән Кама муниципаль районы);

«Чиста уеннар – Татарстан» экологик ярышлары («Татарстан Республикасы балалар оешмалары советы» төбәк иҗтимагый оешмасы, Казан шәһәре);

«Ирекләләр мәктәбе 2022» (Чаллы шәһәренең «Орион» яшьләр үзәге» муниципаль автоном учреждениесе);

«Минем иң яхшы ягым» фотокүргәзмәсе (Казан шәһәренең «Донор-Серч» донорлыкны үстерү коммерциячел булмаган партнерлыгы ассоциациясе);

«Күңел белән яшь!» («Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Бөгелмә муниципаль районындагы «Салават күпере» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе).

«Изге эшләр төбәге» ирекләләр хәрәкәтенә ярдәм итү буенча иң яхшы төбәк тәҗрибәләре бөтенроссия конкурсында Татарстан Республикасы инде дүртенче ел рәттән, ирекләләр хәрәкәтен үстерү буенча ресурс үзәге статусын раслап, «Изге эшләр төбәге» дигән мактаулы исемгә лаек булды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, волонтерлык үзәкләре ассоциациясе һәм «Татарстан Республикасы ирекләләр хәрәкәтенең мәгълүмат-ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы арасында республика территориясендә ирекләләр хәрәкәтен (волонтерлыкны) үстерү турында килешүгә кул кую 2022 елның иң мөһим вакыйгасы булып тора.

**Патриотик тәрбия.**

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан башка кызыксынган министрлыклар һәм ведомстволар, муниципалитетлар, иҗтимагый берләшмәләр белән берлектә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартындагы 158 номерлы карары белән расланган «2019–2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасының «2019–2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләргә патриотик тәрбия бирү» ярдәмче программасын (алга таба – ярдәмче программа) гамәлгә ашыру кысаларында яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча эш алып барылды.

Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруга 2023 елга Татарстан Республикасы бюджетыннан 10,05 млн сум каралган.

Ярдәмче программаның төп максаты – республикада иҗтимагый һәм икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итә торган патриотик тәрбия бирү системасын

үстерү һәм яңартып кору, балаларда һәм яшьләрдә гражданлык тәңгәллеген, югары ватанпәрвәрлек үзаңын, Ватанга тугрылык, конституциячел бурычларын үтәүгә әзер булу, толерантлык, этникара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр культурасын формалаштыру.

2022 елда ярдәмче программа кысаларында 42 зур чара уздырылды, аларда 14 яшьтән алып 35 яшькә кадәрле 184 мең кеше катнашты, шул исәптән «Аҗаган» хәрби-спорт уенында – 41 мең кеше; «Мин – Россия гражданы!» акциясендә – 3 меңнән артык кеше; җәйге палаткалы хәрби-патриотик лагерьларда – 3 мең кеше, шул исәптән, авыр тормыш шартларында калган 357 бала; «Җиңү» хәрби-спорт уенының республика этабында – 12 кеше катнашты.

Яшьләр сәясәтенең өч учреждениесе базасында («Патриот» яшьләрнең спорт-патриотик һәм хәрби хезмәткә алынганчы әзерлеге үзәге» ДАУ, Чистай муниципаль районының «Ватан» яшьләрнең спорт-патриотик һәм хәрби хезмәткә алынганчы әзерлеге үзәге» МБУ, Түбән Кама муниципаль районының «Патриот» яшьләрнең спорт-патриотик һәм хәрби хезмәткә алынганчы әзерлеге үзәге) «Авангард» яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирүнең тәэмин итү өлкәсендә бурычларны хәл итү кысаларында гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның хәрби-укыту җыеннарын оештыру үзәкләре төзелде. Гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының хәрби-укыту җыеннарын уздыруга Татарстан Республикасы бюджетында 2023 елга 25,7 млн сум күләмендә акча каралган. Хәзерге вакытта 38 муниципаль берәмлектә 10 яшьтән 16 яшькә кадәр 14 083 яшүсмер катнашында 153 хәрби-патриотик клуб төзелде.

«Татарстан Республикасының «Ватан» берләшмәсе» төбәк яшьләр оешмасы эзләү эшчәнлеген башкара һәм 1 200 кешедән артык катнашучы кергән 67 эзләү отрядын берләштерә. 31 муниципаль берәмлектәге 67 торак пунктта Бөек Ватан сугышы чоры 79 хәрбиләр күмелгән урын исәпкә алынды. Бөек Ватан сугышы вакытында сугышлар барган урыннар буенча 30 экспедициядә республика эзләү отрядлары катнашты. Экспедицияләр барышында 311 сугышчының мәете табылды.

2022 елның апрелендә «Җиңү» бөтенроссия хәрби-спорт уенының республика этабы узды. Май аенда – кадетлар арасында «Татарстан Республикасы ветераннары берлеге» сугыш ветераннары (инвалидлары) республика иҗтимагый оешмасы күчмә кубогына спортның хәрби-гамәли төрләре буенча республика олимпиадасы булды, ул Ватанны саклаучылар көненә багышланган иде. Сентябрьдә «Яшь армиячеләр, алга!» республика хәрби-спорт уенының һәм югары белем бирү һәм урта һөнәри белем бирү мәгариф оешмалары студентлары арасында спортның хәрби-тактик һәм экстремаль төрләре буенча республика спартакиадасының зона этаплары булып узды.

Бөек Ватан сугышы тарихын өйрәнүгә киң җәмәгатьчелекне җәлеп итү, тарих фәне буенча белемнәрне арттыру максатларында 3 сентябрьдә «Бердәм Россия» бөтенроссия сәяси партиясе иҗтимагый оешмалар белән берлектә «Җиңү диктанты» – Бөек Ватан сугышы вакыйгалары темасына халыкара тарихи диктант уздырды. Анда республиканың 9 меңнән артык укучысы катнашты.

Ноябрь аенда хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле яшүсмерләр арасында спортның хәрби-гамәли төрләре буенча республика спартакиадасы узды. Ярышлар

Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты белән берлектә «Патриот» яшьләрнең спорт-патриотик һәм хәрби хезмәткә алынганчы әзерлеге үзәгендә уздырылды.

«Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр формированиеләре республика үзәге тарафыннан «Үзебезнекеләр» проекты тормышка ашырыла, ул авыр тормыш шартларында калган яшь кешеләргә социаль яктан тотрыклылыкны үстерү һәм аларга аңлы рәвештә киләчәк тормышын сайларга ярдәм итү юлы белән хәзерге тормышын үзгәртүгә юнәлдерелгән. Проектта 40 муниципаль берәмлек катнаша, аларда 15 135 кеше җәлеп ителгән 1 163 җәмәгать тәртибен саклау буенча формирование эшләп килә.

Һәр ел саен балаларның палата лагерьларын оештыруны күздә тоткан республика җәйге профильле сменалар проекты эшләп килә, аның төп максаты – яшьләргә гражданлык-әхлакый тәрбиясе бирү, яшүсмерләрнең игътибарын тискәре мохиттән читкә юнәлтү. 2022 елда 8 «Яшь десантчы» хәрби-палата патриотик лагере (Апас, Минзәлә, Чистай, Биектау, Түбән Кама, Азнакай, Питрәч, Мамадыш муниципаль районнарында) ачылды.

Россиякүләм дәрәҗәдән халыкара дәрәҗәгә күчкән: «Җиңү хатлары», «Хәтер сандыгы», «Георгий лентасы», «Җиңү агачы», «Җиңү көне» флешмобы, «Җиңү вальсы», «Хәтер шәме» һәм башка чаралар традицион рәвештә уздырыла килә.

Республикада «Җиңү волонтерлары» бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан төбәк бүлекчәсе төзелде, аның төп бурычы – яшьләрне волонтерлык хәрәкәтендә катнашуга җәлеп итеп, аларда Бөек Ватан сугышында җиңүгә үзләреннән өлеш керткән дигән хис формалаштыру. Бүлекчә тарафыннан 2 590 чара оештырылды, алар арасында «Камалыштагы ипи» бөтенроссия акциясе, Ленинград шәһәрен камалыштан азат итүгә багышланган «Кино карау өчен тәнәфескә тукталу» бөтенроссия яшьләр фестивале кысаларында фильмнар күрсәтү, «КУРКЫНЫЧ. Ленинградның камалышка алу» республика интеллектуаль уены.

Республиканың гомуми белем бирү оешмаларында «Алга» республика хәрби-спорт уенын һәм «Ватанга хезмәт итәм! Халыкка хезмәт итәм!» метапредмет олимпиадасын үз эченә алган мәктәп укучыларына рухи-әхлакый һәм патриотик тәрбия бирү буенча еллык чаралар комплексы уздырыла.

Республикада «Яшь армиячеләр» хәрәкәте җирле бүлекчәләренең 49 штабы, 37 861 яшь армияче кергән 1 211 яшь армиячеләр отряды эшли. Муниципаль берәмлекләрдә Яшь армиячеләр йортларын төзү буенча юл карталары эшләнә.

Мәктәп укучылары махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм итү буенча төрле акцияләр һәм чараларда актив катнаша: «Солдатка видео-открытка», «Үзебезнекеләрне ташламыйбыз», «Яшь армияче посылкасы», «Бар шундый һөнәр – ул Ватанны саклау!», «Фронттан открытка», «Билгесез солдат көне», «Ватан Геройлары көне»

2023 елның башында «#Без бергә» проекты кысаларында Россия мәктәп укучылары хәрәкәтенең төбәк бүлекчәсе һәм Яшь армиячеләр хәрәкәте активистлары Луганск һәм Донецк халык республикасыннан күчеп килергә мәҗбүр булган кешеләргә гуманитар ярдәм җыюны оештырды.

**Яшьләр мәйданчыклары.**

«УРАМ» экстрим-паркы үзенең эшен дәвам итә. 2022 елда анда 850 мең кеше булды, 26 дисциплина буенча 32 ярыш уздырылды. Enter интернет-журналы оештырган «2022 елга йомгак: Шәһәр, кешеләр һәм командалар» бишенче еллык тавыш бирү йомгаклары буенча «УРАМ» яшьләр экстрим-паркы «Кластер года» номинациясендә җиңүче дип табылды, парк командасы «Ел командасы» номинациясендә җиңү яулады.

26 муниципаль берәмлектә 33 яшьләр үзәге эшләп килә.

Лаеш муниципаль районының капиталь төзекләндерүдән соң яңартылган «Орион» яшьләр үзәгендә 50 кешегә исәпләнгән лекторие булган коворкинг ачылды, анда йога, биюләр һәм башка төрле фитнес-тренировкалар уздыру өчен универсаль спорт залы, конференц-зал, универсаль остаханәләр, киберзал, тавыш яздыру студиясе һәм медиаүзәк бар.

Алабуга муниципаль районында «Барс» яшьләр үзәге ачылды, анда психолог кабинеты, коворкинг зонасы, күпфункцияле зал, күргәзмә мәйданчыгы, гамәли дәресләр алып бару бүлмәсе, тавыш яздыру студиясе, фотостудия, музыкаль бүлмә, актлар залы, грим салу бүлмәсе бар.

Профилактика эшендә психологик-педагогик ярдәм үзәкләре мөһим роль уйный. «Татарстан Республикасында психологик-педагогик ярдәм үзәкләре биналарын капиталь төзекләндерү (матди базасын ныгыту)» программасы кысаларында 304,9 млн сумга 3,5 мең кв метр мәйдандагы 15 бина төзекләндерелде.

Моннан тыш, 3 яшүсмерләр клубы төзекләндерелде.

Алексеевск муниципаль районының «Яшь армияче» яшьләр (яшүсмерләр) клубында капиталь төзекләндерүдән соң күпфункцияле зал, музей, ИТ-сыйныф, бию залы, картинг ачылды. Апас муниципаль районында – 360 кв. метрлы яңа «Алга» яшьләр (яшүсмерләр) клубы, анда егетләр көрәш белән шөгыльләнә алачак, альпинизм, туризм, робототехника һәм авиамодельләр төзү дәресләренә, ә кызлар флористика, кулинария һәм тегү курсларына йөри алачак.

**Балаларның ялын һәм сәламәтләндерүне оештыру.**

Төрле милек рәвешендә булган 1 523 сәламәтләндерү учреждениесендә 205 670 бала төрле формада ял һәм сәламәтләндерү чаралары оештырылды, шулардан 842 лагерь – көндезге (мәктәп яны), 122 шәһәр яны стационар сәламәтләндерү лагере, 493 лагерь – хезмәт һәм ялны оештыру, 49 палата лагере, 13 санаторий-курорт учреждениесе, 4 лагерь Кара диңгез яр буенда.

Җәйге сәламәтләндерү кампаниясе чорында 154 398 баланың ялы оештырылды, шулардан 192 шәһәр яны лагерендә 86 199 кеше, 1 335 көндезге лагерьда – 68 199 кеше ял итте. Палаталы типтагы 49 лагерьда 10 673 кеше ял итте. Кара диңгез яр буендагы «Черноморец» республика үзәгенең 4 балаларны сәламәтләндерү лагерында 5 215 кешенең ялы оештырылды. Махсуслаштырылган смена кысаларында сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле 700 бала ял итте.

Көзге каникул чорында мобилизацияләнгән гражданнарның 294 баласы балаларны сәламәтләндерү лагерында ял итте.

Луганск һәм Донецк халык республикаларыннан килгән 386 баланың сәламәтләндерү лагерында ялы оештырылды (психолог ярдәме, экскурсияләр, иҗади һәм спорт чаралары кергән ял итү программасы).

Барлык сәламәтләндерү лагерьлары үз эшенә тәрбия программасын кертте, ул флаг күтәрү тантанасы һәм дәүләт гимнын башкару, цифрлы гигиена һәм цифрлы тәрбия мохите, сәламәт яшәү рәвеше, шулай ук һөнәр сайлау һәм «Минем Татарстан» төбәк модульләрен һәм башка чараларны үз эченә ала.

2022 ел Россия Федерациясендә Халык сәнгате һәм мәдәни мирас һәм Татарстанда Цифрлаштыру елы дип игълан ителү белән бәйле рәвештә балаларны сәламәтләндерү лагерьларында тематик чаралар комплекслы оештырылды.

**Вакыйгалар һәм чаралар.**

2022 елда Казан шәһәре «Ислам хезмәттәшлеге оешмасы яшьләр башкаласы» статусын алды. Шәһәребезгә дөньяның 70 иленнән 1 000 гә якын катнашуы килде. Түбәндәге аеруча зур чаралар уздырылды:

Казан Глобаль яшьләр саммиты (дөньяның 67 иленнән 300 катнашучы);

V Глобаль Яшь дипломатлар форумы (дөньяның 45 иленнән 120 делегат);

VIII Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең Яшь эшкуарлары форумы (100 катнашучы);

Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең халыкара яшьләр фәнни конгрессы (100 делегат: 60 – Россия төбәкләреннән, 40 – Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләреннән);

Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең киберспорт буенча халыкара яшьләр чемпионаты (16 илдән 100 киберспортчы).

2022 ел дәвамында республикада яшьләр өчен бик күп вакыйгалар булып узды, түбәндәгеләр алар арасында иң зурлары булып санала:

XXII «Созвездие-Йолдызлык – 2022» республика ачык телевидение яшьләр эстрада сәнгате фестивале (60 меңнән артык катнашучы);

X «Наше время – Безнең заман» эшләүче яшьләр иҗатының еллык ачык республика телевидение фестивале (Татарстан Республикасының 187 предприятиесе һәм оешмасы катнашында);

«Әлбәдән» хәрби уеннары» бөтенроссия тарихи реконструкция фестивале (16,5 мең катнашучы);

«Сәләт» халыкара яшьләр мәгърифәти форумы (онлайн һәм офлайн форматларда 14 меңнән артык катнашучы);

«Ел студенты – 2022» югары белем бирү программалары буенча укучылар өчен республика премиясе (гала-концертта 900 тамашачы, номинацияләрдә 18 җиңүче);

«Ел казанышы – 2021» һөнәри белем бирү оешмаларында укучылар өчен республика премиясе (300 дән артык гариза, гала-концертта 1 000 тамашачы, 17 җиңүче);

COMBOnation брейк-данс һәм урам сәнгате буенча халыкара турнир (5 меңнән артык катнашучы һәм бөтен дөнья буенча 40 мең онлайн караучылар);

Республика Яшьләр көне (127 меңнән артык кеше);

«Город – RE’ACTOR» креатив индустрияләр буенча төрле жанрлар фестивале;

«УРАМ» урам сәнгате фестивале (50 меңнән артык катнашучы);

«Алга-Вперед» студентлар үзидарәләре бөтенроссия форумы (Россиянең 20 төбәгеннән 194 катнашучы);

«Хезмәт батырлыгы шәһәрләре» яшьләрнең бөтенроссия патриотик форумы;

II Игелек.Конференция;

II «Яшьләргә эш» республика яшьләр форумы (республиканың 24 муниципаль берәмлегеннән 600 катнашучы);

Халыкара төзелеш чемпионаты (27 илдән катнашулар).

XXX (I) «Россия студентлар язы» һөнәри белем бирү оешмалары бөтенроссия фестивале йомгаклары буенча республика гомуми исәптә 1 нче урын яулады.

«Актуаль миллилек» проект офисы үз эшен дәвам итә, аның кысаларында «Таба», республика «ЭтноСтартапФорум», «Таба» этномузыка фестивале милләтара проектлар яшьләр инкубаторы кебек проектлар тормышка ашырыла.

Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау һәм үстерүгә юнәлтелгән 13 яшьләр проекты эшли, алар гомуми суммасы 6,5 млн сумлык ярдәм алды.

2022 елда «Татарча диктант»та 31 чит ил дәүләтеннән һәм Россиянең 74 төбәгеннән 1,1 млн кеше катнашты.

Яшьләр эшләре федераль агентлыгы һәм федераль форум кампаниясе уздырган конкурслар йомгаклары буенча Татарстан яшьләре үз проектларын тормышка ашыруга 133,0 сум акча алды.

**Яшьләрне эшкә урнаштыру һәм аларның һөнәри яктан үз мөмкинлекләрен ачу.**

Яшьләр өчен эшкә урнашу һәм һөнәри яктан үз мөмкинлекләрен ачу гаять мөһим. «Яшьләргә – эш» автоматлаштырылган системасы ел әйләнәсендә студентларга вакытлыча эш табу мөмкинлеге бирә. 2022 елда портал ярдәмендә 3 меңнән артык кеше эш тапты. Студентлар хезмәт отрядларында, «Яшьләргә эш» порталын да кертеп, эшкә урнашкан яшьләрнең гомуми саны 11,8 мең тәшкил итә.

2022 ел йомгаклары буенча «Россия студентлар отрядлары» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсе Россиядә комиссарлык эшчәнлеген оештыру буенча 2 нче урын алды.

**Яшь гаиләләргә ярдәм.**

Дәүләт яшьләр сәясәтенең төп бурычы – яшь гаиләләргә ярдәм итү. Республикада яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуга бушлай субсидияләр, процентсыз өлешләп түләү, шулай ук социаль ипотека форматында дәүләт ярдәме күрсәтү программалары эшләп килә.

Татарстанның һәр районында яшь гаиләләргә шәхси торак сатып алуга уртак финанслау шартларында федераль бюджеттан республика бюджетына торак бәясенең 30– 35 % күләмендә бушлай субсидияләр бирү шартларында дәүләт ярдәме күрсәтү муниципаль программалары расланды һәм эшләп килә.

Әлеге программаны тормышка ашыру чорында (2006–2022 еллар) мондый субсидияләр 35 яшькә кадәрге 8 041 яшь гаиләгә бирелде (2022 елда – 20 муниципаль берәмлектән 50 яшь гаиләгә).

2022 елда 32 яшь гаиләгә торак сатып алу өчен процентсыз өлешләп түләү мөмкинлеге бирелде («Яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме турында» 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Законы кысаларында).

«Яшь гаилә» республика ташламалы ипотека программасын тормышка ашыру чорында 1 958 гаилә торак шартларын яхшыртты, шулардан 2022 елда – 1 010 яшь гаилә.

## МӘДӘНИЯТ

Республикада мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәте Татарстан Республикасының 2030 елга кадәр чорга мәдәниятне үстерү стратегиясе нигезендә алып барыла. Аның максаты – мәдәни үсеш өлкәсендә халыклар мәдәниятләренең гармонияле үсеше һәм алгарышы өчен шартлар тәэмин итәчәк, һәр шәхеснең һәм тулаем алганда җәмгыятьнең мәдәни һәм рухи потенциалын тормышка ашыруга этәргеч бирәчәк нәтиҗәле сәясәт формалаштыру.

Республикада барлыгы 3 811 мәдәният учреждениесе бар:

40 театраль-тамаша, шул исәптән 19 театр, 20 концерт оешмасы, 1 цирк;

1 508 китапханә (шулардан 1 298 – авылларда);

177 дәүләт һәм муниципаль музей челтәр берәмлеге;

1 896 мәдәни-ял итү учреждениесе, шул исәптән 75 күчмә мәдәният учреждениесе;

156 мәгариф оешмасы;

14 киноучреждение;

9 Халыклар дуслыгы йорты һәм 4 үзәк;

6 типик булмаган дәүләт мәдәният учреждениесе;

1 зоопарк.

**Театр-тамаша учреждениеләре.**

*Театрлар*

Республиканың дәүләт һәм муниципаль театрларында 111 премьера спектакле куелды, барлыгы 4 428 спектакль уйналды, шулардан 1 690 ы – балалар һәм яшүсмерләр өчен. Театрларга 1 378,85 мең тамашачы килде.

14 фестиваль уздырылды, 62 фестивальдә катнашу оештырылды.

Татарстан театрлары «Кече ватан мәдәнияте» федераль проектлары программасында 12 театр катнашты, шулардан 6 – дәүләт балалар театры («Театрлар – балаларга» проектында) һәм 2 муниципаль балалар театры («Түбән Кама шәһәренең Яшь тамашачы театры» муниципаль бюджет учреждениесе һәм «Зеленодольск музыкаль театры» муниципаль бюджет учреждениесе – «Кече шәһәрләр театрлары» проектында).

2022 елда Казан дәүләт яшь тамашачылар театры үзенең 90 еллык юбилеен билгеләп үтте. Юбилей декадасы кысаларында беренче тапкыр «Мин – Казан яшь тамашачылар театры» тамашачыларыннан проектлар питчингы уздырылды. Автор белән берлектә язылган иң яхшы проект 2023 елда дәүләт театры сәхнәсендә куелачак.

«Казан театр училищесы» (техникумы) дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең 100 еллыгы елның мөһим вакыйгаларыннан берсе булып тора.

Иң күренекле театраль чаралар:

Муса Җәлил исемендәге татар академия дәүләт опера һәм балет театрында Ф.И. Шаляпин исемендәге XXXX халыкара опера фестивале (2022 елның 30 гыйнварыннан 22 февраленә кадәр);

Муса Җәлил исемендәге татар академия дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә Рудольф Нуриев исемендәге XXXV халыкара классик балет фестивале (2022 елның 13–31 мае);

Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында VII «Нәүрүз» халыкара театраль-мәгърифәти форум (2022 елның 21–28 июне);

IV «Шомбай-fest» халыкара курчак театрлары фестивале;

Мәскәү шәһәрендә XXVIII «Алтын битлек» фестивале конкурс программасы кысаларында Г.Ибраһимовның «Адәмнәр» спектакле (2022 елның 30–31 марты);

Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә дәүләт татар драма театрында I «ЛӘКЛӘК» бөтенроссия балалар театрлары фестивале (30 ноябрьдән 2 декабрьгә кадәр).

Республикада 12 хосусый театр эшләп килә. 2022 елда аларга килгән тамашачыларның саны 51,1 мең кеше тәшкил итте.

**Концерт оешмалары.**

Концертларны 1 637,5 мең кеше тамаша кылды.

Ел дәвамында концерт оешмалары республика муниципаль берәмлекләренә күчмә гастрольләр белән чыкты. Дәүләт һәм муниципаль концерт оешмалары тарафыннан 389 яңа концерт программасы әзерләнде, 2 025 концерт оештырылды.

2022 елда Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбле үзенең 85 еллыгын билгеләп үтте, ул иң югары һөнәри дәрәҗәдә татар халкының музыкаль, бию, гамәли сәнгатен күрсәтү аша милли гореф-гадәтләрне саклаучы булып тора.

Россия джазының 100 еллыгын билгеләп үтү уңаеннан зур масштаблы «Калининградтан алып Сахалинга кадәр» гала-концертлары сериясе кысаларында Казан шәһәренең «Пирамида» концертлар комплексында уздырылган концерт төп вакыйгаларның берсе булды.

Концерт оешмаларының иң күренекле чаралары түбәндәгеләр:

күренекле татар композиторлары – Мансур Мозаффаров һәм Рәшит Кәлимуллиннарның юбилейлары, шулай ук Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан уздырылган Нәҗип Җиһанов исемендәге «Мирас» VII татар музыкасы фестивале;

А.Сладковский җитәкчелегендәге Татарстан Республикасы Дәүләт академия симфоник оркестры Мәскәү шәһәрендә Халыкара музыка фестивале ачылышында чыгыш ясады, ул Россиянең күренекле дирижеры һәм композиторы Валерий Хәлиловка багышланган иде;

Татарстанның беренче оркестры баш дирижеры, СССР халык артисты Н.Г. Рахлин истәлегенә багышланган «Рахлин сезоннары» XI халыкара фестивале;

Сергей Рахманинов исемендәге «Ак канәфер» XI халыкара фестивале;

«Халык көйләре» VIII бөтенроссия фестивале;

«Джаз-КроссоверФест-Казан» VI халыкара фестивале;

«Тылдагы батырлык» төбәкара патриотлык марафоны;

TATAR CYЗE II татар телендә әдәби әсәрләрне сәнгатьле укучыларның халыкара конкурсы.

*Цирклар эшчәнлеге*

Казан шәһәрендә циркка 219,7 мең тамашачы килде. Цирк мәйданында 9 программа күрсәтелде, барлыгы 136 тамаша куелды.

1996 елдан  Казан дәүләт циркының балалар цирк мәктәбе эшләп килә, анда акробатика, жонглерлык итү, эквилибристика, хореография, актерлык осталыгы, цирк тарихы дәресләре укытыла. 2022 елда 150 укучы белем алды.

Цирк репертуарына цирк сәнгатенең эксперименталь төрләре дә кертелде: «Цирк мюзиклы» һәм «Клоуннар спектакле». Беренче тапкыр цирк хезмәткәрләре тарафыннан республиканың иҗади һәм спорт коллективлары белән берлектә мөстәкыйль  спектакль буларак  яңа ел цирк әкияте куелды.

**Музей эше.**

Музейлар челтәренә 177 дәүләт һәм муниципаль музей берәмлеге керә, шул исәптән 70 структур бүлекчәдән торган 13 дәүләт музее һәм 107 структур бүлекчәдән торган 50 муниципаль музей.

Республика музейларында 118,9 мең экскурсия, 3 854 массакүләм һәм 18,7 мең мәдәни-мәгърифәти чара, 3 089 күргәзмә, шәхси фондлардан 1 612 күргәзмә оештырылды. 2022 елда музей учреждениеләренә килүчеләр саны 8,6 млн кеше тәшкил итте.

Татарстан Республикасы дәүләт музейлары һәм музей-тыюлыклары тарафыннан 899 күргәзмә проект оештырылды, шулардан Россия Федерациясенең башка төбәкләренә 69 күргәзмә проект, Россия Федерациясенең башка төбәкләренә 69 күргәзмә проект алып барып күрсәтелде.

ARTEFACT платформасында Татарстан Республикасы Милли музее, Татарстан Республикасының Дәүләт сынлы сәнгать музее, «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгының экспозицияләре һәм күргәзмә проектлары буенча 3 мультимедиа-гид булдырылды.

**Китапханәләр.**

Республикада халыкка хезмәт күрсәтүче 1 508 китапханә исәпләнә, шул исәптән 4 республика («Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе, «Республика яшүсмерләр китапханәсе», «Роберт Миңнуллин исемендәге Республика балалар китапханәсе», «Республика сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен махсус китапханә» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениеләре) һәм 1 504 муниципаль китапханә, шулардан 1 298 е авыл җирлекләрендә урнашкан.

Татарстан Республикасының җыелма электрон китапханә каталогына 59 мең библиографик язмалар кертелде. Барлыгы каталогка 1,07 млн библиографик язмалар кертелде.

«Татарстан Республикасының Электрон милли китапханәсе»  порталында (kitap.tatar.ru) «Электрон коллекцияләр» бүлегендә 11 988  тулы текстлы документлар урнаштырылды, шулардан 7 632 – «Татарика», Матур әдәбият коллекцияләренә багышланган, аларда рус һәм татар телләрендә Татарстанның мәдәнияте, тарихы, әдәбияты, сәнгате турында мәгълүмат бирелгән.

Гомуми кулланылыштагы китапханәләрнең  җыелма фонды 23,5 млн нөсхәдән тора.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе «Цифрлы нигезгә корылган мәдәният» төбәк проектын тормышка ашыру кысаларында кульязма һәм басма китаплар дип танылган документларны цифрлаштыру эшен дәвам итә. «Кульязма

һәм басма китаплар» коллекциясенә 1 000 электрон документ кертә, фондларны цифрлаштыру барышында 33 мең нөсхә электрон документ булдырылды.

Китапханә хезмәтләреннән 1,9 млн куллану файдаланды.

**Киноучреждениеләр.**

Республиканың кино челтәренә 14 кино учреждениесе, 175 кино күрсәтү урыны, шул исәптән 1 дәүләт кинотеатры («Мир» кинотеатры), 7 муниципаль кинотеатрда 8 кино залы, мәдәни-күңел ачу учреждениеләрендә 43 муниципаль кино залы; 25 – коммерциячел кинотеатр, 27 – күчмә кино күрсәтү урыны керә.

Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы һәм Кино фонды проекты буенча 100 меңнән алып 500 меңгә кадәр кеше яшәүче торак пунктларда милли фильмнар күрсәтү өчен шартлар булдыру максатларында муниципаль берәмлекләрдәге 30 кино залына яңа цифрлы җиһазлар куелды. 2022 елда муниципаль районнарда 33 цифрлы кинотеатр һәм кино залы эшләде.

Туган телне үстерү программасын гамәлгә ашыру кысаларында «Татаркино» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе Әмирхан Еникинең «Кем җырлады», «Бер генә сәгатькә», «Матурлык» әсәрләре буенча «843 км» фильмын төшерде.

XVIII Казан халыкара мөселман киносы фестивалендә «Тарлан» кинофильмы (Татарстан Республикасы һәм Казахстан Республикасы) тамашачылар мәхәббәтен яулады.

«Татаркино» фондында Татарстан Республикасы үсеше тарихы белән бәйле 106 цифрлаштырылган документаль фильм, һәм Татарстан кинематографиячеләре тарафыннан төшерелгән 42 уен фильмы саклана.

Кинотеатрларны һәм киноучреждениеләргә 2,9 млн кеше килде.

**Мәдәни-ял итү учреждениеләре.**

Мәдәният учреждениеләренең иң зур өлеше булып мәдәният йортлары тора, алар, шул исәптән авыл җирлекләрендә дә, турыдан-туры халык өчен мәдәни чаралар уздыру урыны булып хезмәт итә.

Мәдәни-ял итү учреждениеләре 1 828 бинада (авыл җирлекләрендә – 1731) урнашкан, шуларның 711 е – терәк-хәрәкәтләнү аппараты зарарланган затлар, 10 – күрү сәләте начар булган затлар, 9 – ишетү сәләте начар булган затлар өчен.

Мәдәни-ял итү учреждениеләрендә 15 804 клуб формированиесе эшли (209 311 кеше катнашында), шул исәптән 1 465 инклюзив клуб формированиесе (17 739 кеше катнашында).

**Матди булмаган мәдәни мирас.**

Татарстан закон чыгару башлангычы белән чыкты, аның нигезендә «Россия Федерациясенең матди булмаган этномәдәни мирасы» 2022 елның 20 октябрендәге 402-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителде, ул этник берәмлекләрнең үз мәдәни-милли үзенчәлекләрен саклауга хокукларын тормышка ашыру өчен матди булмаган этномәдәни мирасын ачыклау, өйрәнү, алардан файдалану, саклау һәм популярлаштыру өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2022 елның 31 декабренә Россия Федерациясенең матди булмаган этномәдәни мирасы объектлары реестрына Идел буе федераль округында урнашкан 30 объект, шул исәптән Татарстан Республикасының 4 объекты кертелде. Әлеге реестр нигезендә формалаштырылган халык мәдәнияте антологиясенә республиканың 3 объекты кертелде. «Россия бәйрәмнәре» бүлегенә

«Дини бәйрәмнәр һәм алар белән бергә уздырыла торган Казан аръягы рус авылларындагы кичке әйлән-бәйләннәр. Каравон» объекты керә, «Россия халыкларының традицион һөнәрләре технологияләре» бүлегенә – «Казан җөе» күн тегү буенча традицион татар техникасы» объекты, «Традицион һөнәрләр технологияләре. Традицион текстиль» бүлегенә – «Рус Никольское авылында традицион костюм» объекты керә.

«Татарстан Республикасы мәдәният өлкәсенә инновацияләр кертү һәм традицияләрне саклау ресурс үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан матди булмаган мәдәни мирас объектларына уздырылган мониторинг йомгаклары буенча республикада теркәлгән объектларның гомуми саны 182 берәмлек, шулардан 86 объект учреждениесе сайтында «Матди булмаган мирас объектлары» бүлегендә урнаштырылган.

**Мәдәният өлкәсендә белем бирү.**

Республикада мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә белем бирү буенча 156 мәгариф оешмасы эшләп килә: 105 балалар сәнгать мәктәбе һәм мәдәният идарәләре органнары карамагындагы 2 балалар үзәге, мәгариф идарәләре органнары карамагындагы 38 балалар сәнгать мәктәбе, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге 9 һөнәри белем бирү оешмасы (көллиятләр), 2 югары белем бирү мәгариф оешмасы.

Әлеге оешмаларда 42 883 укучы белем ала, шулардан 37 762 бала – балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында, 2 450 бала – һөнәри белем бирү оешмаларында (көллиятләрдә), 2 671 укучы – югары белем бирү мәгариф оешмаларында. Укытучылар составы 3 659 кешедән тора, шулардан өстәмә белем бирү оешмаларында 2 876 укытучы һәм концертмейстер, һөнәри белем бирү оешмаларында 418 укытучы, 365 кеше югары уку йортларының профессор-укытучылар составына керә.

Конкурслар һәм фестивальләр сәләтле балаларны һәм яшүсмерләрне ачыклауның бер рәвеше булып тора, аларда балалар сәнгать мәктәпләрендә белем алучылар бик актив катнаша. Балалар сәнгать мәктәпләрендә 27 216 кеше катнашында 10 665 иҗади чара булып узды.

**«Мәдәният» илкүләм проекты.**

«Мәдәният» илкүләм проекты максатларына ирешү өчен «Мәдәни мохит», «Иҗади кешеләр» һәм «Цифрлы нигезгә корылган мәдәният» төбәк проектлары тормышка ашырылды. Аларга 1 157,4 млн сум акча бүлеп бирелде, шул исәптән 700,3 млн сум – федераль бюджеттан, 457,1 млн сум – Татарстан Республикасы бюджетыннан.

«Мәдәни мохит» төбәк проекты кысаларында 2022 елда:

Арча, Баулы һәм Зеленодольск муниципаль районнарында 3 авыл мәдәният йорты, Чүпрәле муниципаль районында күпфукцияле үзәк һәм Мамадыш муниципаль районында мәдәни-күңел ачу үзәге төзелде;

Кукмара муниципаль районының Байлангар һәм Ядегәр авылларындагы 2 мәдәният йорты капиталь төзекләндерелде;

Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәрендә урнашкан «Г.Р. Державини Лаеш туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе төзекләндерелде;

Арча муниципаль районының Арча шәһәрендә урнашкан «Арча балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе капиталь төзекләндерелде;

«Түбән Кама шәһәренең яшь тамашачылар театры» муниципаль бюджет учреждениесендә реконструкция эшләре тәгәлләнде;

Алабуга һәм Зеленодольск шәһәрләрендә мәдәни үсеш үзәкләре төзелде;

Буа муниципаль районының Буа шәһәрендә «Район мәдәният йорты» муниципаль мәдәният учреждениесендә реконструкция эшләре башланды;

5 модельле муниципаль китапханәләр:

«Теләче муниципаль районының авылара китапханәсе» муниципаль бюджет учреждениесенең 14 номерлы филиалы – Иске Җөри авылы китапханәсе;

Чистай муниципаль районының «Чистай муниципаль районының авылара китапханәсе» муниципаль бюджет учреждениесенең 16 номерлы филиалы –Кубас авылы китапханәсе;

Апас муниципаль районының «Үзәкләштерелгән китапханә системсы» муниципаль бюджет учреждениесенең Үзәк китапханәсе;

Актаныш муниципаль районының «Актаныш авылара үзәк китапханәсе» муниципаль бюджет учреждениесе Үзәк китапханәсе;

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесе Г.Тукай исемендәге Үзәк балалар китапханәсе.

Мәдәният өлкәсендә 14 мәгариф учреждениесенә музыка уен кораллары, җиһазлар һәм уку-укыту материаллары сатып алынды (сәнгать төрләре буенча балалар сәнгать мәктәпләре һәм училищелар).

«Иҗади кешеләр» төбәк проектын тормышка ашыру кысаларында:

мәдәният һәм кинематография өлкәсендә чаралар уздырылды (Казан шәһәрендә XXXX Ф.И. Шаляпин исемендәге опера фестивале, XXXV Рудольф Нуриев исемендәге халыкара классик балет фестивале, XVI «Нәүрүз» төрки халыкларның халыкара театр фестивале);

иң яхшы муниципаль мәдәният учреждениесе һәм иң яхшы муниципаль мәдәният учреждениесе хезмәткәрләренә дәүләт ярдәме күрсәтелде;

мәдәният өлкәсендә иҗади һәм идарәче кадрларга өзлексез белем бирү һәм аларның квалификацияләрен күтәрү үзәкләре базасында 1 204 белгеч квалификация күтәрү курсларын узды;

үзешчән иҗат коллективларына грантлар бирелде.

«Цифрлы нигезгә корылган мәдәният» төбәк проекты кысаларында 3 виртуаль концерт уздырылды, алар түбәндәге биналарда уздырылды:

«Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесе үзәк китапханәсе;

«Түбән Кама шәһәренең үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесе Габдулла Тукай исемендәге үзәк китапханәсе;

«Буаның 1 номерлы балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе.

Республиканың барлык мәдәният учреждениеләре «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтлары бар. Цифрлы форматта концертлар һәм спектакльләр, күргәзмәләр һәм экскурсияләр, иҗади очрашулар һәм осталык дәресләре, лекторийлар һәм флэшмоблар урнаштырыла, шулай ук киң җәмәгатьчелектә кызыксыну тудыра торган кызыклы формаларда онлайн-чаралар уздырыла.

**Мәдәният өлкәсенә грант ярдәме.**

2022 елда мәдәният өлкәсендә түбәндәге Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары каралган:

мәдәният һәм сәнгать муниципаль учреждениеләре иҗат коллективлары проектларына ярдәм итүгә (гомуми суммасы 11,5 млн сумга 65 җиңүче);

мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләре хезмәткәрләренә ярдәм итүгә (гомуми суммасы 5,0 млн сумга 12 җиңүче);

шәһәр татар һәм рус мәдәни-ял итү мохитен булдыруга грант (гомуми суммасы 400,0 мең сумга 5 җиңүче);

дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә квалификацияләрен күтәрү, тәҗрибә алмашу чараларында катнашуга ярдәм итүгә (гомуми суммасы 3,0 млн сумга 53 җиңүче);

иң яхшы дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренә ярдәм итүгә (гомуми суммасы 4,0 млн сумга 6 җиңүче);

татар халкының мәдәниятен саклаучы, үстерүче һәм популярлаштыручы әсәрләр язуга (гомуми суммасы 9,8 млн сумга 48 җиңүче);

Татарстан Республикасындагы иҗтимагый оешмаларга һәм Россия Федерациясе төбәкләрендә гореф-гадәтләрне саклауга һәм милли мәдәниятне үстерүгә, этномәдәни һәм телләр күптөрлелеген саклауга, мәдәниятне һәм сәнгатьне үстерүгә булышлык итүгә (гомуми суммасы 9,6 млн сумга 18 җиңүче).

Авыл җирлекләренең иң яхшы муниципаль мәдәният учреждениеләренә һәм аларның хезмәткәрләренә акчалата бүләк (хезмәткәрләр арасыннан гомуми суммасы 3,6 млн сумга 72 җиңүче һәм учреждениеләр арасыннан гомуми суммасы 8,0 млн сумга 80 җиңүче).

**«Пушкин картасы» программасын гамәлгә ашыру.**

Балаларны һәм яшьләрне мәдәният һәм сәнгатьне өйрәнүгә, Россия һәм дөнья мәдәнияте кыйммәтләре белән танышуга җәлеп итү, үсеп килүче буынны мәдәният өлкәсендә белемнәрен үстерү максатларында 2021 елның 1 сентябреннән 14 яшьтән 22 яшькә кадәрле яшүсмерләргә мәдәният оешмалары хезмәтләреннән файдалана алуын арттыру өчен «Пушкин картасы» социаль ярдәм программасы гамәлгә ашырыла. 2022 елның 1 гыйнварыннан «Пушкин картасы» номиналы елына 3 меңнән 5 меңгә кадәр артты.

Татарстанда «Пушкин картасы» программасыннан 337 мең кеше файдалана, шулардан Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы мәгълүматлары буенча 2022 елның 31 декабренә – 230,1 мең кеше «Пушкин картасы»н «Мәдәният өлкәсендә дәүләт хезмәтләре» мобиль кушымтасында куллана.

«Пушкин картасы» федераль проекты кысаларында республикада төрле юнәлештәге осталык дәресләре: вокал, хореография, халык һөнәрчелеге, актерлык

осталыгы буенча; төрле эшчәнлек өлкәләре вәкилләре белән тематика очрашулар (мәдәният, медицина, сак һәм хокук тәртибе органнары) уздырылды.

**2022 елның иң үзенчәлекле һәм кызыклы проектлары.**

450 дән артык мәдәни, мәгърифәти, белем бирү, фәнни-тикшеренү чарасы булып узды.

Россиядә игълан ителгән Халыкларның мәдәни мирасы елы кысларында ел дәвамында республиканың барлык муниципаль берәмлекләрендә Россия халыкларының мәдәни мирасына багышланган иҗади һәм мәгърифәти проектлар, мәдәни-массакүләм, иҗтимагый һәм социаль әһәмияткә ия чаралар уздырылды. Татарстан халыклары мәдәни мирасын өйрәнү, Россия территориясендә яшәүче халыкларның телләре һәм әдәбиятлары белән танышу һәм аларны популярлаштыру, төрле халыкларны милли мәдәниятләре, тарихы һәм гореф-гадәтләре, милли бәйрәмнәре турында белемнәрне саклау һәм популярлаштыру эшләрен фәнни-методик яктан тәэмин итү өчен шартлар булдыру максатларында 9 меңнән артык чара булып узды.

Идел буе Болгар дәүләрендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышлаган чаралар кысаларында Казан шәһәрендә җәмигъ мәчете нигезенә таш салу һәм «Изге Болгар җыены» бәйрәм тантаналары булып узды.

Елның иң мөһим вакыйгалары булып Россиянең әйдәүче музейлары белән берлектә оештырылган «Идел буе Болгар дәүләте. Бөек мирас», «Иман нуры», «Шамаил-арт», «Ислам на снегу» бөтенроссия күргәзмә проектлары.

Россиянең 14 шәһәрендә тулы бер музей туры булып Алабуга музей-тыюлыгының «Татарларда кунакта» күргәзмәсе булды.

12–13 августта Спас муниципаль районының Болгар шәһәрендә К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры «Яңарыш» фонды белән берлектә ачык һавада 3 D mapping технологияләрен кулланып, «Кара пулат» операсын куелды. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең «Болгар дәүләте эзләре буйлап» дигән гастроль туры Россия шәһәрләрендә аерым уңыш казанды. «Тархан» телевидение конкурсы иң яхшы мәгариф проекты булып тора, биредә яшь талантлар тарих, мәдәният, Татарстанда басылып чыккан китаплар турында белемнәр алышты.

Россия Федерациясендә Чечня мәдәнияте көннәре, Беларусь Республикасы көннәре, Казахстан Республикасы көннәре булып узды. Ел дәвамында Саха (Якутия) Республикасында, Мәскәү шәһәрендә һәм Баку шәһәрендә (Азәрбайҗан Республикасы) Татарстан Республикасы көннәре оештырылды.

Россиянең күпмилләтле мәдәниятенең үзенчәлекле гәүдәләнеше булган халык бәйрәмнәрен һәм фестивальләрен саклауга һәм популярлаштыруга аерым игътибар бирелә. Күп еллар дәвамында республикада аның территориясендә яшәүче халыкларның йолалар һәм гореф-гадәтләрен саклауга ярдәм итүче Татарстан халыкларының милли бәйрәмнәре: Сабантуй, Нәүрүз, «Каравон» төбәкара рус фольклор бәйрәме, «Балтай» һәм «Валда Шинясь» мордва мәдәнияте бәйрәмнәре, «Троица» рус фольклор бәйрәме, «Семык» мари халык бәйрәме, «Уяв» чуваш милли халык бәйрәме, «Иван Купала» славян мәдәнияте бәйрәме, «Гырон Быдтон» удмурт мәдәнияте бәйрәме, «Питрау» керәшен мәдәнияте бәйрәме уздырыла.

2022 елда 337 сабантуй, шул исәптән 277 – Россия Федерациясенең 48 төбәгендә, 60 – чит илдә. Ульяновск шәһәрендә уздырылган XXII Федераль Сабантуй, Новокузнецктагы II Халыкара шахтерлар Сабантуе, Мордовия Республикасының Аксеново авылында булган XII Бөтенроссия авыл Сабантуе Россия Федерациясе төбәкләрендә төп бәйрәмнәр булып тора.

Милләттәшләребезнең иҗади активлыгын үстерүгә халыкара һәм төбәкара конкурслар, Түгәрәк уен Бөтенроссия татар фольклоры фестивале, «Идел-йорт» төбәкара театр коллективлары фестивале, Татар моңы яшь башкаручыларның халыкара телевидение конкурсы, Р.Ваһапов исемендәге халыкара татар җыры фестивале, «Татар кызы» бөтенроссия конкурсы, Сөйкемле Шүрәле бөтенроссия иҗат эшләре конкурсы кебек мәдәни проектлар ярдәм итә.

## КОММЕРЦИЯЧЕЛ БУЛМАГАН ОЕШМАЛАРГА ЯРДӘМ ИТҮ ИНФРАСТРУКТУРАСЫН ҮСТЕРҮ

Граждан җәмгыяте институтлары белән актив хезмәттәшлек алып барыла. Идел буе федераль округында теркәлгән коммерциячел булмаган оешмалар (алга таба – КБО) саны ягыннан республика алдынгы урыннарның берсен алып тора. 2023 елның 1 гыйнварына республикада 6 060 КБО, шул исәптән 1 697 иҗтимагый оешма, 2 106 дини берләшмә, 2 235 коммерциячел булмаган башка оешмалар, шулай ук сәяси партияләрнең 22 төбәк бүлекчәсе теркәлгән.

Татарстанда «Татарстан Республикасының 2014–2025 елларга икътисадый үсеше һәм инновация икътисады» дәүләт программасының 2014–2025 елларга Татарстан Республикасы социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга (алга таба – СЮКБО) ярдәм буенча ярдәмче программасы (алга таба – Ярдәмче программа) гамәлдә. Аның максаты – Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешендә катнашуга СЮКБОга этәргеч бирү, иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкны һәм милләтләр арасындагы татулыкны саклау, социаль сәясәтнең нәтиҗәлелеген арттыру һәм халыкка социаль ярдәм күрсәтүнең сыйфатын яхшырту, дәүләт һәм иҗтимагый мәнфәгатьләрнең балансланган булуы нигезендә иҗтимагый иминлеккә ирешү. Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 3,96 млрд сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән – 3,39 млрд сум, федераль бюджет акчалары исәбеннән – 42,2 млн сум, җирле бюджетлардан – 11,2 млн сум һәм бюджеттан тыш чыганаклардан – 497,8 млн сум. 2022 елда Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 362,7 млн сум тәшкил итте.

КБОга грантлар бирүгә конкурслар уздыру буенча бердәм грант операторы итеп «Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм итү буенча республика ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы билгеләнде (Татарстан Республикасы Президентының «Граждан җәмгыятен үстерүгә бирелә торган Татарстан Республикасы грантлары турында» 2021 елның 29 декабрендәге ПУ-1002 номерлы указы). 2022 елда гомуми фонды 106,6 млн сум күләмендә, шулардан 53,3 млн сум – Президент грантларыннан уртак финанслау, 53,3 млн сум – Татарстан Республикасы бюджетыннан беренче конкурс уздырылды. Грантларны 19 юнәлеш буенча 230 СЮКБО алды, шулардан 18 СЮКБО Россия Федерациясе субъектларыннан.

Республикада КБОларның муниципальара ресурс үзәкләре эшли, алар Ярдәмче программа акчалары ярдәмендә укыту, консалтинг һәм КБОлар эшчәнлегенә хезмәт күрсәтүне тормышка ашыра. КБОларның муниципальара ресурс үзәкләре Казан («Инновацияле үсеш һәм технологияләрне трансферлау» автоном коммерциячел булмаган оешмасы), Әлмәт («Вертикаль» социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы), Чаллы («Горизонт» социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы), Кукмара («Вектор» социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы), Буа («Буа Грант» социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның ресурс

үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы), Чистай («Бердәмлек» социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы) шәһәрләрендә урнашкан.

Ел дәвамында әлеге үзәкләр 994 консультация һәм 197 семинар уздырды, шулар арасында «КБО мәктәбе: А дан Я га кадәр», «Мәдәни башлангычларга Президент грантларга фонды конкурсына гаризалар формалаштыру методологиясе», «Президент грантларга фонды конкурсына гаризалар формалаштыру методологиясе», «КБО бухгалтерлык исәбе һәм салым түләүнең актуаль мәсьәләләре», «КБО проект эше: төп фикердән ярдәм итү чараларына кадәр», «Социаль проектлар ясау һәм социаль проектларга идарә», «КБОның ярдәм итү үзәкләре буйлап сәяхәте», шулай ук КБОдан конкурсларда катнашуга 575 гариза кабул ителде. 2022 елда аларның ярдәме белән 38 СЮКБО төзелде.

9 халыклар дуслыгы йорты (Казан, Чаллы, Азнакай, Лениногорск, Менделеевск, Түбән Кама, Нурлат, Тәтеш һәм Буа шәһәрләрендә) һәм Татарстан халыклары ассамблеясе ресурс үзәкләре булып торган 4 халыклар дуслыгы йорты үзәге КБОларга этномәдәни һәм конфессияара хезмәттәшлек алып баруда ресурс үзәкләре булып тора. 4 муниципаль районда район мәдәният йортларының структур бүлекчәләре буларак халыклар дуслыгы үзәкләре эшләп килә (Апас, Чүпрәле, Яңа Чишмә һәм Спас муниципаль районнары).

Гражданлык инициативаларын хуплау һәм республикада граждан җәмгыяте институтларын формалаштыруга ярдәм итү максатларында Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә керткән өлеше өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен гамәлгә кую турында» 2015 елның 3 июлендәге ПУ-619 номерлы Указы гамәлгә ашырыла. 2022 елда әлеге премияне дәгъвалауга үткәрелгән конкурс нәтиҗәләре буенча (гомуми приз фонды – 2,75 млн сум) 8 премия бирелде:

Татарстан Республикасының «Созвездие-Йолдызлык» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы генераль директоры Д.А. Тумановка;

«Донор-Сёрч» донорлыкны үстерү коммерциячел булмаган партнёрлыгы ассоциациясе директоры Р.П. Шекуровка;

«В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты (Икътисад, идарә һәм хокук институты)» югары белем бирү хосусый мәгариф учреждениесе ректоры А.В. Тимирясовага;

«Россия студентлар отрядлары» бөтенроссия яшьләр иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсенә;

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Әфганстандагы һәм Төньяк Кавказдагы сугыш хәрәкәтләре ветераннарының җирле иҗтимагый оешмасына;

«Татарстан Республикасы балалар оешмалары советы» төбәк иҗтимагый оешмасына;

«АЛЬПАРИ» хәйрия фондына;

«Татарстан энҗесе» инвалидларга ярдәм итү төбәк иҗтимагый оешмасына.

2015 елдан лауреат исеменә Татарстан Республикасының 21 күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм 34 КБО лаек булды.

Социаль хезмәт күрсәтүчеләр реестрында 26 дәүләтнеке булмаган оешма, шул исәптән:

өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтүче 17 оешма, 11 СЮКБОны да кертеп;

мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләргә һәм авыр тормыш хәлендә калган балаларга социаль хезмәтләр күрсәтүче 9 оешма, 6 СЮКБОны да кертеп.

2022 елда социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмаларның гомуми санында дәүләтнеке булмаган оешмаларның өлеше 18,4 процент тәшкил итте (2021 елда – 18,4 %, 2020 елда – 18,2 %). Дәүләтнеке булмаган оешмалар тарафыннан 12 309 кешегә хезмәт күрсәтелде (2021 елда – 12 573 кеше, 2020 елда – 10 524 кеше).

Гражданнарны граждан җәмгыятен үстерүгә җәлеп итү эше КБОларның Татарстан Республикасы ведомстволары һәм муниципаль иҗтимагый советларындагы, территориаль иҗтимагый үзидарә органнарындагы вәкиллекләре аша алып барыла.

Территориаль иҗтимагый үзидарәләре гражданнарны территориядә булган мәсьәләләрне хәл итүгә җәлеп итү ресурсы буларак республиканың күп кенә муниципаль берәмлекләрендә актив кулланыла.

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан җирле үзидарә органнарына муниципаль берәмлекләр территорияләрендә СЮКБОларга ярдәм итү чараларын эшләү һәм үтәүдә методологик ярдәм күрсәтү максатларында СЮКБОлар белән хезмәттәшлекне көчәйтү, шулай ук алар эшчәнлегенең нәтиҗәле технологияләрен һәм ысулларын куллану буенча методик тәкъдимнәр эшләнде.

СЮКБОларның социаль әһәмияткә ия проектларны тормышка ашыру буенча эшчәнлеген республика массакүләм мәгълүмат чараларында киң яктыртуны үз эченә алган мәгълүмати ярдәмгә зур роль бирелә. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – Татмедиа), шулай ук СЮКБОларга ярдәм итү буенча ресурс үзәкләре тарафыннан СЮКБОлар эшчәнлеген пропагандалау һәм популярлаштыру буенча эш алып барыла.

Татмедиа КБОларга әһәмиятле социаль гуманитар проектларны тормышка ашыруда, шулай ук ирекләләр хәрәкәте һәм хәйриячелек эшчәнлеге идеяләрен формалаштыруда мәгълүмати ярдәм күрсәтә.

2016 елдан башлап Татмедиа Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы ярдәме белән СЮКБО эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген яктырткан иң яхшы массакүләм мәгълүмат чаралары билгеләү буенча конкурс үткәрү турында» 2016 елның 2 декабрендәге 885 номерлы карары нигезендә) үткәрелә. Конкурста ММЧ редакцияләре, аерым авторлар, авторлар коллективлары һәм төркемнәре, шулай ук башка юридик затлар, шул исәптән СЮКБОлар да катнаша ала. 2022 елда конкурс 4 номинация буенча уздырылды: «Басма массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы мәкалә», «Иң яхшы телевидение сюжеты һәм тапшыруы», «Иң яхшы радио сюжеты яисә радио тапшыруы», «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә СЮКБОлар эшчәнлеген яктырту буенча иң яхшы язма». 12 массакүләм мәгълүмат чаралары авторы җиңүче булды. Конкурсның гомуми приз фонды – 400 мең сум.

Һәр елны республиканың КБОлары Россия Федерациясе Президенты грантларын бирү буенча конкурсларда катнаша. 2022 елда Татарстан Республикасының 99 СЮКБО проекты җиңүче дип танылды, грантларның гомуми суммасы 192,3 млн сум тәшкил итте.

КБОларга ярдәм итү максатында республикада махсус портал булдырылды, анда коммерциячел булмаган оешмалар интернетта бушлай үз сәхифәләрен булдыра ала (http://www.nkort.ru/), бу киләчәктә СЮКБОларның имиджын үстерергә, аларны медиа-киңлектә тагын да танытуга этәргеч бирәчәк. Порталда КБОлар өчен кирәкле барлык мәгълүмат: норматив хокукый база, республика һәм шулай ук федераль конкурсларны уздыру, социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыру йомгаклары, СЮКБОларга ярдәм итү буенча муниципальара ресурс үзәкләре эшчәнлеге, муниципальара ресурс үзәкләре тарафыннан эшләнә торган мәгълүмати-методик материаллар урнаштырыла.

СЮКБОларга конкурслар һәм грантлар турында бер тәрәзә режимында мәгълүмат эзләүдә ярдәмгә «Грантлар Капитаны мәгълүмат-белем бирү үзәге» проекты – Россиянең барлык төбәкләрендәге актуаль грантлар һәм конкурслар турында белешмәләрне автоматлаштырылган рәвештә җыю өчен бердәй мәгълүмат системасы (https://cptgrants.org) тормышка ашырыла.

КБО турында мәгълүматларны үзәкләштерү максатларында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан Татарстанда ярдәмнән файдаланган СЮКБОның республика реестры алып барыла. Төп мәгълүматны СЮКБОларга төрле ярдәм чаралары күрсәтүче дәүләт хакимияте башкарма органнары бирә. Шундый ук реестрлар республиканың муниципаль берәмлекләрендә дә алып барыла. 2023 елның 1 гыйнварына 1 046 оешма турында мәгълүмат теркәлде, аларга 2012–2022 елларда гомуми суммасы 17,2 млрд сум күләмендә финанс ярдәме күрсәтелде. Реестр мәгълүматлары нигезендә 2022 елда 429 СЮКБОга гомуми суммасы 2,9 млрд сум күләмендә финанс ярдәме күрсәтелгән. Реестр Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://mert.tatarstan.ru/reestr.htm сылтамасы буенча урнаштырылган.

# МӘДӘНИЯТ, СОЦИАЛЬ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ, СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ ҺӘМ МӘГАРИФ ӨЛКӘСЕНДӘ ОЕШМАЛАР ТАРАФЫННАН КҮРСӘТЕЛГӘН ХЕЗМӘТЛӘРНЕҢ СЫЙФАТЫНА БӘЙСЕЗ БӘЯ БИРҮ

2013 елдан мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан күрсәтелгән хезмәтләрнең сыйфатына бәйсез бәя бирү эше алып барыла (Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указын, «Мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан күрсәтелгән хезмәтләрнең сыйфатына бәйсез бәя бирү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 21 июлендәге 256-ФЗ номерлы Федераль законны, «Мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар һәм федераль медицина-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан күрсәтелгән хезмәтләрнең сыйфатына бәйсез бәя бирүне камилләштерү мәсьәләләре турында Россия Федерациясе аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 5 декабрендәге 392-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән).

Күрсәтелгән хезмәтләрне бәяләү оешма турында мәгълүматтан һәркемнең куллана алуын тәэмин итү, хезмәт күрсәтү шартларының уңайлылыгы, шул исәптән хезмәт күрсәтүне көтү вакыты, оешма хезмәткәрләренең яхшы мөнәсәбәте, әдәплелеге һәм итәгатьлелеге, күрсәтелгән хезмәтләрдән канәгатьлелек дәрәҗәсе, шулай ук сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле кешеләрнең хезмәтләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү кебек критерийлар буенча алып барыла.

Сыйфатка бәйсез бәя бирүне Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлекне саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, шулай ук республика җирле үзидарәләре органнары карамагындагы иҗтимагый советлар карарлары нигезендә оештырылган иҗтимагый оешмалар уздыра.

Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан күрсәтелгән хезмәт шартлары турында мәгълүматны җыюны һәм гомумиләштерүне иҗтимагый советлар тарафыннан билгеләнгән оешмалар исемлеге нигезендә операторлар тарафыннан башкарыла.

Әлеге максатларга дәүләт хакимияте органнары тарафыннан 245,9 мең сум акча бүлеп бирелде, шулардан мәдәният өлкәсендә – 26,5 мең сум, мәгариф өлкәсендә – 120,0 мең сум, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә – 49,4 мең сум, сәламәтлек саклау өлкәсендә – 50,0 мең сум; җирле үзидарә органнарына – 295,9 мең сум, шулардан мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә – 1 мең сумнан алып 98,9 мең сумга кадәр (11 муниципаль берәмлектә операторлар бушлай яисә җәмәгать башлангычларында эшләде).

Законнар нигезендә бер үк оешманың хезмәтләренә бәйсез бәя бирү елга бер тапкырдан да ешрак һәм өч елга бер тапкырдан да кимрәк булырга тиеш түгел. 2022 елда түбәндәге оешмаларга карата хезмәтләргә бәйсез бәя уздырылды:

219 социаль өлкә дәүләт оешмасы (хезмәтләрнең сыйфатына бәйсез бәя уздырылырга тиешле оешмаларның 30 %), шуларга 18 мәдәният оешмасы, 69 медицина оешмасы, 79 белем бирү оешмасы, 53 социаль хезмәт күрсәтү оешмасы керә;

854 социаль өлкә муниципаль оешмасы (хезмәтләрнең сыйфатына бәйсез бәя уздырылырга тиешле оешмаларның 30 %), шулардан 63 мәдәният оешмасы, 791 мәгариф оешмасы.

Социаль өлкә оешмалары тарафыннан күрсәтелгән хезмәтләргә бәйсез бәя бирү нәтиҗәләре буенча тулаем алганда уңай бәя бирелде.

Анкета һәм социологик сораштыру уздыру нәтиҗәләре буенча социаль өлкә оешмалары тарафыннан күрсәтелгән хезмәтләрнең сыйфаты турында кулланучылар фикере тупланды. 2022 елда анкета һәм социологик сораштыруда 183 523 кеше катнашты.

Сораштыру һәм бәяләү нәтиҗәләре буенча республиканың дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып, бәяләү нәтиҗәсендә ачыкланган кимчелекләрне бетерү планнары раслана. Әлеге планнарда хезмәт күрсәтү өчен уңайлы шартлар тәэмин итү, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затларга башкалар белән беррәттән хезмәтләрдән файдалану өчен шартлар булдыру өчен төзекләндерү эшләре алып бару, социаль өлкә хезмәткәрләренең квалификацияләрен арттыру, өлкән яшьтәге гражданнар һәм сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар белән эшләүдә технологияләр куллану, оешмаларның рәсми сайтларында һәм мәгълүмати стендлардагы мәгълүматны вакытында яңартып тору һәм социаль өлкә оешмалары тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшыртуга юнәлтелгән башка чаралар уздыру каралган.

Гражданнарга бәйсез бәя уздыруда катнашу мөмкинлеге турында хәбәр итү максатларында дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан мәгълүмати-аңлату эшләре алып барыла.

Бәйсез бәя бирү процессын башкару социаль өлкә оешмаларының эш сыйфатын яхшыртуга, иҗтимагый оешмаларны әлеге эшне башкаруга җәлеп итү өчен шартлар булдыруга юнәлтелгән.

# ТУРИСТЛЫК

2022 елда Татарстан Республикасына туристлар агымы 3,7 млн кеше тәшкил итте. Әлеге күрсәткеч буенча республика Россия Федерациясе төбәкләре арасында 7 нче урында һәм Идел буе федераль округында 1 нче урында.

Республиканың төп туристлык үзәкләрендәге музейларда 6,6 млн кеше булды, бу исә 2021 ел белән чагыштырганда 30 % күбрәк (5,1 млн кеше).

**Татарстан Республикасының төп туристлык үзәкләрендә музейларга килүчеләр динамикасы**

| Татарстан Республикасының төп туристлык үзәкләре | 2021 ел | 2022 ел | 2021 белән чагыштырганда % |
|---|---|---|---|
| «Казан Кремле» музей-тыюлыгы | 3 029 068 | 3 728 728 | 123,1 |
| «Свияжск утрау-шәһәре» музей-тыюлыгы | 899 412 | 1 388 267 | 154,4 |
| Болгар тарих-архитектура музей-тыюлыгы | 411 491 | 595 759 | 144,8 |
| Алабуга музей-тыюлыгы | 487 174 | 590 410 | 121,2 |
| Чистай музей-тыюлыгы | 55 391 | 83 240 | 150,3 |
| Тәтеш төбәге тарихы музее | 109 607 | 169 749 | 154,9 |
| Биләр дәүләт тарих-археология һәм табигать музей-тыюлыгы, Биләр авылы | 70 943 | 71 208 | 100,4 |

Республиканың кунакханә фонды 22 мең номердан тора. Әлеге күрсәткеч буенча республика Россия Федерациясендә 7 нче урында һәм Идел буе федераль округында 1 нче урында. Кунакханәләргә килүчеләр саны 73 % (пандемиягә кадәрге 2019 елда – 61 %).

«Туристлык һәм кунакчыллык индустриясе».

Татарстан Республикасында «Туристлык һәм кунакчыллык индустриясе» дигән илкүләм проекты кысаларында «Туристлык инфраструктурасын үстерү» фед проекты гамәлгә ашырыла һәм «Туристлык инфраструктурасын үстерү (Татарстан Республикасы (Татарстан)» төбәк проекты формалаштырылды аны тормышка ашыруга 530,4 млн сум акча бүлеп бирелде, шулардан федераль бюджеттан – 373,7 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан – 156,7 млн сум, шул исәптән:

Татарстанда «Идел Болгарстаны» туристлык макротерриториясен үстерү комплекслы инвестиция проекты составына керә торган инфраструктураны тәэмин итүче объекты төзелешен уртак финанслау: Тәтеш муниципаль районында «Түбәтәй тауэр» объекты территориясен төзекләндерү һәм инфраструктура төзү;

бюджетара трансфертлар рәвешендә модульле капиталь булмаган төзелеш объектлары (кемпинглар һәм автокемпинглар) төзүгә иҗтимагый башлангычларга ярдәм күрсәтү – туристларга урнашу өчен 10 яңа урын төзү һәм 8 гамәлдә булган объектны киңәйтү (706 кешегә исәпләнгән 219 йорт);

Татарстанда туристлык инфраструктурасын үстерү буенча 13 проектка бюджетара трансфертлар рәвешендә туристлык инфраструктурасын үстерүгә грантлар бирүдә булышлык итү.

2022 елның 15 мартында Татарстан Республикасы һәм «Корпорация Туризм.РФ» акционер җәмгыяте арасында хезмәттәшлек турында килешүгә кул куелды, аның кысаларында 73 га мәйданда, елның теләсә кайсы фасылында ял итү мөмкинлеге булган, СПА-үзәкләр, рестораннар, пляж ялы өчен инфраструктура объектлары булган, Россиядә тиңе булмаган туристлык территориясен проектлау эше алып барыла. Проектның үзенчәлеге яхта маринасы һәм яхта хуҗалары өчен яхталарга техник хезмәт күрсәтү мөмкинлеге булган яр буенда сервис инфраструктурасы һәм кыш көне кече судноларны саклау урыны төзү булып тора. Яңа туристлык кластеры Лаеш шәһәреннән берничә километр ераклыкта Кама диңгезе яр буенча төзеләчәк.

**Туристлык маршрутлары челтәрен үстерү.**

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты тарафыннан конкурентлыкка сәләтле туристлык маршрутлары төзү эше дәвам иттерелә: «Бөек Болгар юлы» бренды белән 20 дән артык төбәара җир өсте маршруты һәм 1 Мәскәү – Волгоград круиз маршруты (Свияжск утрау-шәһәрендә, Казан, Болгар, Тәтеш шәһәрләрендә тукталышлар булган). Әлеге проектта Идел буе федераль округының географик, тарихи һәм мәдәни яктан бергәлеккә ия, милли үзенчәлеге булган һәм иң мөһим сәүдә юлы һәм тормыш чыганагы – Идел елгасы буенда урнашкан 14 субъекты буенча төбәкара маршрут керә.

2022 елда яңа проект «Идел юлы» – җәяүлеләр өчен туристлык маршруты төзү буенча эш башланды. Маршрут Идел елгасы яры буенча Чувашстан Республикасы һәм Ульяновск өлкәсе чигенә кадәр Татарстан Республикасы территориясе аша уза. Юлның төп трекы озынлыгы – 284 км. Берничә әйләнә һәм радиаль маршрут эшләнде, шуның нәтиҗәсендә «Идел юлы» маршрутының Татарстанда озынлыгы 360 кмга җитте.

«Ял көннәрендә 1001 ләззәт» программасы дәвам иттерелә. Бу ике көнлек комплекслы тур кысаларында бердәй бәядән – бер кешегә 2 200 сумнан ял итәргә була. 2022 ел туристлык сезоны программасында республиканың 10 муниципаль районы: Спас, Чистай, Алабуга, Мамадыш, Саба, Кама Тамагы, Балык Бистәсе, Арча, Кукмара һәм Алексеевск районнары катнашты. Әлеге районнарда ялларда бер үк вакытта 500 кешене кабул итү мөмкинлеге бар.

«Туристлык һәм кунакчыллык индустриясе 4 илкүләм проекты кысаларында FUN&SUN туроператоры Ростуризм агентлыгы һәм Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты белән берлектә Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләреннән Татарстан Республикасына чартер программасы эшләнде, аның өчен махсус 5 экскурсия программасы төзелде. Чартер программасы нәтиҗәләре буенча язгы-җәйге чорда (29 апрельдән 16 сентябрьгә кадәр) 7,6 мең турист 46 чартер рейсы белән Татарстан Республикасына килде.

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты ярдәме белән Болгар музей-тыюлыгы территориясендә ике зур чара булып узды:

традицион рәвештә 30 меңнән артык кеше катнашында «Бөек Болгар» Урта гасыр көрәше фестивале;

«VANLIFE Фест» бөтенроссия автотуризм һәм караванинг фестивале, анда Россия Федерациясе төбәкләреннән, Беларусь Республикасыннан һәм Казахстан Республикасыннан 400 дән артык экипаж катнашты.

Татарстан Республикасының туристлык мөмкинлекләрен Россия һәм чит ил базарларына чыгару максатларында түбәндәге чаралар үтәлде:

Татарстан Республикасының MITT чит ил туристлык күргәзмәләрендә катнашуы (15-17 март, Мәскәү шәһәре) һәм «Интурмаркет» (12-14 март, Мәскәү шәһәре);

Үзбәкстан Республикасында, Азәрбайҗан Республикасында, Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә Россия туристлык операторлары һәм туристлык агентлары өчен 15 презентация һәм 4 туристлык роуд-шоу; туристлык операторлары һәм туристлык агентларының 186 вәкиле өчен 8 реклама-мәгълүмат туры; журналистлар һәм блогерлар өчен 4 матбугат-туры уздырылды; Татарстан Республикасы территориясендә 7тревэл-тапшыру төшерелде;

Мәскәү шәһәрендә тышкы реклама элмә такталарында; Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләре арасында «Сапсан» тиз йөрешле поездларында; Шереметьево, Домодедово һәм Внуково аэропортларыннан Мәсәү шәһәренә баручы тиз йөрешле «Аэроэкспресс» поездларында; Казан шәһәре аэропортында; Мәскәү – Казан юнәлешендә хәрәкәт итүче поездларда; City Sightseeing ике катлы өч автобуста Татарстанның туристлык мөмкинлекләрен күрсәтүче 7 имидж реклама кампаниясе эшли.

«Тарихи тамырларыбызга сәяхәт» XIII республика конкурсы уздырылды. Ул Татарстанда балалар һәм яшүсмерләр аудиториясенә юнәлтелгән беренче конкурс, аның максаты – тарихи мирас һәм өстенлекле туристлык үзәкләре белән бәйле хосусый инновация проектларын тормышка ашыру аша Татарстан Республикасында эчке һәм тышкы туристлыкны үстерү. Конкурс тугыз номинациядә: «Татарстан Республикасында мин барырга теләгән урын» темасына иң яхшы рәсем», «Иң яхшы мәдәни-танып-белү маршруты», «Иң яхшы авыл туризмы маршруты», «Иң яхшы этнотуризм маршруты», «Иң яхшы актив туризм һәм ял итү маршруты», «Иң яхшы гастрономик туризм маршруты», «Татарстан Республикасы буенча иң яхшы виртуаль экскурсия», «Туристлык өлкәсендә иң яхшы проект» һәм «Иң яхшы видео-экскурсия» уздырылды. 2022 елда конкурста катнашуга республиканың 17 муниципаль районыннан 136 гариза кабул ителде.

**Волонтерлык хәрәкәте.**

1 июньнән 31 августка кадәр «Татарстан Республикасының туристлык волонтерлары ассамблеясе» автоном коммерциячел булмаган оешмасы белән берлектә еллык «Кунакчыл Казан» проекты тормышка ашырылды, аның кысаларында республиканың югары белем бирү мәгариф оешмалары туристлык факультетлары студентлары туристларга Казан шәһәре һәм Татарстанның төп туристлык үзәкләре турында мәгълүмат бирде, шәһәрдә хәрәкәт итәргә булышлы, шулай ук Казан шәһәре, Бөек Болгар һәм Свияжск утрак-шәһәренең өч телдә бастырып чыгарылган туристлык карталарын тәкъдим итте. Волонтерлар теория һәм гамәли күнекмәләр буенча белем алды. Проектны тормышка ашыру барышында Россия Федерациясе шәһәрләреннән (Мәскәү, Санкт-Петербург, Уфа, Түбән Новгород, Самара) һәм чит илләрдән (Германия, Франция, АКШ, Мисыр, Испания) волонтерларга 37 800 дән артык турист мөрәҗәгать итте.

**ЭКОЛОГИЯ**

**Атмосфера һавасын саклау.**

Автотранспортның атмосфера һавасына тискәре йогынтысын киметү максатларында 2022 елда Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе белән берлектә линиягә чыгарылган һәм файдалануда булган автотранспорт чаралары тарафыннан эшкәртелгән газлардагы һавага чыгарылган пычрак матдәләрнең микъдарына карата билгеләнгән нормативлары үтәлешенә күзәтчелек буенча оператив-профилактика чаралары («Чиста һава» операциясе) уздырды. Операция барышында республика предприятиеләрендә һәм автомобиль юлларында барлыгы 6 570 автомобиль тикшерелде, шулардан 183 автомобиль билгеләнгән нормативларга туры килми.

2022 елда Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы 2021 ел өчен Татарстан Республикасы территориясендә парник газларының һавага чыгарылуы һәм йотылуын исәпкә алу буенча эш алып барды (Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының 2015 елның 16 апрелендәге 15-р номерлы боерыгы белән расланган методик тәкъдимнәр нигезендә). Соңгы еллар дәвамында парник газларының һавага чыгарылуы һәм йотылуының тенденцияләре билгеләнде, парник газларының һава бассейнына чыгуын киметүнең тотрыклы тенденциясе билгеләнде.

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең экологик үсеше өлкәсендә һәм климаттагы үзгәрешләр буенча дәүләт фәнни-техник сәясәтен тормышка ашыру чаралары турында» 2021 елның 8 февралендәге 76 номерлы Указын үтәү йөзеннән Татарстан территориясендә 2022–2030 елларга Россия Федерациясенең экологик үсеше өлкәсендә һәм климаттагы үзгәрешләр буенча дәүләт фәнни-техник сәясәтен тормышка ашыру планы эшләнде (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 декабрендәге 1390 номерлы карары белән расланды).

**Су объектларын саклау.**

Татарстан Идел буе федераль округының иң күп сулыклары булган төбәкләреннән берсе булып тора: республиканың гомуми территориясенең 6,4 % ы сулыклардан тора, бу исә 36 384 су объекты дигән сүз.

2022 елның 17 августында Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советының «Татарстан Республикасында су объектларын саклау өлкәсендә экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү турында» утырышы булды, аның йомгаклары буенча дәүләт хакимияте башкарма органнарына, муниципаль берәмлекләргә, хокук саклау органнарына һәм предприятиеләргә су объектларының торышын яхшырту бурычы куелды.

«Нокса елгасын чистарту» проекты эшләнә, ул елгага начар тәэсир ясаучы факторларны ачыклау һәм аларга бәя бирү, су объектын һәм аның янындагы территорияне, шул исәптән Казан шәһәре чикләрендә дә торгызу һәм аның экологик торышын яхшырту буенча эшләр башкаруга юнәлтелгән. Волонтерлар 30 ноябрьдән алып 7 декабрьгә кадәр вакыт аралыгында елга тамагы участокларын карап тикшерде һәм аерым участокларда агачлар ауган җирләрне чистартты. Казан

шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан Нокса елгасы экореабилитацияләү эшләрен федераль программага кертү өчен проект-смета документлары эшләнә.

Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Урынбасары Д.Н. Чернышенко җитәкчелегендәге Татарстанның социаль-икътисадый проектлары исемлегенә кертелгән «Татарстан Республикасы елгаларының һәм сулыкларының экологик торышын яхшырту» дигән пилот проект эшли башлады. Проект Рус география җәмгыяте, Россия фәннәр академиясенең әйдәүче институтлары һәм башка фәнни берләшмәләр белән берлектә эшләнде. Беренче этапта Казансу елгасы бассейнын проблемалы участокларны һәм начар йогынты ясаучы объектларны билгеләү максатыннан өйрәнү, картасын ясау һәм зоналарга бүлү эшләре каралган. Рус география җәмгыятенең Татарстан бүлекчәсе тарафыннан 2022 елда эшләр башкаруга Рус география җәмгыяте тарафыннан географик тикшерү эшләре башланды. Икенче этапта әйдәүче фәнни оешмалар катнашында фәнни-тикшеренү эшләре алып бару каралган.

Диффуз агынты суларының йогынтысын киметү өчен Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан федераль проектлар кысаларында республика территориясендә су объектлары яр буйларында су саклау урман полосалары булдыру буенча пилот проект эшләнде. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы белән берлектә тиешле эшләрне башкару өчен җир кишәрлекләре сайлау һәм аларны резервка алу буенча чаралар уздырыла.

Сулыклардан рациональ файдалануны җайга салу һәм сулыкларны саклау буенча Россия Федерациясе тапшырган вәкаләтләрне үтәү йөзеннән су мөнәсәбәтләре өлкәсендә 247 су объектында гомуми озынлыгы 14 454,65 км яр буе линияләре урнашкан урыннарны (су объектының чикләре), сулыкларны саклау зоналары һәм яр буе сак полосалары чикләрен билгеләү эшләре башкарылды. Белешмәләр дәүләт су реестрына кертелде. Әлеге урыннарда сулыкларны саклау зоналары һәм яр буе сак полосалары чикләрен билгеләү өчен 1 750 махсус мәгълүмати билгеләр урнаштырылды.

**Җир асты сулары запасларын торгызу.**

2023 елның 1 гыйнварына республика территориясендә расланган 2 383,9 мең куб. м/тәүлек запаслары белән җир асты суларының 522 ятмасы ачыкланган һәм тикшерелгән, шуларның 2 336,7 мең куб. м/тәүлек (402 чыганак) - эчәргә яраклы җир асты сулары запаслары.

Су хуҗалыгы торышы һәм җирдән файдалану шартлары үзгәрүгә бәйле рәвештә Столбище ятмасындагы җир асты сулары запасларын яңадан бәяләү тәмамланды. Җир асты суларының баланс запаслары В + С1 категориясе буенча 180 мең куб. м/тәүлек күләмендә яңадан расланган, шул исәптән В категориясе буенча - 110 мең куб. м/тәүлек.

**Гомумтаралган файдалы казылмалар.**

Татарстан Республикасының минераль-чимал базасын торгызу өчен 2022 елда гомумтаралган файдалы казылмалар запаслары 119,4 млн. куб. м күләмендә арттыру тәэмин ителгән, шул исәптән файдалы казылмалар төрләре буенча:

комлы-вак ташлы токымнар - 24,0 млн куб. м;

төзелеш ташлары (известьташ) - 8,3 млн куб. м;
төзелеш комы - 70,3 млн куб. м;
комлы-балчыклы токымнар - 5,8 млн. куб. м;
кирпеч-чирәп чимал - 6,3 млн куб. м;
комлык - 4,2 млн куб. м;
торф - 0,36 млн куб. м;
известь кертү өчен карбонатлар - 0,19 млн куб. м.

Җир асты байлыкларыннан тигез файдалану өчен республиканың гомумтаралган файдалы казылмалар запаслары белән тәэмин ителешен даими тикшереп тору алып барыла.

2023 елның 1 гыйнварына республика территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына 2 029 лицензия гамәлдә булды, шул исәптән:

312 лицензия гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару өчен 184 предприятие тарафыннан рәсмиләштерелгән (җир асты байлыкларының 106 участогы елгалар акваторияләрендә, 206 - коры җирдә урнашкан), шуларның 60 лицензиясе туктатып тору хәлендә;

1 717 лицензия төрле милек рәвешләрендәге предприятиеләргә, бакчачылык ширкәтләренә һәм шәхси эшмәкәрләргә җир асты суларын геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару өчен бирелгән, алар эчәргә яраклы су һәм техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла һәм аларны чыгару күләме 500 куб. м/тәүлектән артмаган.

**Әйләнә-тирә мохит торышын күзәтү буенча территориаль системасын үстерү.**

Әйләнә-тирә мохитнең торышын күзәтү территориаль системасы кысаларында республика территориясендә атмосфера һавасының пычрануын контрольдә тотуның 16 автомат станциясеннән (алга таба - станцияләр) һәм 6 күчмә экологик лабораториядән (алга таба - лабораторияләр) торучы атмосфера һавасының пычрануын күзәтү челтәре формалашты.

Казан һәм Чаллы шәһәрләренең өч лабораториясен атмосфера һавасында формальдегид билгеләү буенча газ-аналитик комплекс белән җиһазландыру үткәрелде. 9 станциядә һәм 4 лабораториядә 22 берәмлек экология-аналитик җиһазлар алыштырылды.

Эре сәнәгать предприятиеләре белән мәгълүматлар алмашу турында төзелгән килешүләр кысаларында Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы on-line режимда атмосфера һавасында пычраткыч матдәләр концентрациясе турында «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ атмосфера һавасының пычрануын контрольдә тотуның биш автомат станциясеннән (Түбән Кама шәһәре), В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ атмосфера һавасының пычрануын контрольдә тотуның өч станциясеннән (Әлмәт шәһәре) һәм «ТАНЕКО» АҖнең атмосфера һавасының пычрануын автомат рәвештә тикшереп тору станциясеннән мәгълүмат алды.

Өске су объектларының торышын анализлау максатларында 108 күзәтү пунктында су объектларының гидрохимик торышын даими мониторинг күзәтеп торуы, шулай ук 132 күзәтү пунктында күзәтү максатларында су объектларының

торышын күзәтү (66 яңгыр сулары канализацияләрен һәм чистарту корылмалары йогынтысы зонасында), 83 су объекты мониторинг һәм күзәтчелек кысаларында күзәтүләр белән колачланды.

**Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге).**

Контроль-күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы хезмәткәрләре ел дәвамында хокук бозучыларга 348 дәгъва гаризасы, шул исәптән 149 - әйләнә-тирә мохит компонентларына зарар салу факты буенча (гомуми суммасы 520,8 млн сум), 199 - ачыкланган хокук бозулар ирекле тәртиптә бетерелмәгән очракларда аларны бетерүгә мәҗбүр итү турында дәгъвалар, дәгъва гаризалары (алардан санкцияләнмәгән калдыкларны ташлауны бетерү өлешендә - 104, файдаланылган җир участокларын рекультивацияләү өлешендә - 75, су объектларыннан файдалану өлкәсендә хокук бозуларны бетерү буенча - 14, җир бозылган очракта - 2, башка очракларда - 4) белдерделәр.

Закон бозган өчен гомуми суммасы 12,6 млн сумлык административ штрафлар салынган. Барлыгы 29,6 млн сумлык зыян һәм административ штрафлар алынды.

Әйләнә-тирә мохит компонентларына шактый зыян китерергә мөмкин булган законнарны тупас бозу өчен хокук саклау органнарына 36 материал тапшырылган, алар буенча 16 җинаять эше кузгатылган.

Табигатьне саклау законнарының мәҗбүри таләпләрен бозуны кисәтү һәм булдырмау максатыннан Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы хезмәткәрләре мәҗбүри таләпләрне бозуны булдырмау турында һәм аларның үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрү зарурлыгы турында 2 888 кисәтү чыгарды. Мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау өчен штраф рәвешендәге административ җәзаны алыштыру сыйфатында 169 кисәтү чыгарылган.

Хуҗалык эшчәнлеген бер елдан кимрәк гамәлгә ашыручы юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга законнар таләпләре турында мәгълүмат бирү өчен хуҗалык итүче субъект эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча 51 профилактик визит башкарылды.

Шулай ук әйләнә-тирә мохит, җирле әһәмияттәге җир асты байлыкларын саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне үтәүгә бәйле булган мөрәҗәгатьләр буенча табигатьтән файдаланучыларга консультацияләр үткәрелде. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының территориаль идарәләре базасында табигатьтән файдаланучыларны массакүләм җәлеп итү өчен табигать саклау законнарын үзгәртү һәм әйләнә-тирә мохитне саклау һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыкларын саклау өлкәсендәге таләпләр буенча профилактик (ачык) чаралар оештырылды.

Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) уздыру кысаларында Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының дәүләт инспекторлары элек инспекторлар билгеләгән срокта бетерелмәгән 1 632 кагыйдә бозу очрагын ачыклаган, шуларның ел дәвамында 1 476 бозу бетерелде.

Ел эчендә табигатьне саклау законнарын бозуның 7 599 очрагы туктатылды. Ачыкланган хокук бозулар фактлары буенча Татарстан Республикасы Экология

һәм табигать ресурслары министрлыгы дәүләт инспекторлары тарафыннан административ хокук бозулар турында 663 беркетмә төзелде. Гомумтаралган файдалы казылмаларны законсыйз чыгаруның 31 факты һәм лицензия шартларын бозуның 153 очрагы теркәлде. Ачыкланган хокук бозулар фактлары буенча 64 беркетмә төзелде. Хокук бозучыларга 3,1 млн сумлык штраф салынды, дәгъвалар белдерелде, хокук бозучыларга 18,0 млн сумлык зыянны кайтару буенча дәгъва таләпләре юлланды.

**«Экология» илкүләм проекты**

2022 елда Татарстанда «Экология» илкүләм проектының 4 федераль проектын гамәлгә ашыруга 6 811,7 млн сум юнәлдерелгән, шул исәптән федераль бюджеттан - 5 370,5 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан - 1 441,2 млн сум, шул исәптән:

1) “Иделне сәламәтләндерү” федераль проектының ике юнәлеше буенча 6 387,0 млн сум үзләштерелгән, шул исәптән федераль бюджеттан - 5 025,8 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан - 1 361,2 млн сум, шул исәптән:

*«Идел елгасына чыгарыла торган пычрак агып төшүче сулар өлешен киметү»* юнәлеше буенча - Казан шәһәре канализациясенең биологик чистарту корылмаларын реконструкцияләгәндә 2 786,2 млн сум үзләштерелгән, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән - 2 256,8 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан - 529,4 млн сум;

*«Идел елгасына куркыныч тудыручы тупланган экологик зыян объектларын бетерү»* юнәлеше буенча:

Казан шәһәренең 100 гектарга якын мәйданлы биологик чистарту корылмаларының ләм кырларын рекультивацияләү эшләрен дәвам итүгә 3 300,8 млн сум үзләштерелгән, шул исәптән федераль бюджеттан - 2 673,7 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан - 627,1 млн сум;

«Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә Озерный ятмаларының эшләми торган торба үткәргечләрен сүттү» чарасы гамәлгә ашырыла башлауга - 300,0 млн сум, шул исәптән федераль бюджеттан - 95,3 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан - 204,7 млн сум (шул исәптән 200 млн сум - Татарстан Республикасы бюджеты керемен түләүсез кергән «РИТЭК» ҖЧҖ бюджеттан тыш чаралары);

2) «Чиста ил» федераль проекты буенча Казан шәһәренең Мамадыш тракты урамында 14,14 га мәйданлы Самосырово полигонын рекультивацияләү эшләрен дәвам итүгә 200,0 млн сум үзләштерелгән, шул исәптән федераль бюджеттан - 120,0 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан - 80,0 млн сум. Чараны гамәлгә ашыру срогы - 2021 - 2023 еллар;

3) «Уникаль су объектларын саклау» федераль проекты буенча федераль бюджеттан - түбәндәге чараларга 113,2 млн сум:

«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольск авылы янындагы Мишә елгасының уң кушылдыгын чистарту», яр буе сызыгы озынлыгы - 4 км. Эшләр 2021 елда тәмамланды, 2022 елда су биологик ресурсларына зыянны каплау эшләре башкарылды;

«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Державин авылында буаны чистарту», яр буе сызыгының озынлыгы - 7,2 км. Эшләр 2021 елда тәмамланды, 2022 елда су биологик ресурсларына зыянны каплау эшләре

башкарылды;

«Татарстан Республикасы Мамадыш шәһәрендә Нократ елгасының уң кушылдыгын чистарту», яр буе сызыгының озынлыгы - 3,3 км. Эшләр 2022 елда тәмамланды;

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Кама Леспромхозы авылы янында Берсут елгасы юлын чистарту», яр буе сызыгының озынлыгы - 7 км. 2022 елга планлаштырылган эшләр төгәлләнде.

2022 елда «Уникаль су объектларын саклау» федераль проекты кысаларында яр буе территорияләрен чистарту чараларында 300,6 мең волонтер катнашты, 8,5 мең км яр буе сызыклары чистартылды.

Татарстан Республикасы «Уникаль су объектларын саклау» федераль проектының «Россия суы» федераль акциясендә икенче ел рәттән 1 нче урынны алып тора;

4) “Урманнарны саклау” федераль проекты буенча федераль бюджеттан 111,5 млн сум күләмендә субвенцияләр үзләштерелде, шул исәптән урман орлыклары запасын булдыру, урман торгызу һәм урман үрчетүне тәэмин итү, урманнарны янгыннардан саклау техникасы һәм җиһазлары белән җиһазландыруга, учреждениеләрне урман торгызу һәм урман үрчетү өчен махсус техника һәм җайланмалар белән җиһазландыруга.

**Табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану.**

*«Табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» Россия Федерациясе дәүләт программасы.*

22 чараны гамәлгә ашыруга 271,5 млн сум акча тотылган (федераль бюджеттан - 177,9 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан - 93,6 млн сум), шул исәптән:

126,2 млн сум (федераль бюджет акчасы - 75,7 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы - 50,5 млн сум) - «Татарстан Республикасы Кама Тамагы торак пункты янында Куйбышев сусаклагычы ярын ныгыту» объектында эшләр башларга, 2022 - 2023 елларда гамәлгә ашыруга;

107,8 млн сум (федераль бюджет акчасы - 64,7 млн сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы - 43,1 млн сум) - Алабуга, Мамадыш, Питрәч, Саба, Чирмешән, Биектау, Чистай һәм Зеленодольск муниципаль районнарында 14 гидротехник корылмаларда капиталь ремонтны башлау өчен;

19,2 млн сум (федераль бюджет акчасы) - су саклау зоналары һәм яр буе яклау полосалары чикләренең яр буе сызыклары урынын билгеләү эшләре башлануга һәм 2021 елда башланган эшләрне тәмамлауга, җирлектә су саклау зоналары һәм яр буе яклау полосалары чикләрен махсус мәгълүмат тамгалары белән беркетү эшләрен төгәлләүгә, Буа шәһәрендәге Карлы елгасының сул кушылдыгында су басуга каршы чараларны төгәлләүгә су мөнәсәбәтләре өлкәсендә аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга;

«Россия Федерациясе территориясендә суларның тискәре йогынтысыннан яклау һәм гидротехник корылмаларның куркынычсызлыгын тәэмин итү» федераль проекты кысаларында 18,3 млн сум (федераль бюджет акчасы) - Мамадыш шәһәрендә Ошма елгасында 2019 елда башланган эшләрне тәмамлауга.

*«Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать*

*ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» дәүләт программасы.*

Татарстан Республикасы бюджетыннан табигатьне саклау буенча 93 чараны гамәлгә ашыруга түбәндәге ярдәмче программалар буенча 1 083,8 млн сум акча бүленгән:

«Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохите сыйфатын җайга салу» - 61,7 млн сум;

«Татарстан Республикасында җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә дәүләт идарәсе» - 54,3 млн сум;

«Татарстан Республикасының җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә дәүләт идарәсе» - 172,7 млн сум;

«Татарстан Республикасының су хуҗалыгы комплексын үстерү» - 795,1 млн сум.

**Җирле бюджет акчалары исәбеннән табигатьне саклау чараларын финанслау.**

2022 елда 209 табигатьне саклау чараларын гамәлгә ашыруга 252,9 млн сумга 45 килешү төзелгән. Каты коммуналь калдыклар белән эш итүне оештыруга, территорияләрнең экологик санитар иминлеген тәэмин итүгә, шул исәптән рөхсәтсез чүплекләрдән территорияләрне чистартуга, хуҗалык-көнкүреш суларын чистарту өчен чистарту корылмаларын карап тотуга һәм ремонтлауга, карьерларны рекультивацияләү, торак пунктлар территорияләрен төзекләндерүгә һәм яшелләндерүгә, табигатьне саклау чараларына проект-смета документларын эшләүгә, ярларны ныгыту һәм су тирәнәйтү эшләренә, чишмәләрне, сулыкларны һәм елгалар ярларын чистартуга, себер түләмәсе үләксә чокырларының санитар-яклау зоналарын кыскарту буенча эшләр башкаруга 191,1 млн сум күләмендә эш финансланды.

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 30 декабрендәге 446-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе субъектларына 2022 елның 1 сентябреннән башлап әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләүдән, штрафлардан һәм табигатьне саклау законнарын бозган өчен дәгъвалардан керемнәрне Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» Федераль законның 16.6 статьясындагы 1 пунктында, 75.1 статьясындагы 1 пунктында һәм 78.2 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән чаралар планын эшләү һәм килештерү тәртибе турында» 2022 елның 2 августындагы 1370 номерлы карары белән расланган чараларның бертип исемлеге нигезендә әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау, бәяләү һәм аларны бетерү эшләрен оештыруга, шулай ук табигатьне саклау чараларын гамәлгә ашыруга юнәлтергә кирәк.

**Табигать-тыюлык фондын үстерү.**

Махсус саклана торган табигать территорияләрен (алга таба - саклана торган территорияләр) булдыру табигать байлыкларын саклауның һәм арттыруның иң нәтиҗәле механизмы булып тора, бу экологик балансны һәм табигый биотөрлелекне сакларга, шулай ук халыкның тормыш сыйфатының мөһим компонентларының берсе буларак республиканың экологик иминлеген тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

Республиканың табигать-тыюлык фондыгомуми мәйданы 465,1 мең га булган (Татарстан Республикасының гомуми мәйданының 7 %) 193 саклана торган территорияне төзи, анда табигый комплексларны, ландшафтларны һәм биологик төрлелекне саклау һәм торгызу өчен оптималь шартлар тәэмин ителгән, шуларның 2 се - федераль әһәмияттәге, 187 се - төбәк әһәмиятендәге, 4 е- җирле әһәмияттәге.

Балтач һәм Саба муниципаль районнары территориясендә урнашкан кишәрлекләрдә табигый һәм ясалма нарат, чыршы һәм ак чыршы утыртмаларын саклау, сирәк үсемлекләрне һәм хайваннарны саклау өчен шартлар тудыру максатында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Экология проблемалары институты тәкъдиме буенча 202,8 гектар гомуми мәйдандлы «Ципьинский урманы» һәм «Екатериновка авылы янында урман массивы» төбәк әһәмиятендәге табигый һәйкәлләр төзелде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге саклана торган территорияләр төзү турындагы карарлары проектлары эшләнде: «Минзәлә муниципаль районы территориясендә «Шифа» чишмәсе тирәсендә табигый комплекс, Алексеевск һәм Балык Бистәсе муниципаль районнары территориясендә «Акчарлаклар колониясе», Азнакай муниципаль районы территориясендә «Байбаклар колониясе», Чистай муниципаль районы территориясендә «Ак челәннәр колониясе», Алексеевск муниципаль районы территориясендә «Юеш Көрнәле», Апас муниципаль районы территориясендә «Сфагново-үрге сазлык».

Өстәмә рәвештә 73 су саклау территориясе өчен саклау зоналары булдыру турында Татарстан Республикасы Рәисе указлары проектлары эшләнде.

Төбәк әһәмиятендәге саклана торган территорияләрне булдыру өчен перспективалы кишәрлекләрне ачыклау максатларында Югары Ослан, Кайбыч, Кама Тамагы, Лаеш, Зеленодольск (өлешчә Идел алды территориясе) муниципаль районнары территориясендә хайваннарның, үсемлекләрнең һәм гөмбәләрнең төр төрлелеген ачыклау буенча фәнни-тикшеренү эшләре алып барылды. Нәтиҗәдә, аларга махсус саклanучы табигать территориясе статусы бирү өчен потенциаль территорияләр буларак каралачак 8 участок билгеләнгән. Республика территориясендә моңарчы очрамаган сирәк очрый торган хайван һәм үсемлек төрләренең яңа яшәү урыннары ачыкланды.

**Урман комплексын үстерү.**

«Татарстан Республикасы урман хуҗалыгын үстерү» дәүләт программасы, 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясе һәм «Татарстан Республикасында урманнарны саклау» төбәк проекты кысаларында «Экология» илкүләм проектының «Урманнарны саклау» федераль проекты кысаларында түбәндәге чаралар уздырылды:

3 619 гектар гомуми мәйданда урман торгызу, шул исәптән 1 412,5 гектар мәйданда урман культуралары утырту, 104,6 гектар мәйданда урман үрчетү, 2 098 гектар мәйданда табигый урман торгызу, 4 гектар мәйданда катнаш урман торгызу;

булдырылган урман культураларын бетүдән саклап калу максатларында 13 530,8 гектар мәйданда агротехник тәрбия уздырылды, шулай ук 5 153,5 гектар мәйданда урман культуралары тулыландырылды. 1 413,5 гектар мәйданда урман культураларын утырту өчен туфрак әзерләнде. 111,6 гектр мәйданда утыртылганн

урман орлыкчылыгы объектларын тиешенчә карау уздырылды;

төп урман хасил итүче токымнарның 15,26 тонна орлыгы, шул исәптән ылыслы орлыклар - 880 килограммнан артык, нәселдәнлек сыйфатлары яхшыртылган орлыклар - 520 кг әзерләнгән. 2017 елда Татарстан Республикасының Урман селекция-орлыкчылык үзәге базасында урман үсемлекләре орлыкларының иминият фонды төзелде. Иминият фондында барлыгы 336,9 кг ылыслы токым орлыклары бар, шулардан 173,2 кг нарат орлыгы, 149,4 кг чыршы орлыгы, 14,3 кг карагай орлыгы.

“Хәтер бакчасы” халыкара табигатьне саклау акциясе барышында республиканың муниципаль берәмлекләре белән берлектә 250 гектар мәйданда 1,2 млн данә агач утыртылды. Көз көне “Урманны саклыйк” акциясе үткәрелде, аның кысаларында 595 гектар мәйданда 2 млн данә агач утыртылды.

Урманнарда имин санитар-экологик хәл тудыру һәм урман проблемаларына җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү максатында яз һәм көз көне “Татарстанның чиста урманнары” республика табигатьне саклау акциясе уздырылды. Акциядә республиканың 25 меңнән артык кешесе катнашты.

Урманны карау һәм санитар кисүләр 10 мең гектардан артык мәйданда башкарылды. 325 мең кубометр ликвидлы агач әзерләнде.

Урманны яклау максатларында 42 847,7 гектар мәйданда урман патологиясен тикшерү үткәрелде. 2 796,7 гектр мәйданда файдаланылмый торган агач җыештырылды.

Урман фонды җирләренә 33 меңнән артык патруль ясалды. Федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелек) кысаларында 74 планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасы гамәлгә ашырылды, шул исәптән 1 планнан тыш күчмә тикшерү һәм тикшерелә торган зат белән турыдан-туры бәйләнешләрсез планнан тыш 73 чара тикшерелде (күчмә тикшерү, мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү).

Административ хокук бозулар турында 433 беркетмә төзелгән, административ җәза билгеләү турында 532 карар чыгарылган, шуларның 158 е кисәтү рәвешендә, гомуми суммасы 1,5 млн. сумга административ штрафлар билгеләнгән.

Моннан тыш, 2 970 профилактик чара уздырылды, шул исәптән контрольдәге субъектлар адресына 2 171 профилактик һәм мәгълүмати хат җибәрелде, 28 кисәтү ясалды, 662 консультация һәм 107 профилактик визит башкарылды.

*«Татарстан Республикасында урманнарны саклау» төбәк проекты.*

“Экология” илкүләм проектының “Урманнарны саклау” федераль проектының “Татарстан Республикасында урманнарны саклау” төбәк проекты максаты - 2024 елга урманнарның бетү һәм тогызу балансын 100% нисбәтендә тәэмин итү. Шуңа бәйле рәвештә проектның ике төп күрсәткече билгеләнгән: «урманнарны яңадан торгызу һәм урман үрчетү мәйданының киселгән һәм һәлак булган урман утыртмалары мәйданына карата мөнәсәбәте» һәм «еллар буенча урман янгыннарыннан зыян».

2022 елда Татарстан территориясендә урман янгыннары теркәлмәгән.

“Татарстан Республикасында урманнарны саклау” төбәк проектын гамәлгә ашыру өчен 111,5 млн сум акча бүлеп бирелгән, шул исәптән 89,5 млн сум - урман торгызу мәйданын арттыруга, 5,4 млн сум - махсус учреждениеләрне урманнарны


янгыннан саклау буенча чаралар комплексын үткәрү өчен урмна янгыннарыннан саклау техникасы һәм җиһазлары белән тәэмин итүгә.

## ТӨП ИКЪТИСАДЫЙ КҮРСӘТКЕЧЛӘР

Татарстан Республикасы төп макроикътисадый күрсәткечләр буенча Россия Федерациясе төбәкләре арасында алдынгы урыннарны саклый.

Тулаем төбәк продукт күләме буенча республика Россия Федерациясе субъектлары арасында 6 нчы урында тора, сәнәгать җитештерүе күләме һәм авыл хуҗалыгы - 5 нче урында, төзелеш эшләре күләме - 4 нче урында, төп капиталга инвестицияләр һәм торакны гамәлгә кертү буенча - 6 нчы урында, ваклап сату әйләнеше - 7 нче урында.

**2022 елда Татарстан Республикасында тулаем төбәк продукты**




Ел нәтиҗәләре буенча тулаем төбәк продукты күләме, бәяләүләр буенча, 3 865,1 млрд сум тәшкил иткән, яки 2021 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 106,0 %.

**Татарстан Республикасында тулаем төбәк продукты җитештерү структурасы икътисадый эшчәнлек төрләре буенча 2022 елда (бәяләү), %**





Икътисад структурасында традицион рәвештә иң зур чагыштырма

авырлыкны сәнәгать били - 49,2 % (шул исәптән, файдалы казылмалар чыгару - 29,8 %, эшкәртү производстволары - 17,3 %, электр энергиясе, газ, пар белән тәэмин итү; һаваны кондиционлаштыру - 1,7 %, су белән тәэмин итү; су чыгару, калдыкларны җыю һәм утильләштерүне оештыру, пычрануларны бетерү эшчәнлеге - 0,4 %), авыл хуҗалыгы - 4,9 %, төзелеш - 7,1 %, күпләп һәм ваклап сату - 9,4 %, транспортировка һәм саклау - 5,2 %.

## Сәнәгать

Сәнәгать җитештерүе индексы 2021 ел дәрәҗәсенә карата 106,6% тәшкил иткән, төяп җибәрелгән продукция күләме (гамәлгә ашырылмаган калдыкларны исәпкә алып) - 4 623,9 млрд сум.

**2022 елда сәнәгать җитештерүе**




Файдалы казылмалар чыгаруда җитештерү индексы 2021 ел дәрәҗәсенә карата 105,2 % тәшкил итте, шул исәптән чи нефть һәм табигый газ чыгаруда - 103,5 %, файдалы казылмалар чыгару өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүдә - 123,1 %.

Эшкәртү производстволарында җитештерү индексы 2021 ел дәрәҗәсенә карата 108,2 % тәшкил итте.

Үсеш түбәндәге эшкәртү производстволарында күзәтелә: кокс һәм нефть продуктлары җитештерү (2021 ел дәрәҗәсенә карата 113,0 %), дару чаралары һәм медицина максатларында кулланыла торган материаллар (127,8 %), компьютер, электрон һәм оптика әйберләре (134,3 %), әзер металл эшләнмәләр, машиналардан һәм җиһазлардан тыш (102,4 %), электр җиһазлары (105,8 %), металлургия җитештерүе (109,3 %), башка транспорт чаралары һәм җиһазлар җитештерү (112,1 %), азык-төлек продуктлары (103,8 %), эчемлекләр (105,3 %), кәгазьләр һәм кәгазь эшләнмәләр (117,5 %), кием (107,6 %), күн һәм күн әйберләре (116,5 %), башка әзер әйберләр (100,2 %), җиһаз(101,8 %) җитештерү.


Сәнәгать җитештерүе күләмнәренең кимүе башка төркемнәргә кермәгән машиналар һәм җиһазлар (2021 ел дәрәҗәсенә 95,9 %), автотранспорт чаралары,

прицеплар һәм ярымприцеплар (90,0 %), резина һәм пластмасса эшләнмәләре (96,5 %), химик матдәләр һәм химик продуктлар (99,4 %), текстиль эшләнмәләр (90,5 %), башка металл булмаган минераль продукция җитештерүдә (93,7 %), агач эшкәртү һәм агач эшләнмәләре җитештерүдә (84,3 %), полиграфия эшчәнлеге һәм мәгълүмат чыганакларын күчереп алуда (23,3 %) күзәтелде.

Электр энергиясе, газ, пар белән тәэмин итүдә; һаваны кондицияләштерүдә җитештерү индексы 2021 ел дәрәҗәсенә 100 % тәшкил итте, су белән тәэмин итүдә; су чыгару, калдыкларны җыюны һәм утильләштерүне оештыру, пычрануларны бетерү эшчәнлеге - 91,1 %.

Сәнәгать структурасында файдалы казылмалар чыгару өлеше 22,7 %, эшкәртү производстволары - 72,4 %, электр энергиясе, газ һәм пар белән тәэмин итү өлеше; һаваны кондицияләштерү - 3,7 %, су белән тәэмин итү; су чыгару, калдыкларны җыюны һәм утильләштерүне оештыру, пычрануларны бетерү эшчәнлеге - 1,3 %.

**2022 елда Татарстан Республикасында сәнәгать структурасы**





## Авыл хуҗалыгы

Авыл хуҗалыгы продукциясе күләме 334,1 млрд сум тәшкил итте (2021 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 125,9 %). Үсемлекчелек продукциясе күләме - 175,6 млрд сум (160,0 %), терлекчелек продукциясе - 158,4 млрд сум (100,9 %).

5 210,7 мең тонна ашлык суктырылган (эшкәрткәннән соң авырлыгында), барлык категория хуҗалыкларда 920,1 мең тонна бәрәңге җыелган, 1 921,9 мең тонна шикәр чөгендере, 278,8 мең тонна ачык һәм саклаган грунт яшелчәләре җыелды.

2 033,5 мең тонна сөт савылган, 527,1 мең тонна терлек һәм кош ите (тере үлчәмдә), 1 537,9 млн данә йомырка җитештерелде.

**2022 елда авыл хуҗалыгы продукциясе күләме**




## Төзелеш

Төзелеш эшләре күләме 573,1 млрд сум тәшкил итте, ягъни 2021 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 120,4 %. Гомуми торак мәйданы 3 093,4 мең кв. м (2021 ел дәрәҗәсенә карата 102,7%) эксплуатациягә тапшырылды.


**2022 елда «Төзелеш» эшчәнлек төре буенча эшләр күләме**




## Кулланучылар базары

Ваклап сату әйләнеше 1 216,3 млрд сум тәшкил итте, ягъни 2021 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 96,9%.

**2022 елда ваклап сату әйләнеше**





Халыкка түләүле хезмәтләр күләме - 343,5 млрд сум (2021 ел дәрәҗәсенә карата бәяләрдә 103,3 %), җәмәгать туклануы әйләнеше - 54,7 млрд сум (103,6 %).

**2022 елда халыкка түләүле хезмәтләр күләме**




**2022 елда җәмәгать туклануы әйләнеше**




2022 елның декабрендә кулланучылар бәяләре индексы 2021 елның

декабренә карата 111,4% тәшкил итте, шул исәптән азык-төлек товарларына - 111,1%, азык-төлек булмаган товарларга - 111,4 %, хезмәт күрсәтүләргә - 111,7 %.

Татарстан Идел буе федераль округының инфляция темплары буенча 14 төбәк арасында 11 нче урында тора (1 нче урында - Ульяновск өлкәсе (113,5%), 14 нче урында - Мордовия Республикасы (110,8%).

## СӘНӘГАТЬ

Республикада импорт компонентларын алыштыру һәм продукция тәкъдим итү максаты белән республика предприятиеләренә җирле җитештерүчеләр белән кооперациядә ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында җитештерелә торган продукцияне базарларга чыгару эшен оештыру турында» 2019 елның 5 мартындагы ПУ-157 номерлы Указы белән төзелгән Республика маркетинг үзәге (rmcrt.ru) (алга таба – РМҮ) базасында эшли торган үз импорт алыштыру базасы булдырылды.

Тармак министрлыклары тәкъдимнәре нигезендә һәм Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының Критик комплектлау әйберләрен җитештерүне үстерү мәсьәләләре комиссиясе утырышының 2022 елның 21 апрелендәге 68-ОВ/12 номерлы беркетмәсе белән расланган сәнәгать тармаклары өчен кирәкле критик комплектлау әйберләре исемлеген исәпкә алып, чит ил дәүләтләре һәм халыкара оешмалар ягыннан кертелгән чикләү чаралары шартларында импортны алыштыруны тәэмин итү өчен кирәкле продукция исемлеге төзелде (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы  б-1765 номерлы боерыгы белән расланды).

2022 елның мартында Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан Дәүләт мәгълүмат сәнәгать системасы базасында импортны алмаштыруның яңа онлайн сервисы эшли башлады. Аның ярдәмендә заказчылар товарлар сатып алуга запрослар урнаштырырга, ә тәэмин итүчеләр – өстәмә чыгымнарсыз, килештерүләрсез һәм арадашчыларсыз үзләренең бәя буенча тәкъдимнәрен һәм  аналогларын җибәрергә мөмкин.

Фәнни һәм мәгариф учреждениеләре, инжиниринг компанияләре белән эшләү дәвам итә, республикада һәм башка Россия төбәкләрендә альтернатив тәэмин итүчеләр булдыру мәсьәләсе эшләнә, Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән хезмәттәшлек ителә. Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы инициативасы белән 2022 елның августында автомобиль сәнәгатенең технологик куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен критик компонентлар һәм материаллар өлкәләре буенча 25 предмет эш төркеме булдырылды.

«Резинотехник эшләнмәләр» төркемен «Татнефтехиминвест-холдинг» АҖ генераль директоры Р.С. Яруллин җитәкли. Эш барышында товарны алмаштыруга кирәкле критик продукция исемлеге билгеләнде. Кирәкле компонентларны эзләү гамәлгә ашырыла, үз илебез җитештерүчеләре һәм продукция кулланучылар арасында үзара бәйләнешләр җайга салына.

Даими нигездә зур компанияләрнең тәэмин итүче көннәре һәм түгәрәк өстәлләр уздырыла, аларның максаты – зур заказчылар белән үзебезнең җитештерү компанияләре арасында хезмәттәшлекне җайга салу. Мондый чаралар ел дәвамында В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, «Сибур Холдинг» ГАҖ, «КАМАЗ» ГАҖ, «Россельмаш» ДК һәм башкалар белән үткәрелде.

### Нефть һәм газ химиясе комплексы

#### *Нефть чыгару сәнәгате*

2022 елда 34,5 млн тонна, шул исәптән В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ тарафыннан 27,4 млн тонна, кече компанияләр тарафыннан 7,15 млн тонна

нефть чыгарылды, бу 2021 ел белән чагыштырып караганда 3,5 процентка күбрәк.

Җитештерү процесслары белән идарә иткәндә углерод эзен киметү, калдыклар белән экологик имин эш итүне тәэмин итү, табигать экосистемаларының торышын өйрәнү һәм оператив контрольдә тоту мәсьәләләре мөһим аспект булып тора. Ел саен компания 23 параметр буенча 1 000 нән артык туфрак пробаларын тикшерде һәм 20 мең радиометрик үлчәү ясады. Тикшеренү эшчәнлеге кысаларында нәтиҗәле инновацияләр, шул исәптән биотехнологияләр эшләүгә зур игътибар бирелә.

***Нефть эшкәртү сәнәгате***

Нефть эшкәртү заводларында 22 млн тоннадан артык углеводород чималы эшкәртелде (шулардан «ТАНЕКО» акционерлык җәмгыятендә – 16,2 млн тонна, «ТАИФ-НК» акционерлык җәмгыятендә – 6,1 млн тонна), 1 079,9 млрд сумга продукция төяп җибәрелде, бу республика буенча төяп җибәрелгән товарларның, башкарылган эшләрнең һәм күрсәтелгән хезмәтләрнең гомуми күләменнән 41,2 процент тәшкил итә.

Эшкәртү тирәнлеген һәм ачык нефть продуктларын чыгаруны арттыру өчен «ТАИФ-НК» АҖ һәм «ТАНЕКО» АҖ компанияләре тарафыннан зур инвестиция проектларын гамәлгә ашыру дәвам ителә.

24 декабрьдә «ТАНЕКО» акционерлык җәмгыятендә комплекслы сынау режимында хуш исле углеводородлар җитештерелә башлады. Ароматика комплексы 2018 елдан этаплап файдалануга тапшырылган 8 технологик җайланмадан тора. Яңа җайланмалар бензол җитештерүне елга 60 мең тоннага кадәр арттырырга, шулай ук елына 150 мең тонна параксилол җитештерүне үзләштерергә мөмкинлек бирәчәк. Бу продуктларны нефть химиясе өчен чимал буларак «Татнефть» компанияләр төркеменең яңа производстволарында кулланырга планлаштырыла.

***Медицина максатларында кулланыла торган химик матдәләр һәм химик продуктлар, резиннан һәм пластмассадан эшләнгән әйберләр, дару чаралары һәм материаллар җитештерү***

«Түбән Кама нефть химиясе» ГАҖдә 2025 елга кадәр предприятиене үстерү буенча стратегик программаны гамәлгә ашыру дәвам итә. Аның төп проектлары:

полимерлар җитештерелә торган ЭП-600 яңа олефин (этилен) комплексы;

елга 200 мең тоннага кадәр галобутил каучуклар җитештерүне техник яңадан җиһазландыру;

линияле альфа-олефиннар җитештерүне модернизацияләү.

«Казаньоргсинтез» ГАҖ 2025 елга кадәр тәмамларга планлаштырыла торган түбәндәге инвестиция проектлары буенча эшне дәвам иттерә:

җитештерү куәтен елына 220 мең тоннага кадәр арттырып, түбән басымлы полиэтилен җитештерү һәм эшкәртү заводында «В» реакторын модернизацияләү;

пропан чималын эшкәртү мөмкинлеге өчен этилен заводы цехларын модернизацияләү;

елына 100 мең тоннага кадәр җитештерү куәтен арттыру буенча поликарбонатлар заводларын модернизацияләү;

«СИБУР» компаниясе тарафыннан катализаторлар, урта һәм аз тоннажлы химия җитештерү буенча проектлар әзерләнә.

2022 елның 31 августында «Алабуга» СЖТ МИЗ» АҖ һәм «Түбән Кама нефть химиясе» ГАҖ Татарстан нефть-газ химиясе форумында импортны алыштыра торган яңа производстволар ачу өчен «Этилен 600» индустриаль паркы территориясендә сәнәгать-җитештерү эшчәнлеген алып бару турындагы килешү имза куйдылар. Шул ук вакытта «Түбән Кама нефть химиясе» ГАҖ тарафыннан чыгарыла торган продукциянең спектры катнаш тармаклардагы производстволарны үстерү өчен киң мөмкинлекләр тудыра, ә парк резидентлары өчен чимал китерүгә логистика чыгымнарының фактта булмавы аларның продукциясенең конкурентлык сәләтен сизелерлек арттырырга мөмкин.

«Северные ворота» индустриаль паркы территориясендә («Казаноргсинтез» ГАҖ) сәнәгать-җитештерү эшчәнлеген алып бару турында килешүгә имза кую буенча эш алып барыла.

В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ терефталь кислотасы, аммиак, ЛАБ (линияле алкилбензол) һәм АБСК (алкилбензолсульфокислота) җитештерү буенча проектларны гамәлгә ашыру мөмкинлеген карый.

«Татшина» ҖЧҖ тарафыннан 12,3 млн шин җитештерелде. Предприятие җитештерүне модернизацияләүне, продукцияне диверсификацияләүне дәвам итә, квадрацикллар өчен шинлар җитештерелә башлады, илкүләм проектларда һәм экологик инициативаларда катнаша.

«Нәфис косметикс» АҖ көнкүреш химиясе һәм техник продукция җитештерүне киңәйтү һәм техник җиһазлау буенча инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга, продукциянең яңа төрләрен чыгаруны оештыруга, шулай ук склад логистикасын үстерүгә һәм камилләштерүгә һәм склад техникасын яңартуга 1,2 млрд сум акча җибәрде. Импортны алыштыру буенча проектлар гамәлгә ашырыла. Предприятие базарга «BiMAX Арома Мистери» кер юу чарасы, дача бәдрәфләре өчен начар исләрне бетерә торган Sorti порошоксыман чарасы кебек яңа продуктлар чыгарды, Sorti сәүдә маркасы астында кер юу капсулалары ассортиментын киңәйтте.

«Аммоний» АҖ зур тоннажлы аммиак (елга 1,2 млн тонна), метанол (елга 0,5 млн тонна) һәм карбамид (елга 1,4 млн тонна) җитештерү буенча «Аммоний 2» проектын гамәлгә ашыруны дәвам итте.

«Казан синтетик каучук заводы» АҖ дәүләт оборона заказын үтәүне һәм граждан билгеләнешендәге продукция чыгаруны киңәйтүне дәвам итте.

«Татхимфармпрепаратлар» АҖ чыгарыла торган продукция ассортиментын киңәйтү һәм импортны алыштыра торган дару препаратларын базарга чыгару максатыннан таблеткалар һәм күгә сала торган ике яңа дару препараты рәвешендә өч яңа дару препаратлары җитештерүне үзләштерде; ике актив фармацевтика субстанциясенә теркәлү таныклыгы алды, таблеткаларны каплау җайланмасын файдалануга тапшырды һәм эшләтеп җибәрде.

«СИЛИКОН» ҖЧҖ «Казан синтетик каучук заводы» АҖ мәйданчыгында кремнийорганик материаллар җитештерү буенча проектны гамәлгә ашыруны яңадан дәвам итте.

Моннан тыш, полимерлар эшкәртү буенча проектлар гамәлгә ашырыла:

«ДАНАФИЛМЗ» ҖЧҖ икенчел эшкәртү өчен яраклы яңа буын пленка материаллары җитештерү;

«КАО Поволжье» ҖЧҖ тарафыннан пенополистиролдан форма эшләнмәләре җитештерү;

«АЙ-ФЛЭКС» ҖЧҖендә азык-төлек продукциясе һәм көнкүреш техникасы өчен сыгылмалы төргәкләр җитештерү;

«Техстрой» ҖЧҖендә төрле диаметрлы полимер торбалар һәм фитинглар җитештерү;

«СИМПЛ» ҖЧҖендә полипропилен торбалар, фитинглар, XPS-плиталар һәм башка материаллар җитештерү;

«Тасма» ФҖП ҖЧҖендә инновацион күпкатлы пленкалар җитештерү;

«Чистай пластмасса заводы» ҖЧҖ тарафыннан пластмассалардан эшләнмәләр җитештерү.

**Энергетика комплексы**

Республика энергетика системасы Урта Идел берләштерелгән энергетика системасының электр куллану территориаль структурасында иң зурысы булып тора.

Электр энергиясе җитештерүчеләр арасыннан иң зурлары – «Татэнерго» АҖ, «ТГК-16» АҖ, «Түбән Кама ТЭЦ» ҖЧҖ.

Иң зур электр челтәре оешмасы – «Челтәр компаниясе» АҖ. 2023 елның 1 гыйнварына 18 территориаль челтәр оешмасы эшли.

«Татэнергосбыт» АҖ гарантия бирә торган тәэмин итүче булып тора.

Энергетика системасының эш режимнары белән оператив-диспетчерлык идарә итү эшчәнлеген «СО ЕЭС» АҖ филиалы «Татарстан Республикасы энергосистемасының төбәк диспетчерлык идарәсе» (алга таба – Татарстан ТДУ) башкара.

2020 елда республиканың энергия системасы кулланучыларны ышанычлы һәм куркынычсыз энергия белән тәэмин итте. Татарстанның ТДУ мәгълүматлары буенча, бүленгән генерация объектларын исәпкә алып, электр энергиясе җитештерү 2021 ел дәрәҗәсенә 4,7 процентка артты һәм бу 28,1 млрд кВтч, куллану 33,0 млрд кВтч тәшкил итте, бу 2021 елга караганда 3,5 процентка күбрәк.

Республиканың барлык кулланучыларын электр һәм җылылык энергиясе белән ышанычлы тәэмин итү, шулай ук конкурентлык сәләтен арттыру һәм энергетика тармагын тотрыклы үстерүне тәэмин итү өчен энергия системасының җитештерү объектларын модернизацияләү һәм яңа куәтләр кертү беренче дәрәҗәдәге әһәмияткә ия.

Соңгы елларда Татарстанда, шул исәптән җылылык станцияләрен модернизацияләүнең федераль программасы (куәт бирү турындагы шартнамә буенча, КБШ), 4 энергетика станциясе модернизацияләнде. Бу энергия системасының куәтен 1,2 ГВтка, шул исәптән «Татэнерго» АҖ Казан ТЭЦ-1 һәм ТЭЦ-2, «ТГК-16» АҖ Казан ТЭЦ-3, «Түбән Кама ТЭЦ» ҖЧҖ станциясе арттырды.

Бүленгән генерация проектлары гамәлгә ашырыла («Сибур Холдинг» ГАҖ). «Түбән Кама нефть химиясе» ГАҖнең 495 МВты куәтле пар-газ җайланмасы төзелеп бетте һәм файдалануга тапшырылды. «Түбән Кама ТЭЦ» ҖЧҖндә Түбән Кама ТЭЦда (ПТК-2) 155 МВт куәтле газ-турбина җайланмасын төзү планлаштырыла.

«Татэнерго» АҖ Яр Чаллы ТЭЦында 230 МВт куәтле пар-газ җайланмасын төзү карала (җылылык электр станцияләренең генерацияләү объектларын модернизацияләү буенча федераль программага кертү юлы белән).

Өстенлекле юнәлешләр арасында – углеродсыз энергетиканы, аерым алганда, җил энергетикасын үстерү. Берничә килешүгә кул куелды.

«Челтәр компаниясе» АҖ электр челтәре хуҗалыгын модернизацияләү дәвам итте. Төп инвестиция проектлары: Тойма-2 220 кВ ЯС реконструкцияләү; Азино 110 кВ ЯС реконструкцияләү; Прикамская 110 кВ ЯС реконструкцияләү.

*Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү.* Татарстан Республикасында 2013 елдан «Татарстан Республикасында энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру» ярдәмче программасы гамәлгә ашырыла. Программаның төп индикаторы булып Татарстан Республикасының тулаем төбәк продуктының энергия сыйдырышлылыгын киметү тора. 2021 ел йомгаклары буенча әлеге индикаторның күрсәткече 20,23 т.у.т./млн сум тәшкил итте (2007 елга 26,2 процентка кимеде)

Квартал саен муниципаль районнар һәм шәһәр округлары, шулай ук тармак министрлыклары яктылыгында бюджет өлкәсендә энергия ресурсларын нәтиҗәлелеге куллану буенча ирешелгән күрсәткечләргә мониторинг уздырыла.

Хәзерге икътисадый шартларда мөһим юнәлеш – энергия ресурсларын нәтиҗәлелеге куллану проектларын гамәлгә ашырганда бюджеттан тыш финанслауны, шул исәптән энергия сервисы контракты (алга таба – ЭСК) механизмы аша җәлеп итү. Төзелгән ЭСК кысаларда автоматлаштырылган индивидуаль җылылык пунктлары, һава торышына карап җайга салу узеллары урнаштырыла, урам яктырту һәм эчке яктырту җайламасы модернизацияләнә. Барлыгы бюджет өлкәсендә 1 662 млн сумлык гомуми суммага 94 ЭСК, шулардан 2022 елда 16 млн сумга 6 ЭСК төзелде. 2022 ел йомгаклары буенча әлеге механизм энергия ресурсларын 232,1 млн сумга экономияләргә мөмкинлек бирде.

Энергияне саклауны популярлаштыру һәм пропагандалау, энергия ресурсларын нәтиҗәле куллануны арттыру, шулай ук «Татарстан Республикасында энергия ресурслары нәтиҗәлелеге» дәүләт программасы чараларын үтәү максаты белән ел саен энергетика һәм энергия ресурслары нәтиҗәлелеге буенча Татарстан халыкара форумы уздырыла. 2022 елда аның кысаларында «Энергетика. Ресурсларны саклау» XXII Халыкара махсуслаштырылган күргәзмә һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «2021 елда «Татарстан Республикасында энергия ресурслары нәтиҗәлелеге» дәүләт программасын гамәлгә ашыру барышы һәм 2022 елга бурычлар турында» утырышы үткәрелде.

Күргәзмәдә Россия Федерациясенең 10 төбәгеннән 34 компания һәм Татарстаннан 29 компания тарафыннан 63 экспозиция тәкъдим ителде. Форум кысаларында энергетика нәтиҗәлелеген арттыру, ягулык-энергетика комплексын үстерү, энергиянең, водород энергетикасының альтернатив чыганакларын куллану, газ-мотор ягулыгы базарын үстерү, энергетика комплексында цифрлаштыру, электр транспорт чараларын һәм зарядка инфраструктурасын куллану мәсьәләләре буенча 23 чара, шулай ук мәктәп укучылары, студентлар һәм энергетика компанияләре яшьләре катнашында Яшьләр көне үткәрелде.

Форумда якынча 4 000 кеше катнашты.

***Газлаштыру һәм газ белән тәэмин итү***

17 776 млн куб. м, ягъни 2021 ел дәрәҗәсенә карата 97,4 % табигый газ кулланылды.

2022 елда 2025 һәм 2030 елларга фараз белән республиканың ягулык-энергетика балансы белән эшләнде, Газ белән тәэмин итүнең һәм газлаштыруның генераль схемасы актуальләштерелде.

Республикада торакны газлаштыру дәрәҗәсе 99,5 % тәшкил итте. Социаль газлаштыру программасын гамәлгә ашыра башлаганнан бирле (2021 елның III кварталы) 12 700 йорт чикләренә кадәр газүткәргеч үткәрелде, шулардан 6 942 йорт газга тоташтырылды.

Татарстанда *газ-мотор ягулыгы базары* актив үсеш ала. Узган елда 7 яңа газ салу станциясе һәм автотранспорт чараларына сыек һәм газ хәлендәге мотор ягулыгы сала торган 2 объект кулланышка кертелде. Автомобильләргә газ салу компрессор станцияләренең төзелгән челтәренең гомуми проект җитештерүчәнлеге елына кысылган табигый газның 374 млн куб. м артык тәшкил итте (барлыгы 44 АГСКС).

Моннан тыш, елына 25 000 тонна суммар куәт белән табигый газны сыекландыру буенча 2 комплекс файдалануга тапшырылды. Автотранспорт чараларына сыек һәм газ хәлендәге мотор ягулыгы сала торган 4 объект эшли.

72,2 млн куб. м артык кысылган табигый газ һәм якынча 8,0 мең тонна сыекландырылган табигый газ сатылды.

13,0 мең берәмлектән артык газ-мотор техникасы, шул исәптән сыекландырылган табигый газ белән эшли торган 214 техника эксплуатацияләнә.

**Машиналар төзү комплексы**

Машиналар төзү комплексы предприятиеләре тарафыннан 921,0 млрд сумга товар продукциясе төяп җибәрелде, бу республика буенча төяп җибәрелгән товарларның, башкарылган эшләрнең һәм күрсәтелгән хезмәтләрнең гомуми күләменнән 20,3 % тәшкил итә.

Тармакның эш нәтиҗәләре, беренче чиратта, «КАМАЗ» ГАҖ күрсәткечләре белән билгеләнә, 2022 елда анда 44,8 мең автомобиль чыгарылды. Предприятиенең фәнни-техник үзәге конструкторлары «Юпитер 30» исеме бирелгән КамАЗ-6559 уникаль самосвал эшләп чыгардылар – бу карьер эшләрен башкару өчен билгеләнгән пилотсыз машина (көпшәк тау массасы яки руда ташу).

Бу елда чыгарылган яңа әйбер – ул «Компас» аз тоннажлы йөк машиналары. Проект нигезендә ике модель: тулы массасы 9,5 тонна булган «Компас-9» һәм 11,99 тонналы «Компас-12» чыгарыла башланды. Болар – шәһәр һәм шәһәр бистәсе өчен, кайвакыт шәһәрара ташулар өчен тарату классындагы машиналар. Бу автомобильләрнең версияләре төрле махсус өстәмә җайланмалар өчен кулланылырга мөмкин. Алга таба тагы да компактлырак һәм җиңелрәк булган «Компас-5» (тулы массасы 5,5 тонна) һәм «Компас-6» (6,0 тонна) модельләрен базарга чыгару планлаштырыла. Яңа семьялыкта иң җиңел машина «Компас-3» (3,0 тонна) булачак.

2022 елгы Петербург халыкара газ форумы кысаларында «Газпром» ГАҖ

заказы буенча эшләнгән КамАЗ-6250 тулы приводлы инновацион автобус-вездеход тәкъдим ителде.

2023 ел башында КамАЗ-54901 дигән беренче яңартылган магистраль йөк машинасы җыелды.

Россия Федерациясендә, партнерлар белән берлектә, К5 нче буын автомобильләрен локальләштерү кысаларында кайбер импорт компонентларын җитештерү үзләштерелде. Локализацияләнә торган компонентларның шактый өлеше республика территориясендә җитештерелә. Мәсәлән, Россия Федерациясендә К5 буын автомобильләре кабинасы каркасы өчен кабиналар каркасларын штамплы җиһазландыру һәм аларның детальләрен җитештерү, кайнар штамповка детальләрен, импорт корычтан эшләнгән детальләрне локальләштерү оештырылды.

2023 елга К5 автомобильләренең модель рәтен яхшыртылган кулланучылар характеристикалары булган санкциягә тотрыклы компонент базасында киңәйтү планлаштырыла.

«Соллерс» ГАҖ Татарстанда үз проектларын гамәлгә ашыруны дәвам итә. 2022 елда компания «Алабуга» СҖТ МИЗнда «СОЛЛЕРС» дигән үз бренды исеме белән җиңел коммерцияле автомобильләр линейкасын җитештерүне башлап җибәрде. Автомобильләр сатуга декабрьдә чыгарылды.

«СОЛЛЕРС Атлант» һәм «СОЛЛЕРС Арго» автомобильләре махсус версияләр өчен, шул исәптән ашыгыч медицина ярдәме автомобильләре, мәктәп автобуслары, сәнәгать товарлары фургоннары, рефрижераторлар һәм башка модификацияләр кебек социаль әһәмияттәге база транспорт чаралары булачак. Компаниянең фәнни-техник үзәге, партнерлар белән берлектә, 130 дан артык махсус версия эшләде.

2023 елдан «СОЛЛЕРС Алабуга» ҖЧҖ автомобильләрнең яңа линейкасын җитештерүне локальләштерүнең масштаблы программасын башлап җибәрәчәк, ул дизель двигательләрен (күләме 2 л һәм 2,7 л) җитештерүне (детальләр коюны һәм аларны механик эшкәртүне, төп электрон компонентларны, шасси элементларын, пластик эшләнмәләрне штамплы җитештерүне, локальләштерүне кертеп) үз эченә алачак.

Ноябрь аенда «АУРУС» ҖЧҖ тарафыннан AURUS – Komendant брендының икенче автомобиле, АУРУС вәкиллек классындагы автомобильләр күпләп җыела башланды (куәте елына 5 000 автомобильгә кадәр җитештерергә мөмкинлек бирә).

«АйСиЭл Техно» ҖЧҖендә 270 меңнән артык эшләнмәләр (шәхси компьютерлар, моноблоклар, ноутбуклар, серверлар, мәгълүмат саклау системалары, интерактив панельләр) чыгарылды. 2023 елда «Иннополис» МИЗда басма платалар өстен монтажлау һәм әзер эшләнмәләрне җыю буенча яңа завод эшләтеп җибәрү планлаштырыла.

«ЕлАЗ ЖБ» АҖ үз җитештерүендәге дүрт күчәрле ярымтагылма базасында нефть һәм газ скважиналарын ремонтлау һәм бораулау өчен йөк күтәрүчәнлеге 100 тонна булган УПР-100 мобиль күтәрү җайланмасының яңа модификациясен үзләштереп бетерде. Предприятие үз җитештерүендәге махсус үзйөрешле платформа базасында скважиналар ремонтлау һәм бораулау өчен АПР-80С күтәрү агрегатының яңа модификациясенең төп үрнәген эшләде һәм ясап

чыгарды. Конструкциягә түбәндәге яңалыклар кертелү нәтиҗәсендә яңа эшләп чыгарылган агрегат яхшыртылган техник-икътисадый параметрларга һәм эксплуатация технологик күрсәткечләргә ия:

көч агрегатыннан механик куәтне сайлап алуның яңа, гадиләштерелгән схемасы кертелде, көчлерәк технологик узелларны: тапшыру тартмаларын, тарату һәм реверсия редукторларын куллану исәбенә югары җиһаз приводы трансмиссиясе оптимальләштерелде;

техник хезмәт күрсәтүне җиңеләйтә торган югары җиһаз компоновкасы яхшыртылды.

ELAZ-BL йөк төяү экскаваторларын локальләштерү чаралары кысаларында импорт йөк төяү экскаваторы урынына куллану максатларында «ЯМЗ» маркалы двигателен ELAZ-BL йөк төяү экскаваторларына кую буенча тәҗрибә-конструкторлык эшләре уңай нәтиҗә бирде, әлеге двигательле техниканың пилот партиясе җитештерелә башлады.

Декабрь аенда «ИНКОМСИСТЕМ» фәәни-инженерлык үзәге ябык акционерлык җәмгыяте АБАК, АБАК ПЛК контроллерларын җитештерү буенча автомат линияләрне эшләтеп җибәрде.

«КАМА ДИЗЕЛЬ» АҖ Сәнәгать үсеше фонды ярдәме белән двигательләр компонентларын локальләштерү проектын гамәлгә ашыра башлады.

«Инженерлык-җитештерү үзәге» ҖЧҖ предприятие эшчәнлегенең перспективалы юнәлешләрен киңәйтү кысаларында чыгарыла торган продукциянең номенклатурасын арттыру һәм аларның яңа төрләрен эшләү буенча тәҗрибә-конструкторлык эшләрен алып барды (полиэтилен-корыч торбаларны аерып алмыйча тоташтыру (күчү) һәм газ бүлү системалары өчен цокольдән үткәрү).

«НАЧАЛО» ҖБ ҖЧҖ LadaVesta автомобильләре өчен барабан тормозы колодокларының яңа комплектларын реализацияли башлады.

«ЦФ КАМА» ҖЧҖ трансмиссияләр җыюны гына түгел, ә мөстәкыйль рәвештә аларның компонентларын (тешле тәгәрмәчләр һәм әйләнмәле үзәкләр) җитештерә, чит компанияләр өчен детальләрне механик эшкәртүне гамәлгә ашыра, трансмиссияләр компонентларын локальләштерү проектларын алып бара.

«Эйдос-Робототехника» ҖЧҖ тарафыннан «КАМАЗ» ГАҖдә эретеп ябыштыра торган роботны гамәлгә кертү буенча пилот проекты уңышлы төгәлләде, тәҗрибәсе уңышлы тиражлана.

«РИАТ» ААҖ «РИАТ-Кран» кран-манипулятор җайланмасының тәҗрибәле үрнәген эшләде.

«РИМЕРА-АЛНАС» ҖЧҖ берничә инвестиция проектын, шул исәптән үз көчләре белән сынаулар стендларын җитештерүне үзләштерү, комлы полимер формалар булдыру өчен заманча аддитив җайланманы эштә куллана башлау проектларын гамәлгә ашырды. Кыска вакыт эчендә заводның кою цехы стержень чыгаруның яңа аддитив технологияләрен куллануга кереште. Фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре алып барыла. Предприятие вентиль электр двигательләренең, электр үзәктән куу насосларының яңа модельләрен һәм яңа буынны гидросаклагычларны эшләп чыгарды. Альтернатив юнәлешләр – автомобиль сәнәгате өчен номенклатур линейканы киңәйтү эшләнә. Ел йомгаклары

буенча тормоз дискларының өч яңа төрен җитештерү үзләштерелде, планда – тагын дүртне эшләү һәм үзләштерү.

**Оборона-сәнәгать комплексы**

Оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре дәүләт заказын үтәүне уңышлы тәэмин итә.

С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы – «Туполев» ГАҖ филиалы ике (яңа әзерләнгән һәм яңартылган) стратегик ракета йөртү аппаратын очу сынауларына тапшырды. Тагын ике самолет соңгы җыю цехына тапшырылды.

Республика пассажирлар йөртүченең Ту-214 дүрт пассажир самолетын ясауга заказы үтәлә.

«Аэрофлот» компаниясе белән 40 самолетка ниятләр турында килешүгә имза куелды.

«Казан вертолет заводы» АҖ тарафыннан «Ансат» вертолеты өчен яңа буын канатлары әзерләнде.

«Радиоприбор» АҖ тарафыннан МС-21 һәм «Сухой Суперджет-100» самолетлары идарәсе системаларының өлешләрен җитештерү үзләштерелә.

«КАПО-Композит» АҖ үз илебезнең материалларыннан эшләнгән МС-21 пассажир лайнеры канатын механикалаштыру элементларын һәм агрегатларын серияле чыгара башлады.

«А.М. Горький исемендәге Зеленодольск заводы» АҖндә 7 кораб һәм судно, шул исәптән «Метеор» тизйөрешле судно төзелеп елгага төшерелде. Россиядә водород ягулыгында эшли торган беренче судно төзелә башлады.

«ПОЗиС» АҖ «Ростех» дәүләт корпорациясе предприятиеләре өчен стандарт булмаган җиһазлар әзерләү буенча бердәм үзәккә әверелде.

«Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе» АҖ җитештерүендәге газ турбиналы двигательләр белән эшли торган газ кудыру агрегатлары Ковыкта ятмасыннан газ кабул итү өчен билгеләнгән Чаянда ятмасы станциясендә уңышлы файдалануга тапшырылды. «Себер көче» газүткәргеченең Ковыкта – Чаянда участогында эшләрне башлап җибәрү өчен декабрь аенда Россия Федерациясе Президенты тарафыннан старт бирелде. Предприятиедә газ турбиналы двигательнең цифрлы игезәген булдыру программасы гамәлгә ашырыла һәм аның бер этабы – яну камерасын модернизацияләү төгәлләнде, ул елның салкын вакытында двигатель эшләп чыгара торган файдалы гамәл коэффициентын арттырырга мөмкинлек бирде.

**Урман эшкәртү сәнәгате**

Урман эшкәртү сәнәгатендә сәнәгать җитештерүе күләме 75,2 млрд сум тәшкил итте.

«Агач эшкәртү һәм агачтан һәм бөкедән эшләнмәләр (җиһаздан тыш) җитештерү, саламнан эшләнмәләр һәм үрү өчен материаллар җитештерү» икътисадый эшчәнлек төре буенча төяп җибәрелгән продукция күләме – 26,7 млрд сум, «Кәгазь һәм кәгазь эшләнмәләр җитештерү» буенча – 44,9 млрд сум, «Җиһаз җитештерү» буенча 3,6 млрд сум тәшкил итте.

«Кастамону Интегрейтед Вуд Индастри» ҖЧҖ 1,1 млн куб. м еллык

җитештерү күләме белән ДСП (агач йомычкалар плитәсе) җитештерү заводын төзүне дәвам итте. 2021 елда төзелә башлады, 2024 елның II кварталында эшләтеп җибәрергә планлаштырыла. Заводның корпусларын күтәрү буенча төзелеш эшләре төгәлләнде.

Kastamonu компаниясе тарафыннан Evogloss линейкасындагы МДФ-плиталарның (тыгызлыгы уртача дәрәҗәдә булган агач җепселле плитәләрнең) яңа декорлары эшләп чыгарылды. Әгәр Evogloss МДФ-плиталар линейкасының яңаларын чыгарганга кадәр 74 декор булса, хәзер аларның саны 81гә кадәр җитте. Ламинат идәннәр линейкасы киңәйтелде. Floorpan флагман линейкасы Nanoclick һәм Amber исемендәге 33 нче класс тузуга чыдамлылыкта булган яңа коллекция белән тулыландырылды.

«Татарстан агач эшкәртү комбинаты» ҖЧҖ җитештерү эшендә яңа җиһаз – йомшарта торган күчәрсез һәм кайры чистарткыч станокларны кулланышка кертте, бу шпон чыгарылышын арттырырга һәм чимал чыгымы коэффициентын киметергә мөмкинлек бирде. Берничә перспективалы проектлар, шул исәптән эш урыннарын оештыру проекты башлап җибәрелде, алар оешманың күрсәткечләрен яхшыртты. Ел ахырына «Җиһаз» сегментында ассортимент матрицасы 289 товар позициясенә кадәр арттырылды. 2023 елга планда – 1 400 товар позициясенә кадәр арттыру.

«С.П. Титов исемендәге Яр Чаллы картон-кәгазь комбинаты Халык предприятиесе» хезмәткәрләр ЯАҖ, «Хаят Кимья» ҖЧҖ, «ПАЛП Инвест» ҖЧҖ, «Драйлок Текнолоджиз» ҖЧҖ һәм «НЕГА» АҖ кебек зур предприятиеләр республиканың целлюлоза-кәгазь сәнәгатен тәшкил итә.

Август аенда «С.П. Титов исемендәге Яр Чаллы картон-кәгазь комбинаты Халык предприятиесе» хезмәткәрләр ЯАҖ гофротараның күп ярусл автоматлаштырылган складының беренче чираты файдалануга тапшырылды (проект 16 мең паллет-урынга исәпләнгән). Яңа склад кран-штабелерлар белән һәм Fast Ring дип аталган шаттллы монорельслы транспорт системасы белән җиһазландырылды.

«Хаят Кимья» ҖЧҖ, технологик мохитләр агымнарын өзлексез анализлый торган заманча җиһаз һәм төп чималның – целлюлоза җепселләренең үзлекләрен тикшерә торган җиһаз урнаштырып, үзенең фәнни-тикшеренү потенциалын көчәйтте.

«Драйлок Текнолоджиз» ҖЧҖ 11,5 мең кв. м мәйданлы склад бинасы төзеп бетерде, аның кыйммәте – якынча 600 млн сум. Март аенда балалар өчен подгузник-трусиклар җитештерү линиясе яңартылды, ул линия эшенең тизлеген минутына 500 данәгә кадәр арттырырга мөмкинлек бирде.

**Җиңел сәнәгать**

Республиканың җиңел сәнәгать предприятиеләре 10,7 млрд сумлык продукция төяп озатты.

Ел дәвамында читтән кертелә торган текстиль продукциясен, тукымаларны, чыгым материалларын һәм җиһазларны алыштыру, яңа җитештерү чылбырларын булдыру, логистика юлларын эзләү, шулай ук кадрларга ихтыяҗлар һәм тармакка ярдәм итү чаралары мәсьәләләре тикшерелде, эшмәкәрләр белән эшлекле очрашулар оештырылды.

«Полиматиз» АҖ «спанбонд» һәм «мелтблаун» технологияләре буенча заманча тукылмаган материаллар, төзелеш мембраналары җитештерә һәм сата. Декабрь аенда яңа линиядә композитлы тукылмаган материаллар – диварлар, түбәләр җылыткычы һәм биналарның төп элементларын конденсаттан, дымнан һәм җилдән саклау сыйфатында файдаланыла торган ике катлы һәм өч катлы мембраналар чыгару җайга салынды.

«Эластик заводы» ҖЧҖ төрле сәнәгать тармаклары (медицина, авыл хуҗалыгы, төзелеш, автомобиль төзелеше һ.б.) өчен тукылмаган материаллар эшләп чыгара.

«Эластик заводы» ҖЧҖ һәм «Здравмедтех» ҖЧҖ арасындагы стратегик партнерлык бер тапкыр кулланыла торган хирургия киеменең киң спектрын, бер тапкыр кулланыла торган эчке киемне һәм инфекционист табиблар өчен саклау комплектлары базарга чыгарырга мөмкинлек бирде.

«Бикотекс» ҖЧҖндә төп җитештерү цехы – җепне формалаштыру һәм текстурлаштыру цехы эшләтеп җибәрде. Тегү цехының җитештерү мәйданнары арттырылды. Предприятие «МЕДИН-Н» ҖЧҖ компаниясенең атравматик энәләр һәм җөй хирургия материалын җитештерү буенча Россия лидеры өчен хирургия җөй җепләре белән рәсми тәэмин итүчегә әверелде.

«Алсу» Әлмәт оек-оекбаш фабрикасы» ҖЧҖ – Россиядә оек-оекбаш эшләнмәләрен иң эре җитештерүчеләрдән берсе. 2003 елдан башлап, фабрика эшләнмәләре «Носкофф» сәүдә маркасы астында чыгарыла һәм илнең 30 дан артык төбәгенә җибәрелә. Ассортиментка трикотаж эшләнмәләр өстәлде, шулай ук оек-оекбаш эшләнмәләренең яңа төрләре, шул исәптән компрессия оеклары эшләп чыгарылды.

«Кукмара тегү фабрикасы» АҖ – балалар һәм зурлар өчен плащлар, курткалар, сүүткәрми торган итеп эшкәртелгән тукымалардан тегелгән пәлтәләр чыгаруда махсуслашкан тармакның әйдәп баручы предприятиеләреннән берсе. Предприятиедә ел саен 70 тән артык яңа модель эшләнә һәм тегелә.

«Кукмара киез итек комбинаты» АҖ традицион киез итекләр белән беррәттән декоратив элементлар белән резиналанган табанлы киез аяк киеменең заманча модельләрен, шулай ук өлкәннәр һәм балалар өчен натураль йоннан ясалган эшләнмәләр чыгара. Ел каталогына киездән тегелгән яшьләр аяк киеменең яңа линейкасы кертелде, шулай ук элек чыгарыла торган эшләнмәләрнең ассортименты төс гаммасы буенча киңәйтелде.

«Азнакай киемнәре» АҖ, «Бөгелмә тегү фабрикасы» ҖЧҖ, «Спецодежда-НЧ» ҖЧҖ һәм «Кама Аланы тегү фабрикасы» ҖЧҖ – зур һәм төзелеш компанияләре өчен дә, мәгариф һәм сәламәтлек саклау оешмалары өчен дә махсус сеңдергечләрдән: суны этәрә торган, майга, суга, утка чыдам булган һәм җилдән саклый торган тукымалардан эшләнгән махсус кием чыгару буенча төп предприятиеләр.

2022 елның икенче яртыеллыгында «Азнакай киемнәре» АҖ Баулы шәһәрендә һәм Җәлил шәһәр тибындагы поселогында яңа тегү цехлары ачу исәбенә җитештерүне киңәйтте.

«Бөгелмә тегү фабрикасы» ҖЧҖ сату күләмен 2 тапкырга арттырды.

Мәктәп формасын эшләп чыгару – «ИРЭН» тегү остаханәсе» ҖЧҖ,

«Унисервис-Уңыш+» ҖЧҖ (Казан шәһәре), «Бросско» ҖЧҖ, «Мәктәп Модасы» ҖЧҖ, «Триада» ҖЧҖ (Яр Чаллы шәһәре), «Түбән Кама тегү фабрикасы» ҖЧҖ (Түбән Кама шәһәре) эшчәнлегендә төп юнәлешләрнең берсе.

«Бросско» ҖЧҖ Татарстанның һәм Россиядәге башка төбәкләрнең 150 дән артык уку йорты өчен укучыларга һәм укытучыларга, шулай ук корпоратив киемнәргә заказ бирүче эре һәм кече предприятиеләр өчен форма җитештерә. 2022 елда җитештерү күләме мәктәп формаларын күпләп тегү цехын реконструкцияләү һәм модернизацияләү, яңа җиһазлар сатып алу хисабына 50 процентка арттырылды.

Форма, корпорация, медицина киемнәре һәм мәктәп формалары җитештерүче «Триада» ҖЧҖ җитештерү күләмен 2,2 тапкырга арттырды.

**Эчемлекләр җитештерү**

Республикада азык-төлек чималыннан ректификацияләнгән 5,7 млн дал спирт (2021 ел дәрәҗәсенә карата 103,0 %), 9,3 млн дал аракы (113,0%), 55,1 млн дал сыра (100,1 %) җитештерелде.

«Татспиртпром» АҖ – Россия Федерациясендә иң эре алкоголь компанияләренең берсе. 2022 елда компания тарафыннан мәгълүмат технологияләре инфраструктурасын масштаблы яңартуга, технологик һәм җитештерү процессларын модернизацияләүгә һәм роботлаштыруга инвестицияләр арттырылды.

«АБ ИнБев Эфес» акционерлык җәмгыятенең Казан шәһәрендәге филиалы 500 млн сумнан артык бәягә заманча чистарту корылмалары төзү проектын гамәлгә ашырды.

Ноябрь аенда «Булгарпиво» ААҖ Kola (Кола), Orange (Оранж), Sprint (Спринт) кебек алкогольсез продукциянең яңа сортларын җитештерә башлады.

**«Хезмәт җитештерүчәнлеге» илкүләм проекты**

«Хезмәт җитештерүчәнлеге» илкүләм проекты, 2018 елдан башлап, оешмалар хезмәткәрләре арасында җитештерүчәнлеге һәм нәтиҗәлелеге югары булган культура булдырып, Россия товарларының һәм хезмәт күрсәтүләренең конкурентлыкка сәләтен арттыру максатларында гамәлгә ашырыла һәм хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру хисабына икътисад үсешен тулаем ил буенча кимендә 5 процентка арттыруга юнәлтелгән.

Республикада әлеге илкүләм проекты «Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру буенча системалы чаралар» һәм «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга адреслы ярдәм» дигән ике төбәк проекты кысаларында гамәлгә ашырыла.

«Системалы чаралар» төбәк проекты күбесенчә оештыру чараларына – остазлык конкурсының төбәк өлешен уздыруга, катнашучы предприятиеләрне күрсәтелгән ярдәм чараларына җәлеп итүгә һ.б. юнәлдерелгән.

«Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга адреслы ярдәм» төбәк проекты lean-технологияләр кертү, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру һәм хезмәткәрләрне укыту буенча иң яхшы тәҗрибәләрдән файдалану юлы белән сакчыл җитештерү культурасын кертү өчен хезмәт җитештерүчәнлеге өлкәсендә төбәк компетенцияләр үзәген төзүгә һәм аның эшчәнлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

«Татарстан Республикасы Энергия ресурслары нәтиҗәлелеге технологияләре үзәге» ДАУ базасында төзелгән Татарстан Республикасының Хезмәт җитештерүчәнлеге өлкәсендәге компетенцияләр төбәк үзәге тарафыннан адреслы ярдәм күрсәтелә.

2022 елда Төбәк үзәге «Хезмәт җитештерүчәнлеге өлкәсендәге компетенцияләр федераль үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасының кабат мәҗбүри сертификациясен уңышлы үтте һәм, ел йомгаклары буенча компетенцияләрнең төбәк үзәкләре рейтингында 3 нче урынны алып, илнең иң яхшы компетенцияләр төбәк үзәкләре өчлегенә стабиль керә.

Төбәк үзәге базасында практик тренинглар үткәрү өчен «Җитештерү процесслары фабрикасы» (2020 елда) һәм «Офис процесслары фабрикасы» (2021 елда) төзелде. Фабрикалар гамәлдә булганда 1,5 меңнән артык кеше, шул исәптән 2022 елда 458 кеше тренинглар узды.

2021 ел йомгаклары буенча Татарстан Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан формалаштырыла торган Россия Федерациясе субъектлары арасында хезмәт җитештерүчәнлеге рейтингында лидер төбәк дигән исем алды һәм аңа 2023 елда «Җитештерү 360» V федераль форумын үткәрү өчен өстенлекле хокук бирелде (2022 ел өчен рейтинг 2023 елның декабрендә төзеләчәк).

Татарстанда илкүләм проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре:

илкүләм проектта, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән килешү төзеп, 208 предприятие (шул исәптән 2022 елда – 62 предприятие) катнашты;

катнашучы предприятиеләрнең 3 566 хезмәткәренә (шул исәптән 2022 елда – 1 351 кеше) хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру инструментлары өйрәтелде;

катнашучы предприятиеләрнең 222 вәкиле (шул исәптән 2022 елда – 123 кеше) «Хезмәт җитештерүчәнлеге лидерлары» идарә кадрларын укыту программасын узды;

ел саен остазлык бәйгесе үткәрелде. Төбәк этабының «Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру өлкәсендә остазлык» номинациясендә «Софт пайп» ҖЧҖ; «Һөнәри үзбилгеләнештә остазлык», «Яшьләрне һөнәри үстерүдә остазлык», «Алдынгы технологияләр өлкәсендә остазлык» номинацияләрендә «Казан вертолет заводы» АҖ җиңү яулады.

Конкурсның федераль этабы йомгаклары буенча «Яшьләрнең һөнәри үстерүдә остазлык» номинациясендә «Казан вертолет заводы» АҖ җиңүче булды.

Моннан тыш, 2022 елда Төбәк үзәге тарафыннан «Сакчыл җитештерү» юнәлеше буенча 44 проект гамәлгә ашырылды.

**«Халыкара кооперация һәм экспорт» илкүләм проекты**

«Халыкара кооперация һәм экспорт» илкүләм проекты кысаларында

«Татарстан Республикасында халыкара кооперацияне һәм экспортны үстерү буенча системалы чаралар» һәм «АПК Экспорты» төбәк проектлары гамәлгә ашырыла.

«Татарстан Республикасында халыкара кооперацияне һәм экспортны үстерү буенча системалы чаралар» төбәк проекты кысаларында 15 инструменттан торган Төбәк экспорт стандарты 2.0 (алга таба – ТЭС 2.0) гамәлгә кертелә (экспорт эшчәнлеген үстерү өчен уңайлы шартлар тәэмин итү чаралары). Хәзерге вакытта Россия экспорт үзәге тарафыннан 13 инструментны гамәлгә кертү турында расланды. Инструментларның калганнарын кулланышка кертү дәвам итә.

Тышкы икътисадый мәнфәгатьләрне тәэмин итүнең нәтиҗәле инструменты – ул Татарстан Республикасының вәкаләтле, даими һәм сәүдә-икътисадый вәкиллекләренең эше.

Татарстан «Россия экспорт үзәге» АҖнең Экспорт мәктәбендә Экспортны үстерү буенча республика идарә командасын (команда составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 9 март, б-464 нче боерыгы белән расланды) түләүсез укытуда катнашу өчен конкурс нигезендә сайлап алынды. Уку биш модуль буенча үткәрелде. Экспортны үстерү буенча төбәк программасы проекты укуларның нәтиҗәсе булырга тиеш (2023 елның 1 июленә кадәр).

2022 елда беренче тапкыр чимал булмаган энергетикага карамаган экспорт өлкәсендә зур сәнәгать предприятиеләре өчен «Ел экспорты» конкурсы үткәрелде. «Сәнәгать өлкәсендә иң яхшы предприятие-экспортер» номинациясендә «КАМАЗ» ГАЖ, «Сәнәгать продукциясе экспорты өлкәсендә ел алдынгысы» номинациясендә «Нәфис Косметикс» АҖ җиңүче дип танылды.

Россия Федерациясе субъектларында ел саен «Ел экспортеры» конкурсын уздыру РЭС 2.0 – «Россия Федерациясе субъектының икътисадый актив халкы һәм яшьләре арасында экспорт эшчәнлеген популярлаштыру механизмнарын булдыру һәм үстерү» кораллары исемлегенә керә.

## АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ

Татарстан илнең 2 процентка якын авыл хуҗалыгы җирләрен били, 3,8% авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы республика авыл хуҗалыгы тармагының төп программа документы булып тора. Программада авыл хуҗалыгының, азык-төлек һәм эшкәртү тармагының максатлары, бурычлары, үсеш юнәлешләре, чаралары һәм аларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү, максатларга ирешүне характерлый торган һәм котелә торган нәтиҗәләр билгеләнә.

Кыр эшләрен планлаштыруны җиңеләйтү өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының агросәнәгать комплексы дәүләт мәгълүмат системасы гамәлгә кертелде. Бу – авыл хуҗалыгы җитештерүе этапларын нәтиҗәле файдалану, планлаштыру һәм контрольдә тоту, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне күзәтү һәм мониторинглау веб-сервисы.

2022 елда авыл хуҗалыгы предприятиеләре тарафыннан эшкәртелгәннән соң 5,21 млн тонна авырлыкта ашлык суктырылды, бу 2021 ел дәрәҗәсеннән 2,2 тапкырга күбрәк. Бу күләм он тарту һәм икмәк пешерү предприятиеләрен икмәк пешерү чималы, ә республика терлекчелеген – концентрацияләнгән азык белән тулысынча тәэмин итәргә мөмкинлек бирде.

Төп техник культурасы булган шикәр чөгендеренең тулаем җыемы 43,3 процентка артты һәм 1,9 млн тонна тәшкил итте. Эшкәртүгә юнәлдерелгән чөгендер-шикәр субкластеры җирле чимал белән тулысынча тәэмин ителде. 278,8 мең тоннадан артык яшелчә, 920,1 мең тоннадан артык бәрәңге җыелды.

Республика сөт җитештерү буенча – 1 нче урында, бәрәңге җыю буенча – 2 нче урында, сугымга терлек һәм кош ите җитештерү буенча – 8 нче урында, йомырка һәм ашлык җитештерү буенча – 9 нчы урында, шикәр чөгендере җитештерү буенча 10 нчы урында тора.

2023 ел уңышы өчен түбәндәге эшләр башкарылды:

чәчү мәйданнарын 2022 ел дәрәҗәсендә саклап калырга планлаштырыла;

2,0 млн га мәйдан туфракта төп эшкәртү эшләре үткәрелде;

бөртекле һәм кузаклы культуралар орлыклары белән тәэмин ителеш ихтыяҗның 126 процентын тәшкил итә;

472 мең га мәйданда уҗым культуралары чәчелде, аларның торышына мониторинг уздырыла.

Кайтартыла торган орлыклар белән тәэмин итүгә контрактлар төзү эше алып барыла. 2023 елның 13 мартына 100% шикәр чөгендере орлыгы, 94 % кукуруз орлыгы, 80% көнбагыш орлыгы алуга контракт төзелде.

Авыл хуҗалыгы республика халкын үзенең төп сыйфатлы һәм арзанлы продукциясе төрләре белән тәэмин итә.

Нәсел хуҗалыклары сөтчелек юнәлешендә гамәлгә ашырыла торган һәм яңа проектларның җитештерү куәтләрен югары генетик потенциалы булган таналар белән тәэмин итә ала. Сөт терлекчелеге системасын югары интенсив җитештерү

формаларына (энергия куәте көчле һәм югары протеинлы азыклар куллануны, технологик процессларны модернизацияләүне, терлекләр авыруларына каршы профилактика һәм алар белән көрәшү өчен ветеринария препаратларын актив куллануны, югары квалификацияле зооветеринария белгечләрен әзерләүне кертеп) күчерү исәбенә сөт җитештерү күләмнәренең артуына ирешү планлаштырыла.

Татарстанда илнең иң эре мөгезле терлекләр саны – 914 мең баш, шул исәптән 328,2 мең баш сыер тупланган.

2022 елда республикада беренче мәртәбә барлык категория хуҗалыклары буенча сөт саву 2 млн тоннадан артып китте (2 033,5 мең тонна).

Тармакта бара торган инновацион процесслар шартларында терлекчелек фермаларын һәм комплексларын төзү эше дәвам итә. 18 мең башка исәпләнгән 24 сөт комплексы файдалануга тапшырылды.

Терлекләрне азык белән тәэмин итү өстенлекле бурыч булып кала. Терлек азыгы үзәкләрен төзү дәвам итә. Хәзерге вакытта 39 үзәк кулланыла, алар 18 муниципаль районда 139 мең баштан артык эре мөгезле терлеккә хезмәт күрсәтә.

Ел ахырында муниципаль районнар терлекчелек тармакларын үстерү буенча үзләренең юл карталарын якладылар. 2023 елга 15,5 мең башка исәпләнгән 22 объект, шулай ук 16 муниципаль районда 22 терлек азыгы үзәге төзү планлаштырыла.

Сөт җитештерүне стимуллау өчен барлыгы 1,3 млрд сумга субсидияләр каралды (2022 елга караганда 112,0 млн сумга артыграк). Ярдәмнең яңа чарасы – эре мөгезле терлек җитештерү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү 83,3 млн сум тәшкил итә.

**Техник модернизацияләү**

Машина-трактор паркы яңартыла. 2022 елда хуҗалыклар тарафыннан 12,3 млрд сумнан артык суммага 3 116 берәмлек авыл хуҗалыгы техникасы һәм җайланма, шул исәптән 404 трактор, 141 ашлык җыю комбайны, 38 терлек азыгы җыю комбайны һәм 2 533 берәмлек башка техника сатып алынды.

Республика Россия төбәкләре арасында инвестиция чыгымнары һәм сатып алынган техника саны буенча алдынгы урыннарны алып тора.

Сатып алынган техника чыгымнарын 70/30 схемасы (70 процентын җитештерүче түли) буенча субсидияләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан 1,7 млрд сум акча бүлеп бирелде.

**Хуҗалык итүнең кече формаларын үстерү**

Хуҗалык итүнең кече формалары актив үсештә.

Хуҗалык итүнең кече формалары өчен 1,4 млрд сум күләмендә турыдан-туры дәүләт ярдәме күрсәтелде, шул исәптән федераль бюджеттан 629,5 млн сум (45 процент) акча бирелде.

Ярдәмнең иң мөһим юнәлешләре – ул фермерларга һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына грантлар бирү. 2022 елда 92 фермер грант алды, шул исәптән 68 фермерга 158,9 млн сум («Агростартап» юнәлеше буенча «Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары акселерациясе» төбәк проекты кысаларында) һәм 24 гаилә фермасына 387,4 млн сум акча бүлеп бирелде.

Грантлар ярдәмендә 1,5–2 ел дәвамында эре мөгезле терлекләр санын – 4,1 мең башка (шул исәптән сыерлар санын 1,6 мең башка), атлар санын – 320 башка, кош-кортлар санын 590 мең башка арттыру планлаштырыла.

6 кооператив авыл хуҗалыгы кооперативларының матди-техник базасын үстерүгә 133,3 млн сумлык грант отты.

2022 елдан федераль дәрәҗәдә «Агротуризм» дигән яңа юнәлеш – туристлар урнаштыру һәм инфраструктура булдыру өчен объектлар төзүгә грант ярдәме гамәлгә кертелде.

Татарстан фермерларының ике бизнес-проекты – Биектау муниципаль районының «Милли колоритлы авыл туризмы» һәм Алексеевск муниципаль районының «Эко-фермалы «Биләр» ял базасы» конкурста җиңделәр һәм барлыгы 16,0 млн сумлык грантлар алды.

«Кече һәм урта эшкуарлык һәм индивидуаль эшкуарлык инициативасына ярдәм» илкүләм проекты кысаларында «Авыл хуҗалыгы куллanучылар кооперативларына тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр» юнәлеше буенча 208,7 млн сумга 43 кооператив субсидия алды.

2022 елдан авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына – мини-сөт парклары территориясендә сөтчелек юнәлешендә эре мөгезле терлекләр асрау фермаларын төзүгә субсидияләрнең яңа төре кертелде.

2023 елдан 2018–2019 елларда гамәлдә булган үз эшен башлап җибәргән кооперативларга Татарстан Республикасы бюджетыннан грант ярдәме яңадан күрсәтелә башлады (2018–2019 елларда 27 кооператив грантлар алды). Грант кооперативның 10 процент үз акчасын салу шарты белән 5 млн сумнан 10 млн сумга кадәр арттырылды, барлыгы 100 млн сум акча каралды.

Шулай ук ярдәмнең мөһим төре – шәхси ярдәмче хуҗалыкларга субсидияләр бирү. Бу максатлар өчен 2022 елда 426,0 млн сум акча җибәрелде, субсидиядән 44 мең граждан файдаланды.

**Ярминкәләр үткәрү**

Авыл хуҗалыгы ярминкәләре – республика җитештерүчеләре тарафыннан җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясен, шул исәптән крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы кооперативлары һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар продукциясен сатуның иң кирәкле форматларыннан берсе.

Казан шәһәрендә ярминкәләр үткәрү өчен 14 мәйданчык, Түбән Кама шәһәрендә – 3 мәйданчык, Яр Чаллы шәһәрендә һәм Зеленодольск муниципаль районында 2 мәйданчык каралган.

Бүгенге көндә авыл хуҗалыгы продукциясен сату өчен 371 ярминкә мәйданчыгы (даими эшләп торган мәйданчыкларны кертеп) бар. Сәүдә урыннарының гомуми саны 5 765 берәмлек тәшкил итә.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан республиканың дүрт зур шәһәрендә (Казан, Яр Чаллы, Зеленодольск, Түбән Кама) оештырылган язгы-көзге ярминкәләрдә 2,1 млрд сумга продукция, шул исәптән 18 769,1 тонн яшелчә (11 323,9 тонна бәрәңге, 359,2 тонна агызып бирелә торган сөт, 2 625,0 тонна ит) сатылды. Ярминкәләр уздыруда

республиканың 32 муниципаль районы катнашты, 21 301 транспорт берәмлеге җәлеп ителде.

Авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә катнашкан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә ярдәм күрсәтү максаты белән ярминкәләрдә катнашучыларга ягулык-майлау материаллары чыгымнарын каплауга субсидияләр бирү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бүлеп бирелә. Моннан тыш, ярминкәләрдә катнашучыларга сәүдә урыннары бушлай бирелә.

Шушы чаралар ярдәмендә товар җитештерүчеләрнең авыл хуҗалыгы продукциясен ярминкәләрдә халыкка уртача ваклап сату бәясеннән 10-20 процентка түбәнрәк бәягә сату мөмкинлеге бар.

Моннан тыш, крестьян (фермер) хуҗалыклары һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар тарафыннан җитештерелә торган авыл хуҗалыгы продукциясен ел әйләнәсе көн дә сату өчен республика шәһәрләрендә махсуслаштырылган мәйданчыклар каралган. Казан шәһәрендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән чатырдан эшләнгән 8 мәйданчык төзелде, аларда ел әйләнәсе көн саен авыл хуҗалыгы продукциясен сату өчен шартлар тудырылды.

Казан шәһәрендә гомуми мәйданы 8 гектардан артык булган «Казан» агросәнәгать паркы уңышлы эшләп килә, аның эше авыл хуҗалыгы өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлегенең кече һәм урта формаларына ярдәм итүгә һәм аларны үстерүгә, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүчеләр һәм китерүчеләр белән төбәкара хезмәттәшлеккә юнәлдерелгән.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының рәсми сайтында («Эшчәнлек/Авыл хуҗалыгы ярминкәләре» бүлегендә) кулланучылар һәм продукция җитештерүчеләр өчен стационар булмаган сәүдә объектлары урнашу схемалары һәм ярминкә чаралары турында актуаль мәгълүмат бирелеп тора.

**«Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыру**

Иң мөһим юнәлеш – авыл халкы өчен уңайлы шартлар тудыру. 22 елда «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыруга 1,9 млрд сум акча бүлеп бирелде. Бу 34 муниципаль районда 84 объектны төзекләндерергә, 5 мең кв. м торак, 2 мәктәп һәм 21 км автомобиль юллары төзергә мөмкинлек бирде.

Агросәнәгать комплексына һәм авыл территорияләренә ярдәм итүнең гомуми суммасы 18,3 млрд сум тәшкил итте, шул исәптән 7,1 млрд сумы федераль бюджеттан бирелде.

**Илкүләм проектларны гамәлгә ашыру**

Татарстан Республикасы ике илкүләм проектны – «Халыкара кооперация һәм экспорт» һәм «Кече һәм урта эшкуарлык һәм шәхси эшкуарлык инициативасына ярдәм» проектларын гамәлгә ашыруда катнаша.

Фермерларга һәм кооперативларга «КУЭ субъектлары акселерациясе» төбәк проекты линиясе буенча ярдәм күрсәтелә. 2022 елда проектның барлык

индикаторлары үтәлде:

111 КУЭ субъектына дәүләт ярдәме күрсәтелде;

53 яңа эш урыны булдырылды;

авыл хуҗалыгы кооперациясе өлешендә республика өчен 2.400 яңа әгъза җәлеп итү буенча план-бирем билгеләнде (Россия буенча гомуми күрсәткечнең 18 проценты). 2023 елның 1 гыйнварына 2 683, ягъни планнан 111,8% яңа әгъза кабул ителде.

«2019–2024 еллар чорына Татарстан Республикасында агросәнәгать комплексы продукциясе экспортын үстерү» төбәк проекты кысаларында түбәндәге өч юнәлеш буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

1) 2022 елда *җирләрне мелиорацияләү* өлешендә Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан 2 объект («Чистай» агрофирмасы» ҖЧҖ – 2 033,5 га, И.И.Вәлиев КФХ – 359,4 га) сайлап алынды. 2,4 мең га мәйданда мелиорация эшләре башкарылды (индикатор 103,0 процентка үтәлде).

2019–2022 елларда гидромелиорация, культуртехник чаралар уздыру һәм сугару җирләрен техник җиһазландыру исәбенә 5 мең га мелиорацияләнгән җир файдалануга тапшырылды (күрсәткеч планның 112,0 процентына үтәлде).

Федераль проектта катнашучылар тарафыннан 1 млрд сумнан артык инвестицияләр җәлеп ителде. Ике дәрәҗәдәге бюджетлардан 519 млн сум акча түләнде. 10 объект файдалануга тапшырылды, җиһаз һәм сугару техникасы белән җиһазландырылды;

2) *майлы культуралар җитештерүне арттыруны* стимуллаштыру өлешендә җитештерү күләме арту күрсәткече 10 мең тоннага кадәр җиткерелде. Федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан 25,9 млн сум акча бүлеп бирелде. Акча авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә тулы күләмдә җиткерелде.

3) *агросәнәгать комплексы продукциясе экспортын* үстерү өлешендә. Әлеге максатлар белән республика агросәнәгать комплексы предприятиеләре һәм Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы вәкилләре Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Россия Федерациясенең агросәнәгать комплексы продукциясе экспортын үстерү буенча федераль үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесе («Агроэкспорт» ФДБУ) белән берлектә оештырылган эшлекле миссияләрдә һәм семинарларда, шул исәптән GulFood, «ПродЭкспо», Saudi Agriculture (Согуд Гарәбстаны), Food Africa (Египет), Russia Halal Expo (KazanSummit 2022 кысаларында) халыкара күргәзмәләр кысаларында, һәм Иран Ислам Республикасына, Мьянма Союзы Республикасына, Кыргызстан Республикасына, Беларусь Республикасына, Сенегал Республикасына, Үзбәкстан Республикасына, Татарстан Республикасы делегациясе составында – Әзербайҗан Республикасына, «Агроэкспорт» ФДБУ делегациясе составында – Малайзиягә визит барышында 11 бизнес-миссиядә катнашты.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан ике яклы хезмәттәшлек мәсьәләләре буенча чит ил делегацияләре белән 17 эшлекле очрашу уздырылды.

«Хәләл» юнәлеше уңышлы үсеш алды. Хәләл продукция экспорты күләме 2021 ел дәрәҗәсенә карата 33,0 процентка артты. Гомумән алганда, агросәнәгать комплексы продукциясе экспорты 2021 ел дәрәҗәсенә карата 11,0 процентка артты.

## ТРАНСПОРТҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ

**2022 елга юл тармагы буенча эш йомгаклары**

Республикада 40,3 мең км гомуми файдаланудагы автомобиль юллары, шулардан 1,2 мең км – федераль юллар, 13,5 мең км – төбәк юллары, 25,6 мең км – муниципаль юллар бар.

Юл эшләре 204,9 млрд сум күләмендә башкарылды, шул исәптән 124,0 млрд сумы – федераль проектларга, 80,9 млрд сумы Татарстан Республикасының юл эшләре программасына җибәрелде.

Федераль проектлар өлешендә:

Татарстан территориясе буенча 142 километры үтәчәк М-12 тизйөрешле автомобиль юлын (Мәскәү – Түбән Новгород – Казан, заказчы – «Автодор» дәүләт компаниясе), шул исәптән Идел елгасы аша 3 км дан артык озынлыктагы күпер кичүен төзү дәвам итә (республика территориясендә башкарылган эшләр күләме 86 млрд сум тәшкил итте);

130 км озынлыктагы юлда җир полотносы эшләнде, 90 км асфальт җәелде, Идел елгасы аша чыга торган күпернең якынча 1,5 км (3 342 метрдан 1 460 метры) терәк корылмалары эшләнде;

Түбән Кама һәм Яр Чаллы шәһәрләрен әйләнеп уза торган участокта 81,1 км гомуми озынлыкта М-7 «Волга» автомобиль юлы төзелә (федераль бюджеттан 16 млрд сум акча бүлеп бирелде);

17 км асфальт салынды һәм Кама елгасы күперендә төзелеш эшләре алып барыла;

дәүләт һәм хосусый партнерлык кысаларында Алексеевск – Әлмәт участогында 145 км озынлыкта Шәле –Баулы автомобиль юлы төзелә (финанслау күләме 16,66 млрд сум тәшкил итте, шул исәптән 6,66 млрд сумы – Татарстан Республикасы бюджетыннан). Моннан тыш, 3,86 млрд сумга инфраструктура бюджет кредиты бирелде. Бүгенге көндә 80 км озынлыктагы автомобиль юлына җир полотносы салынды, 60 км асфальт җәелде.

Моннан тыш, федераль трассаларда түбәндәге эшләр тәмамланды:

Чуваш Республикасы чигеннән Иннополис шәһәренең транспорт юллары чишелешенә кадәр М-7 «Волга» федераль юлының 36 километрын реконструкцияләү (финанслау күләме 3,9 млрд сум тәшкил итте), шул исәптән Свияга елгасы аша күпер кичүен реконструкцияләү (М-7 «Волга» автомобиль юлының 757 километрында, финанслау күләме 2,7 млрд сум тәшкил итте);

735+204 км – 753+400 км участогында 17 км озынлыкта М-7 «Волга» юлын реконструкцияләү (финанслау күләме 5,2 млрд сум тәшкил итте). Эшләр 2019 елда башланды. Реконструкцияләнә торган участок Татарстан Республикасы һәм Чуваш Республикасы чигеннән башлана;

Р-239 Казан – Оренбург федераль юлының 6,4 километрын («Казан халыкара аэропорты» акционерлык җәмгыятенә керү юлын) реконструкцияләү, финанслау күләме 2,1 млрд сум тәшкил итә.

Республиканың юл эшләре программасына 80,9 млрд сум акча, шул исәптән 33,8 млрд сумы – федераль бюджеттан, 47,1 млрд сумы – Татарстан Республикасы бюджетыннан, шулардан 1,4 млрд сумы муниципаль юл фондыннан бүлеп бирелде.

Муниципаль юлларда түбәндәге эшләр башкарылды:

Несмелов урамыннан М-7 «Волга» федераль әһәмияттәге автомобиль юлына кадәр (Казан шәһәренең Киров районындагы «Серебряный бор» торак комплексы аша) 5,5 км озынлыктагы автомобиль юлын төзү;

11 км дан артык озынлыкта Вознесенский трактын төзү;

Казан шәһәрендә Горький шоссесын реконструкцияләү. Якынча 12 км озынлыктагы М-7 «Волга» трассасына кадәр участок.

Җирле юлларның 639,4 километры норматив хәлгә китерелде, шул исәптән аерым төбәк социаль әһәмияткә ия программалар кысаларында түбәндәгеләр башкарылды:

120 км торак пунктлар юллары ремонтланды (300 урам; муниципаль юл фондыннан 1,4 млрд сум);

150 км торак пунктлар юлларына вак ташлар (ЩПС) салынды (торак пунктларда 380 урам норматив хәлгә китерелде);

торак пунктларның 340 урамында 312 км юл ремонтланды;

гаилә фермаларына, терлекчелек комплексларына һәм бакча җәмгыятьләренә керә торган 32 юл (57,4 км) төзекләндерелде.

**«Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты**

«Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты кысаларында 170,5 км төбәк һәм җирле юллар (16,3 км шәһәр урамнары һәм 154,2 км төбәк юллар) ремонтланды. Финанслау күләме 12,17 млрд сум тәшкил итте (7,49 млрд сумы – федераль бюджеттан, 4,68 млрд сумы – Татарстан Республикасы бюджетыннан).

**Транспорт тармагы**

**Һава транспорты предприятиеләре эшчәнлеге**

Татарстанда түбәндәге оешмаларның эшчәнлеге һава транспорты белән гамәлгә ашырыла:

Казан һәм Бигеш халыкара аэропортлары, Бөгелмә төбәк аэропорты;

Татарстан Республикасы аэропортларыннан төбәк авиаташуларны башкара торган биш «ЮВТ АЭРО» авиакомпаниясе, шулай ук «Бизнес авиация» һәм «Вертолет белән ташулар» сегментында эшчәнлек башкаручы «Тулпар Эйр», «Тулпар Экспресс», «Казан авиапредприятиесе» һәм «Авиасервис» авиакомпанияләре.

2022 елда республиканың барлык аэропортлары буенча пассажирлар агымының гомуми күләме 4 676,8 мең кеше (2021 ел дәрәҗәсенә карата 102,2 %) тәшкил итте.

2050 елга кадәр «Казан халыкара аэропорты» акционерлык җәмгыятен үстерү буенча мастер-план кабул ителде, анда яңа терминаллар (пассажир һәм почта-йөк ташу терминаллары), техник хезмәт күрсәтү ангарын төзү, пассажирлар перронын киңәйтү һәм иярчен инфраструктураны яңарту каралган.

«Бигеш аэропорт комплексын реконструкцияләү» проектының икенче чиратын федераль бюджет акчасы исәбеннән реконструкцияләнеп бетте (аэропортның периметр коймасын алыштыру, аны техник саклау чаралары белән җиһазландыру, патруль юлын төзү).

Бигеш аэропортының эчке һава линияләре аэровокзалын төзү дәвам итә, үткәрү сәләте 1 сәгатькә очып китү һәм төшүгә 200 пассажир тәшкил итә. Аэровокзалны файдалануга тапшыруның якынча срогы – 2023 елның III кварталы.

Республиканың авиаташуларны субсидияләү буенча федераль программаны гамәлгә ашыруда катнашуы тармак үсешенә стимул бирә торган өстәмә фактор булып тора. Республика 45 маршрут буенча авиаташулар өчен барлыгы 603,2 млн сум күләмендә (2021 елда – барлыгы 546,6 млн сумга 34 юнәлеш буенча) субсидия бирде.

**Тимер юл транспорты предприятиеләре эшчәнлеге**

Республикада тимер юл пассажирлар транспорты белән эшчәнлек «Содружество» акционерлык җәмгыяте шәһәр яны компаниясе тарафыннан алып барыла.

2022 елда тимер юл транспортына 7,69 млн пассажир (2021 елда – 7,25 млн пассажир), шул исәптән шәһәр яны маршрутлары буенча – 6,04 млн пассажир (2021 елда – 5,87 млн пассажир), еракка бару маршрутлары буенча – 1,65 млн пассажир (2021 елда – 1,38 млн пассажир) утыртып җибәрелде.

Республика территориясе буйлап 16,56 млн тонна (2021 елга карата 109,1 %) йөк ташылды.

Куйбышев тимер юлы полигонында йөкләр күләме 15,46 млн тонна (2021 ел дәрәҗәсенә карата 112,1 %), Горький тимер юлы – «РЖД» ААҖ филиалында – 1,1 млн тоннадан артык (2021 ел дәрәҗәсенә карата 83,0 %) тәшкил итте.

Шәһәр яны элемтәсендә тимер юл транспорты белән ташламалы категорияләрдәге гражданнарны йөртүгә һәм аларның тарифларын дәүләт тарафыннан җайга салуга бәйле рәвештә, «Содружество» акционерлык җәмгыятенең алынып бетмәгән керемнәрен компенсацияләү өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 374,38 млн сум акча бүлеп бирелде.

Логистика чыгымнарын киметүнең төп ысулларыннан берсе – йөк ташуларны контейнерлау. 2022 елның сентябрендә Владивосток порты – Казан шәһәре маршруты буенча FESCO компаниясенең беренче контейнер поезды җибәрелде. Ел ахырына кадәр әлеге маршрут буенча 1 800 контейнер йөкләмәләре ташылды. Яңа маршрут үзләштерелә, ул республика предприятиеләрен Новороссийск порты белән һәм аның аша ислам дөньясы илләре һәм Индия базарлары белән тоташтыра. Моннан тыш 2022 ел ахырына «ТрансКонтейнер» ГАҖ тарафыннан Казан шәһәренең Лагерь станциясе терминалын реконструкцияләп бетерде, аның эшкәртү куәте 60 процентка артты.

**Эчке су транспорты предприятиеләре эшчәнлеге**

Татарстан чикләрендә 1 057 км, шул исәптән Идел бассейнында – 788 км, Кама бассейнында 269 км эчке су юллары уза.

Республикада эшли торган 8 пассажир причалы (Казан, Свияжск, Болгар, Тәтеш, Чистай, Алабуга, Түбән Кама шәһәрләрендә, Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогында), 2 паром кичүе (Зеленодольск – Карамалы Тау, Аракчино – Югары Ослан), 4 боз кичүе (Зеленодольск – Карамалы Тау, Аракчино – Югары Ослан, Соколка – Яңа Закамский, Покровский – Красный Ключ) бар.

Су транспорты белән шәһәр яны маршрутлары буенча пассажирлар йөртү «Татфлот» АҖ һәм «Яр Чаллы» руда булмаган материаллар җитештерү

берләшмәсе тарафыннан башкарыла.

2022 ел навигациясендә суднолар керү саны 2 241не тәшкил итте (2021 ел дәрәҗәсенә карата 1,8 гә тапкыр арту), 293 мең турист йөртелде (2021 ел дәрәҗәсенә карата 1,6 га тапкыр арту), шәһәр яны маршрутлары буенча 330 мең пассажир (2021 ел дәрәҗәсенә карата 98,8%) йөртелде.

Җайга салына торган тарифлар куллануга һәм гражданнарның аерым категорияләренә ташламалар бирүгә бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрне каплау өчен су транспорты оешмаларына 95,7 млн сумлык субсидия түләнде.

**Автомобиль транспорты**

Татарстанның автомобиль транспорты тармагында төрле милек формаларындагы 45 транспорт йөртүче (шул исәптән 276,2 млн пассажир (2021 ел дәрәҗәсенә карата 116,5 %) йөрткән 15 эре автотранспорт предприятиесен кертеп) эшчәнлек алып бара.

Барлык эшчәнлек төрләрендәге эре һәм урта предприятиеләрнең автомобиль транспортында йөк әйләнеше (коммерцияле йөк ташулар белән шөгыльләнүче эшкуарларны исәпкә алып) 112,5 млн тонна (2021 ел дәрәҗәсенә карата 1,5 тапкырга арту) тәшкил итте.

Шәһәр электр транспорты предприятиеләренең хәрәкәт составы 502 берәмлекне, шул исәптән 278 трамвай, 209 троллейбус, 15 метрополитен поездын үз эченә ала.

Шәһәр электр транспорты белән 94,5 млн пассажир (2021 ел дәрәҗәсенә карата 107,0 %) йөртелде, пассажирлар әйләнеше 456,9 млн пассажир-километр (2021 ел дәрәҗәсенә карата 109,0 %) тәшкил итте.

Автотранспорт тармагын субсидияләү өчен 2 516,7 млн сум акча (2021 ел дәрәҗәсенә карата 129,0 %) җибәрелде.

**Юл эшләре планы**

2023 елның юл эшләре программасына – 48,5 млрд сум, шул исәптән 32,4 млрд сумы – Татарстан Республикасы бюджетыннан, 16,1 млрд сумы федераль бюджеттан каралды.

Бүлеп бирелгән акча исәбеннән түбәндәге эшләрне дәвам итү планлаштырыла:

Казан шәһәренең очып китү трассаларын һәм шәһәр магистральләрен төзү;

Алексеевск – Әлмәт участогында Шәле-Баулы автомобиль юлын төзү;

төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү, ремонтлау һәм капиталь ремонтлау;

җирле юлларны норматив хәлгә китерү.

2023 елда «Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты чараларын гамәлгә ашыруга 11,0 млрд сум акча каралды (4,5 млрд сумы – федераль бюджеттан, 6,5 млрд сумы – Татарстан Республикасы бюджетыннан). Илкүләм проект кысаларында түбәндәге эшләр башкарылды:

төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм шәһәр агломерацияләренең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү (Татарстан Республикасы бюджетыннан 5,8 млрд сум);

автомобиль юлларын һәм ясалма корылмаларны норматив хәлгә китерү

(3,8 млрд сум, шул исәптән 3,06 млрд сумы – федераль бюджеттан, 718,7 млн сумы – Татарстан Республикасы бюджетыннан);

юл хуҗалыгы инфраструктурасын үстерү (федераль бюджеттан 1,4 млрд сум), шул исәптән түбәндәгеләрне төзү:

Казан шәһәренең Киров районында «Серебряный бор» торак комплексы аша Несмелов урамыннан М-7 «Волга» федераль әһәмияттәге автомобиль юлына кадәр автомобиль юлын;

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә Зур Казан божрасын үстерү кысаларында Техник урамыннан Киров дамбасына кадәр юл участогын (Магистраль урамыннан Девятаев урамына кадәр участокта Меховщиклар урамы буенча юл);

Җиңү проспектыннан М-7 «Волга» автомобиль юлына кадәр участокта Вознесенский трактын.

## ТӨЗЕЛЕШ ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫК

2022 елда 4 271 объект төзүгә һәм аларны капиталь ремонтлауга 122,26 млрд сум акча җибәрелде. Шул исәптән 44 республика программасы кысаларында 46,44 млрд сумга 3 550 объект, 8 илкүләм проект кысаларында – 20,85 млрд сумга 125 объект (12,5 мең кв. м авария хәлендәге торак фонды), 6 дәүләт программасы кысаларында – 6,31 млрд сумга 108 объект, программадан тыш чаралар кысаларында – 44,32 млрд сумга 472 объект, инфраструктура проектлары кысаларында – 4,34 млрд сумга 16 объект төзелде һәм ремонтланды.

**Торак төзелеше**

Республика ел саен торакны файдалануга тапшыру күләмнәре буенча алдынгы урыннарны били һәм Россия Федерациясе субъектлары – лидерлары исемлегенә керә.

2022 ел йомгаклары буенча 3 093,4 мең кв. м торак (2021 ел дәрәҗәсенә карата 102,7 %) файдалануга тапшырылды, шул исәптән:

783,4 мең кв. м гомуми мәйданлы 99 күпфатирлы йорт;

2 202,8 мең кв. м гомуми мәйданлы 16 317 индивидуаль торак йорт;

социаль ипотека программасы кысаларында 107,2 мең кв. м гомуми мәйданлы 33 торак йорт.

Социаль ипотека программасына яшь гаиләләрне, ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, үзләренә беркетелгән торак урыны булмаган ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасындагы затларны, радиация һәлакәтләре һәм катастрофалар аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны һәм аларга тиңләштерелгән затларны, Ерак Төньяк районнарыннан һәм аларга тиңләштерелгән территорияләрдән күченеп киткән гражданнарны, мәҗбүри күченгән затларны, инвалидларны, 1941–1945 еллар Бөек Ватан сугышы ветераннарын торак белән тәэмин итү, шулай ук запаска азат ителгән хәрби хезмәткәрләр һәм аларга тиңләштерелгән затлар өчен торак төзү буенча федераль механизмнар интеграцияләнде.

Ел йомгаклары буенча республиканың бер кешесенә исәпләгәндә торакның гомуми мәйданы белән тәэмин ителеш 29,2 кв. м (бәяләү) тәшкил итте. 2023 елда 2 830,0 мең кв. м торак файдалануга тапшырырга планлаштырыла.

«Аренда торагы» программасы

Аренда торагын төзү яңа җитештерү мәйданчыкларын ачуга, махсус икътисадый зоналар, сәнәгать паркларын булдыруга, ИТ-өлкә, нефть химиясе сәнәгате предприятиеләрен, шулай ук белгечләр – бюджет өлкәсе хезмәткәрләрен (табиблар, укытучылар, мәдәният, спорт өлкәсе, көч структуралары хезмәткәрләре һ.б.) җәлеп итүгә ихтыяҗ аеруча кискен булган өлкәләрне үстерүгә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

Аренда торагы предприятие хезмәткәрләренә дә, чакырылган белгечләр – бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә дә бирелә.

2010 елдан 2022 елга кадәр 192,6 мең кв. м гомуми мәйданлы 433 аренда йорты, шул исәптән 2022 елда 3,1 мең кв. м гомуми мәйданлы 4 торак йорт файдалануга тапшырылды.

*Өлешле төзелештә алданган катнашучылар* проблемасы системалы рәвештә хәл ителә.

Өлешле төзелештә катнашкан 302 кешенең хокуклары торгызылды. Проблемалы объектларның бердәм реестрыннан 17,9 мең кв. м гомуми мәйданлы 3 объект чыгарылды, шул исәптән:

«Жардин» торак комплексында Казан шәһәре, Аэропорт урамы буенча 25 нче торак йорт (19 өлешле төзелештә катнашучы). Объект йорт төзүченең көчләре белән төзелеп бетте;

«Мелодия» торак комплексында Казан шәһәре, Комиссар Габишев урамының 18 нче А йорты буенча торак йорт (182 өлешле төзелештә катнашучы). Объектның төзелеше «Территорияләрне үстерү фонды» гавами хокукый компаниясе механизмы аша өлешле төзелештә катнашучыларга ярдәм күрсәтү буенча федераль программа кысаларында төгәлләнде;

«Поколение» торак комплексында Казан шәһәре, Г.Кутуй урамының 81 нче А йорты буенча торак йорт (101 өлешле төзелештә катнашучы). Йорт буенча «Территорияләрне үстерү фонды» гавами хокукый компаниясе тарафыннан гражданнарга акчалата компенсация түләү турында карар кабул ителде.

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ *күпбалалы гаиләләрне торак урыннары белән тәэмин итү* чараларын гамәлгә ашыру дәвам итә. Әлеге категория гражданнары өчен торак сертификатлары 2007 елдан рәсмиләштерелә. 2007 елдан 2022 елга кадәр Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелгән акчага торак белән барлыгы 1 983,4 млн сумга 562 күпбалалы гаилә, шул исәптән 2022 елда – 229,2 млн сумга 25 гаилә тәэмин ителде.

Торак шартларын яхшырту федераль законнар белән гарантияләнгән гражданнар алдында дәүләт йөкләмәләрен үтәүгә юнәлдерелгән «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасы гамәлгә ашырыла. Болар – Ерак Төньяк районнарыннан күченгән гражданнар, Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган, шулай ук күченергә мәҗбүри булган гражданнар.

2022 елда 36,3 млн сумга 13 субсидия рәсмиләштерелде, шул исәптән:

5 дәүләт торак сертификаты – 13,1 млн сумга Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга;

1 дәүләт торак сертификаты – 2,9 млн сумга билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри күченүчеләр дип танылган гражданнарга;

7 дәүләт торак сертификаты – 20,3 млн сумга Ерак Төньяк районнарыннан һәм аларга тиңләштерелгән җирләрдән китүче (чыгып киткән) гражданнарга.

Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәме программасы («*Гаилә ипотекасы*») гамәлгә ашырыла, әлеге программада ипотеканың барлык срогы дәвамында елына 6 процентка кадәр ставка белән торак кредиты буенча ипотека алу күздә тотыла (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге 1711 номерлы карары нигезендә) Программада 2018 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 1 июленә

кадәр беренче баласы яки аннан соңгы балалары туган гаиләләр, шулай ук 18 яшькә кадәрге ике бала тәрбияләүче гаиләләр катнаша (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 28 декабрендәге 2485 номерлы карары).

Программа беренчел базарда юридик заттан фатир яки кишәрлекле йорт сатып алганда, юридик зат яисә индивидуаль эшкуар белән подряд шартнамәсе буенча җир кишәрлегендә индивидуаль торак йорт төзегәндә яки индивидуаль торак йорт төзү өчен җир кишәрлеген сатып алганда гамәлдә була.

Программа гамәлгә кергәннән башлап (2019 елның 1 апреленнән) республикада барлыгы 53,33 млрд сумга 17 060 кредит, шул исәптән 2022 елда 23,27 млрд сумга 5 790 кредит бирелде.

*Ташламалы ипотека* программасын гамәлгә ашыру дәвам итә (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020–2024 елларда Россия Федерациясе гражданнарына бирелгән торак (ипотека) кредитлары (заемнары) буенча кредит һәм башка оешмаларга алынып бетмәгән керемнәрне каплау кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 23 апрелендәге 566 номерлы карары кысаларында).

Ташламалы ипотека беренчел базарда (шул исәптән төзелеш стадиясендә) күпфатирлы торак йортлардан торак һәм индивидуаль торак (шул исәптән җир кишәрлекләре белән) сатып алу өчен; подряд шартнамәсе буенча яки заемга алучылар тарафыннан үз көчләре белән индивидуаль торак төзү өчен бирелә.

Ташламалы ипотека программада түбәндәге шартлар карала:

процент ставкасы – 8 %;

кредитның максималь күләме – 6,0 млн сумга кадәр;

башлангыч кертем – 15 проценттан;

ташламалы ипотека программасының гамәлдә булу срогы – 2024 елның 1 июленә кадәр.

Ташламалы ипотека программасы гамәлгә кергәннән алып (2020 елның 2 маеннан) барлыгы 82,28 млрд сумга 28 100 ипотека кредиты, шул исәптән 2022 елда – барлыгы 26,85 млрд сумга 7 410 кредит бирелде.

Моннан тыш, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 30 ноябрендәге 1567 номерлы карары белән *Авыл территорияләрендә торак төзү яки сатып алу өчен бирелгән ипотека кредитлары буенча* алынмаган керемнәрне каплау өчен Россия кредит оешмаларына субсидияләр бирү кагыйдәләре расланды.

2020 елның 1 гыйнварыннан гражданнар авылда торак төзү яки сатып алу өчен елына 3% ставка белән ипотека кредиты алырга мөмкин. Кредит күләме – иң күбе 3 млн сум. Башлангыч кертем – 10 %.

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Россельхозбанк» АҖ, «Сбербанк» ГАҖ һәм «АК БАРС» БАНКЫ ГАҖ белән ташламалы ипотека кредитлары бирү өчен вәкаләтле банклар буларак килешүләр имзаланды.

Авыл ипотекасы программасы эшли башлаганнан бирле (2020 елның апреленнән) республикада барлыгы 9,11 млрд сумга 3 904 ипотека кредиты, шул исәптән 2022 елда барлыгы 1,61 млрд сумга 621 кредит бирелде.

**Күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау**

Капиталь ремонт программасы буенча 40 муниципаль берәмлектә

742 күпфатирлы йорт (4,7 млн кв. м) ремонтланды (шул исәптән 2023 елда капиталь ремонт ясау планлаштырыла торган 2 күпфатирлы йортка проект документациясе эшләнде). Гомуми финанслау күләме 6,32 млрд сум тәшкил итте.

Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә үз торак шартларын республиканың 184 меңнән артык гражданы яхшыртты.

Эшләр барышында эксплуатацияләнергә яраксыз дип танылган 207 берәмлек лифт җиһазы алыштырылды, 284 йортта 269 мең кв. метрдан артык түбә, 372 йортта 967 мең кв. метрдан артык фасад ремонтланды, электр, җылылык, газ, су белән тәэмин ителә һәм су чыгарыла торган 1 млн погонлы метрдан артык йорт эчендәге инженерлык челтәрләре алыштырылды.

2023 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган 2 күпфатирлы йортка проект документациясен эшләнде.

Гомуми финанслау күләме – якынча 6,32 млрд сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 0,96 млрд сум, муниципаль берәмлекләр бюджеты акчасы – 1,07 млрд сум, гражданнар акчасы 4,29 млрд сум тәшкил итте.

**Концессия килешүләре һәм инвестиция программалары кысаларында коммуналь объектларны реконструкцияләү һәм модернизацияләү чараларын гамәлгә ашыру**

Республикада 20 муниципаль районда 115 концессия килешүе, шул исәптән җылылык белән тәмин итү өлкәсендә – 74 концессия килешүе, су белән тәэмин итү һәм су чыгару өлкәсендә – 35 концессия килешүе, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә 6 концессия килешүе гамәлдә, алар нигезендә концессионерларга муниципаль милектәге 2 021 коммуналь инфраструктура объекты тапшырылды.

2022 елда 9 коммуналь комплекс оешмасы өчен су белән тәэмин итү өлкәсендә 12 инвестиция программасы һәм су чыгару өлкәсендә 10 инвестиция программасы, шулай ук җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә (катнаш эшләп чыгару режимында җылылык энергиясен эшләп чыгара торган предприятиеләрне исәпкә алмыйча) 10 инвестиция программасы гамәлгә ашырылды.

**«Безнең ишегалды» программасы**

2020 елдан ишегалды территорияләрен төзекләндерү буенча «Безнең ишегалды» республика программасы тормышка ашырыла. 5 ел эчендә 2014 елга кадәр төзелгән күпфатирлы йортларның барлык ишегалларын (6 меңнән артык йорт яны территориясе) тәртипкә китерү планлаштырыла. Гомуми финанслау күләме 50 млрд сум тәшкил итәчәк.

Программа кысаларында түбәндәге эшләр үткәрелә: юллар һәм тротуарлар ремонтлау, тышкы яктырту, эскәмияләр һәм урналар урнаштыру, каты коммуналь калдыклар өчен мәйданчыклар, комлы-чуерташлы катнашма җәелгән балалар мәйданчыкларын төзекләндерү, өлешчә яшелләндерү.

2022 елда 1 212 ишегалды территориясе төзекләндерелде, финанслау күләме 9 млрд сум тәшкил итте.

**«Торак һәм шәһәр мохите» илкүләм проекты**

«Торак һәм шәһәр мохите» илкүләм проекты максатларына ирешү өчен

3 789,1 млн сумга чаралар гамәлгә ашырылды, шуларның 3 069,2 млн сумы – федераль бюджет акчасы.

*«Торак» төбәк проекты* кысаларында *түбәндәгеләр* төзелде:

Казан шәһәренең («Новые горки» ТК, «Гребной канал» ТК), Яр Чаллы шәһәренең («Замелекесье» торак районы, «Междуречье» ТК, «Притяженье» ТК) яңа торак комплексларында һәм Лаеш муниципаль районының үзләштерелә торган территорияләрендә (Усад ав., Столбище ав., Кече Кабан торак пункты) юл инфраструктурасы;

Казан шәһәрендә («Яратам» ТК), Яр Чаллы шәһәрендә («Замелекесье» торак районы), Буа шәһәрендә (Ипподром пос.), Зеленодольск муниципаль районының Осиново авылында («Удачный» ТК) инженерлык инфраструктурасы объектлары.

Питрәч муниципаль районының «Усадьба Царево» торак комплексында, тәүлегенә 4 000 куб. метрга кадәр җитештерүчәнлекне арттырып, хуҗалык-көнкүреш канализациясенең чистарту корылмалары реконструкцияләнде.

*«Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» федераль проекты* кысаларында 60 иҗтимагый киңлекләр объекты төзекләндерелде, муниципаль берәмлекләрнең – Кече шәһәрләр һәм тарихи җирлекләр арасында уңайлы шәһәр мохите булдыруның иң яхшы проектлары буенча бөтенроссия конкурсында җиңүчеләрнең 6 проекты гамәлгә ашырылды.

*«Яшәү өчен яраксыз булган торак фондын тотрыклы киметүне тәэмин итү» төбәк проекты*

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 29 март, 242 нче карары белән 2019–2023 елларга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча республика адреслы программасы расланды.

2022 ел этабы буенча (2022–2023 елларда гамәлгә ашырыла) 12 174,63 кв. м гомуми мәйданлы 398 бүлмәдән 987 кешене күчереп урнаштыру каралды, шул исәптән 2022 елда Казан шәһәре һәм муниципаль берәмлекләр территориясендә урнашкан 7 663,38 кв. м гомуми мәйданлы 273 бүлмәдән күчерелде.

**Инвестиция программасы**

2022 елда 9 коммуналь комплекс оешмасы өчен су белән тәэмин итү өлкәсендә 12 инвестиция программасы һәм су чыгару өлкәсендә 10 программа гамәлгә ашырылды.

2022 елның инвестиция программалары чараларына оператив мониторинг мәгълүматлары буенча, бәяләүләр буенча, 4 444,1 млн сум акча тотылды, шул исәптән су белән тәэмин итү чараларына – 2 050 ,9 млн сум, су чыгару чараларына – 2 393,2 млн сум (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм (яки) су чыгару системалары объектларының инвестиция программаларын үтәү турында хисап формаларын раслау турында» 2021 елның 6 апрелендәге 62 номерлы боерыгы нигезендә).

2023 елга 15 коммуналь комплекс оешмасы өчен су белән тәэмин итү һәм су чыгару өлкәсендә 35 инвестиция программасы расланды. План буенча финанслау күләме – 5 470 ,2 млн сум, шул исәптән су белән тәэмин итү буенча – 1 908,3 млн сум, су чыгару буенча – 3 561, 9 млн сум.

Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә инвестиция программалары 10 оешма тарафыннан (катнаш эшләп чыгару режимында җылылык энергиясе эшләп чыгаручы предприятиеләрне исәпкә алмыйча) гамәлгә ашырылды. Программа чараларын гамәлгә ашыруга 383,4 млн сум акча бүлеп бирелде. 2023 елга 467,1 млн сумлык 15 инвестиция программасы расланды.

## ИНВЕСТИЦИЯ ЭШЧӘНЛЕГЕ

Татарстан Республикасының инвестицион потенциалын үстерүгә, инвестицион климатны яхшыртуга, бизнес алып бару өчен уңайлы шартлар булдыруга зур игътибар бирелә.

2022 елда икътисадны һәм социаль өлкәне үстерү өчен төп капиталга 888,6 млрд сум, ягъни 2021 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 110,5% инвестицияләр җибәрелде.

Кече эшкуарлык субъектларына карамый торган оешмалар тарафыннан инвестицияләрнең шактый күләме эшкәртү җитештерүләрен үстерү өчен төп капиталга инвестицияләрнең гомуми күләменнән 25,1 проценты (шулардан 9,2 % – нефть продуктлары җитештерүгә, 6 % – химик матдәләр һәм химик продуктлар җитештерүгә, 2,6 % – автотранспорт чаралары, тагылмалар һәм ярымтагылмалар җитештерүгә) җибәрелде, транспортлау һәм саклау өлкәсенә – барлык инвестицияләрнең 24,2 проценты, файдалы казылмалар чыгаруга – 12,1 %, күчемсез мөлкәт белән операцияләр эшчәнлегенә – 8,3 %, авыл, урман хуҗалыгына, аучылык, балык тоту һәм балык үрчетүгә 4,7 % җибәрелде.

Ел саен «Яңа проектлар чыгару буенча стратегик инициативалар агентлыгы» коммерциячел булмаган автоном оешмасы тарафыннан төбәкләр Россия Федерациясе субъектларында инвестицион климат торышының илкүләм рейтингы кысаларында бизнес алып бару шартлары буенча бәяләнә. Татарстан Республикасы, 2022 елда 2 нче урын яулап, лидерлар өчлегендә үз позициясен нык саклап тота.

2022 елда инвестицион климатны яхшырту максатларында түбәндәге чаралар гамәлгә ашырылды:

Төбәк инвестиция стандартының барлык биш элементы (инвестиция декларациясе, инвестиция үсеше агентлыгы, инвестиция комитеты, инвестиция картасы, инвестиция кагыйдәләре җыелмасы) расланды;

Татарстан Республикасында Төбәк инвестиция стандартын гамәлгә кертү мониторингын үткәрү тәртибе һәм критерийлары расланды (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2022 елның 14 июнендәге 208 номерлы боерыгы);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы каршындагы федераль төркем тарафыннан Төбәк инвестиция стандартын Татарстан Республикасында гамәлгә кертү расланды (Россия Федерациясе субъектларында яңа инвестиция проектларына ярдәм итү системасын гамәлгә кертүне раслау буенча федераль төркем утырышының 2022 елның 11 августындагы 24-МК номерлы беркетмәсе («Төбәк инвестиция стандарты»));

Инвестиция проектлары реестрын электрон рәвештә алып бару һәм инвестиция проектларын гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтеп тору өчен «Татарстан инвестицияләрен контрольдә тоту» мәгълүмат системасы билгеләнде (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын тормышка ашыруда «бер тәрәзә» принцибы буенча ярдәм итү буенча инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара хезмәттәшлеге регламентын раслау турында» 2019 ел, 20 февраль, 118 нче

карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 6 апрелендәге 320 номерлы карары);

Төбәк инвестиция стандарты таләпләре нигезендә Татарстан Республикасы Инвестиция порталында:

- стандартның барлык элементлары, норматив-хокукый база һәм җаваплы затлар белән элемтәгә керү өчен белешмә урнаштырылган «Инвестстандарт» бүлеге төзелде;

- квартал саен инвестиция картасы инвестиция инфраструктурасы объектлары өлешендә актуальләштерелә;

- инженерлык челтәрләренә технологик тоташтыру тәртибе турында; ресурслар белән тәэмин итүче оешмаларның инвесторлар белән хезмәттәшлек итү буенча җаваплы затлары турында; электрон рәвештә технологик тоташтыру буенча хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеген күрсәтеп, ресурслар белән тәэмин итүче оешмаларның рәсми сайтлары турында мәгълүмат урнаштырылды;

- инвестиция проектын әзерләгәндә һәм гамәлгә ашырганда күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту (срокларны үтәү, рәсми соратыла торган документларның санын, процедураларның санын кыскарту) өчен түбәндәге процедуралар буенча инвесторның гамәлләре алгоритмы һәм аларны актуальләштерү план-графиклары расланды һәм урнаштырылды: электр челтәрләренә, газ, җылылык, су белән тәэмин итү, су чыгару объектларына тоташтыру; файдалануга тапшырылган объектка милек хокукларын рәсмиләштерү; җир кишәрлеген арендага алу (торгларда һәм торгларсыз); объектны төзүгә һәм файдалануга тапшыруга рөхсәт алу; юл инфраструктурасыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү;

дәүләт хакимияте органнарында, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарында нәтиҗәле төбәк принципларын гамәлгә ашыру максатларында «Нәтиҗәле төбәк» пилот проектын гамәлгә ашыру буенча координация советы төзелде (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 15 декабрь, 1343 нче карары);

«Росатом» дәүләт корпорациясенең «Тоташ инвестиция агымы» сакчыл проектын гамәлгә ашыру кысаларында республикада инвестор гамәлләре алгоритмнарының картасы төзелде. Процессларның агымдагы, идеаль, максатчан торышлары анализлана (аларның картасы ясала); процессның срокларына йогынты ясый торган проблемалы участоклар ачыклана; административ барьерларның сәбәпләре буенча (норматив җайга салу өлешендә дә, бер-бер артлы эшләнә торган эшне оештыруда да) эзләнүләр алып барыла.

**Татарстан Республикасының инвестиция меморандумы**

Инвестиция эшчәнлегендә катнашучылар хезмәттәшлеге нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 7 декабрь, 1296 нчы карары белән 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасының инвестиция меморандумы расланды, анда республикада инвестиция эшчәнлеге үсешенең түбәндәгеләргә караган өстенлекләре билгеләнде:

инвестицияләр җәлеп итү һәм республика җитештерүчеләре продукциясен яңа базарларга чыгару өлкәсендә Россия Федерациясе регионнары һәм чит ил

партнерлары белән хезмәттәшлекне үстерү;

халыкара икътисадый кооперация пространствосыннан актив файдалану;

электрон сәүдәне үстерү (шул исәптән Республика маркетинг үзәге мөмкинлекләреннән файдаланып);

эшкуарлыкка ярдәм итү инфраструктурасын, шул исәптән махсус икътисадый зоналарны, алгарышлы үсеш территорияләрен, инновацион фәнни-технологик үзәкләрне, технопаркларны, индустриаль паркларны үстерү;

цифрлы икътисадны булдыру һәм үстерү;

технологик суверенитетны тәэмин итүгә ярдәм итә торган проектларны гамәлгә ашыру;

экспортка юнәлдерелгән тармакларда проектларны гамәлгә ашыру;

азык-төлек иминлеген тәэмин итүгә һәм авыл хуҗалыгы җитештерүенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән инвестиция проектларын гамәлгә ашыру.

2022 елда Татарстан Республикасының өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә 178 проект (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 10 февраль, 108 нче карары), шул исәптән «ЭП-600 яңа олефин комплексы төзелеше» («Түбән Кама нефть химиясе» ГАҖ), «ЭЛОУ-АВТ-6 урнаштыру» (В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, «ТАНЕКО» АҖ), «Каталитик крекинг урнаштыру» (В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, «ТАНЕКО» АҖ), «Эре габаритлы шиналар җитештерүне оештыру» (Түбән Кама йөк машиналары шиннары заводы ҖЧҖ), «Тоташ металл кордлы шиннарны елына 2,8 млн данәгә кадәр җитештерүне арттыру» («Түбән Кама йөк машиналары шиннары заводы» ҖЧҖ), «КамАЗ автомобильләренең модель рәтләрен үстерү һәм аны җитештерү өчен җитештерү куәтләрен модернизацияләү» («КАМАЗ» ГАҖ) проектлары һ.б. керде.

2023 елга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 30 декабрь, 1464 нче карары белән 140 өстенлекле инвестиция проектлары исемлеге расланды, ул «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы һәм «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зоналары, технопарклар, индустриаль (сәнәгать) парклар, инновацион фәнни-технологик үзәкләр (шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәте яки Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары нигезендә төзелгәннәр) территорияләрендә, алгарышлы үсеш территорияләрендә гамәлгә ашырыла һәм гамәлгә ашырырга планлаштырыла торган проектларны, шулай ук, торглар үткәрмичә, арендага җир кишәрлекләре бирү механизмыннан файдаланып, капитал салуларны саклау һәм бүләкләү турында килешүләр, дәүләти-хосусый партнерлык һәм концессия килешүләре турында килешүләр төзеп гамәлгә ашырыла торган масштаблы инвестиция проектларын үз эченә ала.

**Инвестиция активлыгын стимуллаштыру чараларын гамәлгә ашыру, инвестиция проектларын гамәлгә ашыру ысулларын һәм механизмнарын камилләштерү**

Инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы инвесторлар өчен Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә торган табышка салым ставкасын 13,5 процентка кадәр киметү һәм оешма тарафыннан проектны гамәлгә ашыру өчен

яңа булдырылган яки сатып алынган мөлкәткә салым буенча салым ставкасын 0,1 процентка кадәр киметү («Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы, «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы, «Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2008 елның 2 августындагы 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләре буенча) каралды.

Әлеге ташламалар проектларның үз-үзен аклау срогына бирелә, ләкин ул 7 елдан да артмаска тиеш, ә машина төзелеше тармагында инвестицияләр башланган вакыттан алып 13 елга кадәр срокка бирелергә мөмкин.

Дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1999 ел, 7 май, 284 нче һәм «Инвестиция эшчәнлеге субъекты белән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы арасында инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында шартнамә төзү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне һәм инвестиция проектын тормышка ашыру турында шартнамә формасын раслау хакында» 2006 ел, 24 июль, 377 нче карарлары белән регламентлаштырылды.

2022 елда инвестиция проектларын гамәлгә ашыру турындагы гамәлдәге шартнамәләр кысаларында 17 инвестиция проекты, шул исәптән «Бер үк вакытта саклана торган 150 000 тоннага бөртекле һәм майлы культуралар саклау өчен элеватор төзү» («Зәй элеваторы» ҖЧҖ), «Оксиэтиляцияләнгән продуктлар ассортиментын киңәйтү (метоксиполиэтиленгликоль (МПЭГ), каты полиэтиленгликоль (ТПЭГ)) («Түбән Кама нефть химиясе» ГАҖ), «Ozon күпләп-ваклап бүлү үзәге» («Зеленодольск 2 күпләп-ваклап бүлү үзәге» ҖЧҖ) проектлары гамәлгә ашырылды.

Якынча бәяләүләр буенча, 2006 елдан 2022 елга кадәр республикада инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә барлыгы 16 млрд сумга якын салым ташламалары бирелде. Әлеге проектларны гамәлгә ашыруга 761 млрд. сум инвестицияләр җәлеп ителде, 18 меңнән артык яңа эш урыны булдырылды, Татарстан Республикасы бюджетына салым түләүләре 27,2 млрд. сум дип бәяләнә.

Аерым территорияләрне тизләтелгән үстерү өчен шартлар тудыруга һәм эшкуарлык эшчәнлеген алып баруның преференциаль шартларын булдыруга юнәлдерелгән инвестиция мәйданчыклары уңышлы эшләвен дәвам итә, аларны, шул исәптән Россиядә иң эре сәнәгать-җитештерү тибындагы «Алабуга» махсус икътисадый зонасы (алга таба – «Алабуга» МИЗ) һәм «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы (алга таба – «Иннополис» МИЗ) булдыру мөмкинлеге федераль законнарда каралган.

**«Алабуга» МИЗ**

«Алабуга» махсус икътисадый зонасы республиканың нәтиҗәле инвестиция мәйданчыгының ачык мисалы булып тора. Аның резидентлары арасында «Полиматиз» АҖ, «СОЛЛЕРС Алабуга» ҖЧҖ, Rockwool, Kastamonu, Hayat,

Аурус, Air Liquide, «САРИЯ Био-Индастрис Волга» ҖЧҖ, Coşkunöz h.б. бар.

Сәнәгать-җитештерү эшчәнлеген 33 предприятие башкара. Резидентлар тарафыннан гамәлгә ашырылган инвестицияләрнең күләме барлык чор эчендә 162,2 млрд. сум тәшкил итте, резидентлар тарафыннан 8,8 мең эш урыны булдырылды, 2022 елда еллык керем күләме 137,8 млрд сум тәшкил итте.

2022 елда түбәндәгеләр «Алабуга» махсус икътисадый зонасы резидентлары статусын алды:

«ДАНАФИЛМЗ» ҖЧҖ – икенчел эшкәртү өчен яраклы пленкалы материаллар җитештерү;

«Соллерс Алабуга» ҖЧҖ – бер елга 50 мең автомобильгә кадәр СОЛЛЕРС АРГО һәм СОЛЛЕРС АТЛАНТ җиңел коммерция автомобильләре линейкасын җитештерү;

«АЛТРЕСТ» ҖЧҖ – суыткыч җиһазы өчен комплектлау эшләнмәләре җитештерүне оештыру;

«ТЕКСФЛОР» ҖЧҖ – каты ламинат идән өслекләре җитештерү буенча завод төзү;

«Алабуга Машинери» ҖЧҖ – сәнәгать җиһазы җитештерү;

«ИОНИК» ҖЧҖ – бер ела 30 мең тонна куәте булган полиакриламид җитештерүен булдыру.

**«Иннополис» махсус икътисадый зонасы**

«Иннополис» махсус икътисадый зонасы составында 338 компания, шул исәптән 125 резидент, 55 компания-партнер һәм 158 стартап бар.

Күрсәтелгән компанияләр эшли башлаганнан бирле 7 350 эш урыны булдырылган (шул исәптән 997 - 2022 елда), 78,8 млрд сум инвестицияләнгән (шул исәптән 19,9 млрд сум - 2022 елда). Башлангыч бәяләүләр буенча, табыш күләме 171,1 млрд сум тәшкил иткән (шул исәптән 58,1 млрд сум - 2022 елда).

2022 елда махсус икътисадый зонасы составына 68 яңа резидент, стартап һәм партнерлар кергән. Эре һәм әһәмиятле партнерларның берсе «Газпром» ГАҖ баш фәнни үзәге - «Газпром ВНИИГАЗ» ҖЧҖ. Ягулык-энергетика компанияләрендә җитештерү объектларының техник торышы һәм бөтенлеге белән идарә иткәндә карарлар кабул итүгә ярдәм итүнең интеллектуаль системаларын эшләү максатларында Татарстан Республикасының фәнни оешмалары белән хезмәттәшлек итү өчен компетенцияләр үзәген булдыру планлаштырыла. Инвестицияләрнең гомуми күләме 115,6 млн сум тәшкил итте.

«Иннополис» махсус икътисадый зонасында түбәндәге проектларны эшләү үзәкләре эшли башлады: Qummi (foodtech-стартап шок туңдыруы һәм ашамлыклар әзерләү технологиясен үстерәчәк), «БаСтрим» (тоташтырылган электр транспорты чараларыннан зур мәгълүматларны анализлау өчен интеллектуаль болыт платформасын эшләү), Test IT (үзебезнең тестлаштыру белән идарә итү системасы, ул программа белән тәэмин ителешне эшләргә мөмкинлек бирә һәм дөнья аналоглары дәрәҗәсендә программа белән тәэмин итүнең функциональлеген тәэмин итү өчен кулланыла).

Узган чорда «Иннополис» махсус икътисадый зонасы резидентлары һәм партнерлары компанияләре тарафыннан финанслар, корпоратив системалар,

болытлы компьютинг, интеллектуаль транспорт системалары һәм башка юнәлешләрдә чит ил продуктларын алыштыра алырлык 50 дән артык карар эшләнде.

Иң мөһим проектлар арасында түбәндәгеләрне билгеләп үтәргә кирәк:

«СКБ Инфоматика» ҖЧҖ - 2022 елгы ФИФА футбол буенча дөнья чемпионатын әзерләүдә һәм үткәрүдә катнашкан тамашачыларга электрон контроль системасын тәэмин итүче бердәнбер Россия компаниясе;

«Дронопорт» ҖЧҖ дронопорт булдырган, ул Согуд Гарәбстанында «Неом» шәһәр-бакчасы төзү проектында һәм Берләшкән Гарәп Әмирлекләре урамнарында трафик мониторингы өчен кулланыла;

«ИВКС» ҖЧҖ үзебезнең Zoom - IVA MCU видео-конференц-элемтә платформасы эшләгән, аның ярдәмендә МКС белән видео-конференц-элемтә оештырылган.

Декабрьдә махсус икътисадый зона территориясендә «ИнноПарк» югары технологияләр өлкәсендә технопарк төзелеше тәмамланды, анда алдынгы фәнни-техник, инновацион һәм югары технологияле җитештерү эшчәнлеге алып баручы компанияләр урнаша алачак.

Лаеш муниципаль районында «Иннополис» махсус икътисадый зонасының икенче мәйданчыгын үстерү дәвам итә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 июлендәге 708 номерлы карары нигезендә «Иннополис» МИЗ» АҖ идарәче компаниясе белән «Лаеш» индустриаль паркы булдырылды, анда якорь резиденты - ICL компаниясе урнашачак, ул төп платалар җитештерү белән шөгыльләнәчәк.

**Инфраструктураны финанслау механизмы**

Республикада төбәкләрдә инфраструктураны үстерүнең яңа механизмы гамәлгә ашырыла, ул бер яктан инвестиция проектларын кирәкле инфраструктура белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирә, ә икенче яктан - Россия Федерациясе алдындагы бюджет кредитлары буенча республика бурычын федераль салымнар проектлары белән берләштерелгән күләмдә түләргә мөмкинлек бирә (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчаларын гамәлгә ашыру максатларында Россия Федерациясе субъекты тарафыннан инфраструктура объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыруга җибәрелергә тиеш бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе алдындагы Россия Федерациясе субъекты алдындагы бурычны түләү күләмен киметү нәтиҗәсендә бушатыла торган яңа инвестиция проектларын билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 19 октябрендәге 1704 номерлы карары нигезендә).

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2021 елның 28 июнендәге 386 номерлы боерыгы нигезендә яңа инвестиция проектларының җыелма исемлегенә 208,8 млрд сумлык инвестицияләр күләме булган 11 Татарстан проекты кертелде. Хәзерге вакытта инфраструктураны булдыру буенча инвестор чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан 8,7 млрд сум акча бирелгән. Әлеге проектлардан салым кертемнәре 2022 елда республиканың 1,7 млрд сум күләмендә бурычын түләргә мөмкинлек бирде.

**Алгарышлы үсеш территорияләрен үстерү**

2016 елдан башлап Татарстанда Чаллы, Түбән Кама, Чистай, Зеленодольск һәм Менделеевск моношәһәрләрендә алгарышлы үсешнең 5 территориясе (алга таба - АҮТ) эшләп килә.

Социаль-икътисадый үсеше алга киткән территорияләр резидентлары өчен түбәндәге преференцияләр каралды:

табышка салымның киметелгән ставкасы (федераль бюджетка исәпләү өлешендә – эшчәнлектән беренче табыш алынган вакыттан беренче 5 салым чоры дәвамында 0 процент; Россия Федерациясе субъектлары бюджетына исәпләү өлешендә – беренче табыш алынган вакыттан 5 салым чоры дәвамында 5 процент һәм киләсе 5 салым чоры дәвамында 10 процент);

оешмалар мөлкәтенә салым түләүдән азат итү;

җир салымын түләүдән азат итү;

иминият кертемнәренең бердәм түбән тарифы (мәҗбүри пенсия иминләштерүенә, вакытлыча хезмәткә яраксызлык һәм ана булу белән бәйле очракта мәҗбүри социаль иминләштерүгә, мәҗбүри медицина иминиятләштерүенә) гадәти тәртиптә түләнә торган 30% урынына 7,6% күләмендә. Ташлама алгарышлы үсеш территорияләре резиденты статусын алган көннән 10 ел дәвамында бирелә һәм алгарышлы үсеш территорияләре булдырылган көннән өч елдан да соңга калмыйча шундый статус алган резидентларга карата кулланыла.

2023 елның 1 гыйнварына алгарышлы үсеш территорияләрендә 129 резидент теркәлгән, алар 55,2 млрд сум инвестицияләнгән (бөтен чорда арта барган нәтиҗә белән, шул исәптән 13,3 млрд сумнан артык - 2022 елда), 21,8 мең яңа эш урыны булдырылган (шул исәптән 1,5 меңнән артык - 2022 елда). Резидентлар кереме күләме 259,0 млрд сумнан артык (шул исәптән 88,4 млрд сум - 2022 елда) тәшкил иткән.

Алгарышлы үсеш территорияләре резидентларына бирелә торган салым ташламалары моношәһәрләргә зур бизнес вәкилләрен (Haier, OZON, Wildberriesм и «КазаньЭкспресс») җәлеп итәргә мөмкинлек бирде, кече һәм урта эшкуарлык үсешенә ярдәм итте.

Күрелгән чаралар нәтиҗәсендә моношәһәрләр икътисады структурасын диверсификацияләү гамәлгә ашырыла, кече һәм урта эшкуарлык үсә.

«Чаллы» алгарышлы үсеш территориясе резидентлары төяп җибәргән продукция өлеше, шәһәр округы буенча тулаем төяп җибәрелгән продукция күләменең 10 % артыграгын тәшкил итә. «Зеленодольск» алгарышлы үсеш территориясендә (халык саны – 100 мең кеше) резидентлар тарафыннан кабул ителгән йөкләмәләрдән алга китеп 11,6 мең эш урыны булдырылды.

2022 елда барлыгы биш алгарышлы үсеш территориясенә планлаштырылган инвестицияләр күләме 2,5 млрд сумнан артык булган 16 яңа резидент җәлеп ителде.

**Моношәһәрләрне үстерү**

Моношәһәрләрне үстерү өчен яңа мөмкинлекләр «ВЭБ.РФ» (алга таба - ВЭБ.РФ) дәүләт корпорациясенә ярдәм итү программасы бирә, аның максаты - моношәһәрләр икътисадын диверсификацияләү, эш урыннары булдыру һәм

моношәһәрләргә инвестицияләр җәлеп итү өчен кирәкле шартлар тудыру.

Республиканың инфраструктура проектларына финанс ярдәменең гомуми суммасы 5,3 млрд сумнан артык тәшкил итә, шул исәптән РФ ВЭБ чаралары хисабына - 3,3 млрд сум. Төзелгән инфраструктура ярдәмендә инвестицион проектларны гамәлгә ашыру кысаларында 42,6 млрд сум инвестицияләр җәлеп ителде һәм 17,9 меңнән артык эш урыны булдырылды.

2022 елның 22 ноябрендә РФ ВЭБ белән Чаллы моношәһәрендә инфраструктура төзү һәм (яисә) реконструкцияләү максатларында Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын финанслашу турында килешү төзелде. Haier заводлары өчен мәйданчыктан тыш челтәрләр төзү буенча проектның бәясе - 163,39 млн сум, шул исәптән РФ ВЭБ чаралары хисабына - 65,36 млн сум. Гамәлгә кертүнең планлаштырылган срогы - 2023 елның июне. Проектны гамәлгә ашыру 2027 елга 1 158 эш урыны булдырырга һәм 9,2 млрд сум инвестицияләр җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк. 2023 елның 1 гыйнварына «Хайер» ҖЧҖ дә 432 эш урыны булдырылган һәм 4,4 млрд сум инвестицияләр җәлеп ителгән.

2022 елның 30 декабрендә РФ ВЭБ белән Зеленодольск моношәһәрендә инфраструктура объектларын төзү һәм (яисә) реконструкцияләү максатларында Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын финанслашу турында килешү төзелде (Свияжск төбәкара мультимодаль логистика үзәге өчен инженерлык һәм юл инфраструктурасы объектларын төзүгә). Проектның бәясе - 1,4 млрд сум, шул исәптән РФ ВЭБ чаралары хисабына - 601,37 млн сум. Гамәлгә кертүнең планлаштырылган срогы - 2024 елның июне. Проектны гамәлгә ашыру 2027 елга 1 723 эш урыны булдырырга һәм 7,1 млрд сум инвестицияләр җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Моннан тыш, РФ ВЭБ заем акчаларын җәлеп итү турында килешү гамәлгә ашырыла, аның гомуми суммасы 3,3 млрд сумга якын.

2022 елның мартында РФ ВЭБ заемнар рәвешендә инвестиция проектларын финанслауда катнашу турында ике килешү имзаланды: «Сальэра» ҖЧҖ белән - ярымфабрикатлар производствосын төзү буенча һәм «Логист-Инвест» ҖЧҖ белән - склад комплексын төзү буенча. Бурычлар буенча РФ ВЭБ йөкләмәләре 500 млн сум тәшкил итә. 2022 елның июнендә РФ ВЭБ һәм «Хайер Индастри Рус» ҖЧҖ арасында 250 млн сум күләмендә заем акчалары бирүгә килешү имзаланды.

**Дәүләт-хосусый партнерлыгы**

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы уздырган рейтингта Татарстан Республикасы 2022 елда дәүләти-хосусый партнерлыгын (алга таба - ДХП) үстерү дәрәҗәсе буенча 67 нче урыннан 6 нчы урынга, шул исәптән ДХП проектларын гамәлгә ашыру динамикасын бәяләү факторы буенча - 37 нче урыннан 5 нче урынга, ДХП проектларын гамәлгә ашыруның тупланган тәҗрибәсе буенча - 42 нче урыннан 35 нче урынга, норматив-институциональ мохит торышы буенча - 85 нче урыннан 8 нче урынга күтәрелде.

Татарстан Республикасы 2022 елның 11 гыйнварыннан проектны гамәлгә ашыруга инвестицияләр күләме 82,5 млрд сум булган Шәле (М-7) - Баулы (М-5) түләүле автомобиль юлы составында Әлмәт - Алексеевск автомобиль юлын төзү һәм эксплуатацияләү турында концессион килешү төзеде.

Моннан тыш, 8 млрд сумнан артык инвестицияләр күләме белән Казан шәһәрендә, Чаллы шәһәрендә һәм Арча муниципаль районында гомуми белем бирү мәктәпләрен төзү турында өч концессион килешү имзаланды.

2022 елның ахырына җыелган нәтиҗә белән планлаштырылган инвестицияләрнең гомуми күләме 1,6 млрд сум булган 94 энергия сервисы контракты төзелгән.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 29 декабрендәге 1442 номерлы карары белән Татарстан Республикасында Дәүләт-хосусый партнерлыгын һәм муниципаль-хосусый партнерлыкны үстерү концепциясе кабул ителде.

**Конгресс-күргәзмә чаралары**

Конгресс-күргәзмә чараларын үткәрү республиканың инвестицион потенциалын алга җибәрүдә мөһим юнәлеш булып тора.

2022 елның 19-21 маенда «Россия - Ислам дөньясы: KazanSummit 2022» XIII Халыкара икътисадый саммиты узды, анда 64 илдән 6 388 кунак катнашты.

13 ел дәвамында «Россия - Ислам дөньясы: KazanSummit» Халыкара икътисадый саммиты халыкара оешмалар, дәүләт хакимияте органнары, финанс институтлары, илчелекләр, парламентлар депутатлары, әйдәп баручы инвесторлар һәм бизнесменнар, Россия һәм чит ил компанияләренең топ-менеджерларын берләштерә. Саммит үзен яңа элемтәләр урнаштыру өчен уңышлы бизнес платформа сыйфатында күрсәтте, шулай ук икътисадый мөмкинлекләрне һәм инвестицион потенциалны тәкъдир итү өчен ярдәм булды. Саммитның төп темалары ислам финанслары һәм партнерлык банкингы, хәләл индустрия, яшьләр дипломатиясе, экспорт, эшкуарлык һәм инвестицияләр үсеше булды. Чара кысаларында Russia Halal Expo 2022 күргәзмәсе, Машина төзелеше кластерлы форумы, Бөтендөнья хәләл көне һәм Идел Болгарында ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган чаралар узды.

2023 елда Россия Федерациясе Президентының 2023 елның 17 гыйнварындагы 17 номерлы Указы белән федераль статус бирелде.

2022 елның сентябрендә Kazan Digital Week Халыкара форумы булды, ул ел саен белгечләрнең эшлекле аралашуын үстерү максатларында уздырыла.

Форум нәтиҗәләре аның кирәклеген раслады. 10 төп юнәлеш буенча 143 программа чарасында 13,5 мең кеше, шул исәптән Россия Федерациясе төбәкләреннән һәм якын чит илләрдән 660 спикер катнашты, форум эшен онлайн форматында 4 мең кеше күзәтте. Күргәзмә мәйданчыгында 222 компания тәкъдим иткән югары технологияле продукция үрнәкләре белән 133 экспонент урнаштырылган иде.

Эшче секцияләрен һәм махсуслаштырылган партнерлык чараларын тулыландыру статистикасы күрсәткәнчә, катнашучылар һәм күзәтүчеләрнең кызыксынуы автоном механизмнар һәм машиналарны, экологик чиста энергетика компонентларын, идарәнең, сәнәгать җитештерүенең һәм комплекслы куркынычсызлыкны тәэмин итүнең югары автоматлаштырылган технологияләрен эшләүгә һәм практикага юнәлдерелә.

Узган форумның яңалыгы - партнерлык чаралары, аларда хакимият, фән һәм бизнес вәкилләре икътисадның реаль секторын цифрлы трансформацияләү перспективалары һәм оештыру, финанс, хокукый һәм фәнни-техник проблемалар турында фикер алыштылар.

Россиянең Көнбатышның кайбер илләреннән мәҗбүри икътисадый изоляциясе вәзгыятендә Kazan Digital Week Халыкара форумы аеруча әһәмияткә ия - стратегик Россия һәм Көнчыгыш Азия партнерларының нәтиҗәле хезмәттәшлеге өчен плацдарм булып тора.

2022 елның 6 октябреннән 7 октябренә кадәр 100tatarstan.com цифрлы мәйданчыгында ел саен уздырыла торган «100% Татарстан» онлайн-форумы булды, аның темасы - территорияләрне төзү һәм үстерү. Чарада 190нан артык Россия һәм халыкара экспертлар, шулай ук төзүчеләр һәм девелоперлар, интерьер дизайнерлары, төзелеш материаллары җитештерүчеләр, төзелеш базары профессионаллары, депутатлар, «СИБУР» ҖЧҖ, «Росатом» дәүләт корпорациясе, «Газпром инвест» ҖЧҖ, В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ҖАЖ, «Татэнерго» АЖ, «Ромекс-Кубань» ҖЧҖ һәм башкалар кебек эре федераль һәм төбәк компанияләре җитәкчеләре катнашты. Турыдан-туры трансляцияләрне дөньяның 27 иленнән һәм Россиянең 21 төбәгеннән 4 мең кеше карады.

2022 елның 23 ноябрендә Бәшир Рәмиев исемендәге ИТ-парк мәйданчыгында Дәүләт-хосусый партнерлыгы буенча V тармак форумы узды, анда Россия Федерациясенең 34 субъектыннан 400дән артык эксперт катнашты. Социаль өлкәдә, торак-коммуналь хуҗалыгында, юл инфраструктурасында ДХП механизмын куллану кейслары турында фикер алыштылар.

## КЕЧЕҺӘМ УРТА ЭШКУАРЛЫК

Татарстан Республикасында 2023 елның 1 гыйнварына:

кече һәм урта эшкуарлыкның 165,4 мең субъекты (алга таба - КУЭ) теркәлгән, бу 2022 ел башына карата 5 009 субъектка (3 процентка) күбрәк;

КУЭ белән шөгыльләнүчеләр саны, индивидуаль эшкуарларны һәм үзмәшгульләр санын да кертеп, 767,5 мең кеше исәпләнә, бу 2022 ел башына карата 42,1 мең кешегә күбрәк (5,8 процентка);

республика икътисадында эшләүчеләрнең гомуми санында КУЭ эшләүчеләр өлеше - 38,6 процент, бу 2022 ел башына карата 2,1 процентка күбрәк;

үзмәшгульләр саны 234,2 мең граждан тәшкил иткән, бу 2022 ел башына карата 65,2 мең кешегә (38,5 процентка) күбрәк;

КУЭ субъектларыннан салым кертемнәре күләме - 42 млрд сум, бу 2022 ел башына караганда 7,9 млрд сумга күбрәк (23,2 процентка).

***Татарстан Республикасы КУЭ субъектларына ярдәм инфраструктурасы***

Татарстан Республикасында КУЭ субъектларына ярдәм инфраструктурасы оешмалары төзелде һәм эшли.

Алар исәбенә «Татарстан Республикасы эшкуарлыкны яклау фонды» МКК КБО *(«Минем бизнес» үзәге, Эшкуарлыкка ярдәм итү үзәге, Социаль өлкә инновацияләре үзәге, Бизнес өчен күпфункцияле үзәк, Микрофинанслау үзәге, Экспортка ярдәм үзәге),* «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» КБО, «Татарстан Республикасы Төбәк лизинг компаниясе» АҖ, «Татарстан Республикасы кластерлы үсеш һәм проект идарәсе үзәге» АКБО, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү программаларын гамәлгә ашыру үзәге» ДКУ керә.

Әлеге оешмалар, шул исәптән «Кече һәм урта эшкуарлык һәм индивидуаль эшкуарлык инициативасына ярдәм күрсәтү» илкүләм проектын гамәлгә ашыру кысаларында, КУЭ субъектларына финанс һәм финанс булмаган ярдәм чаралары комплексы күрсәтелә. 2022 елда мондый чаралар белән 30 меңнән артык КУЭ субъекты файдаланды, шулардан 6 меңнән артык субъект 83 млрд сумга якын финанс ярдәме алды, шул исәптән:

*республика ярдәм күрсәтү чаралары:*

3,7 млрд сумга 668 поручительлек бирелгән (2021 елда - 1,8 млрд сумга 404 поручительлек);

1,5 млрд сумлык 777 ташламалы микрозайм бирелгән (2021 елда - 0,9 млрд сумлык 539 микрозайм);

9,99 млн сумга 9 оешмага электр энергиясенә чыгымнар субсидияләнгән (2021 елда - 2,9 млн сумга 4 алучыга);

47,0 млн сумлык 119 грант бирелгән (2021 елда - 9,0 млн сумлык 23 грант);

342,8 млн сумлык 37 лизинг алучы.

*федераль ярдәм күрсәтү чаралары:*

1 155 КУЭ субъекты өчен 8,8 млрд сумга кредит каникуллары бирелгән;

«Инвестицион» кредитлауны стимуллаштыру программасы буенча ярдәм күрсәтүдән 3,9 млрд сумга 146 алучы файдаланды;

Россия Федерациясе Үзәк банкы программасы буенча «Оборотная» кредитлауны стимуллаштыру программасы буенча 322 КУЭ субъектына 7,3 млрд сумга ярдәм күрсәтелде;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре өчен ташламалы кредитлаудан 29,3 млрд сумга 507 алучы файдаланган;

кредит бирүне субсидияләү (1 151 алучыга) - 15,1 млрд сумга;

2,5-4% еллык ставка буенча ташламалы кредитлау 2,5 млрд сумга 28 алучыга бирелгән;

реструктуризация (955 алучы) - 9,8 млрд сумга.

***Мәгълүмат-консультация һәм белем бирү характерында ярдәм күрсәтү, алга этәрү, сертификацияләү хезмәтләре күрсәтү, экспортка чыгу һ.б.***

*Экспортка ярдәм үзәге.*

Экспортка ярдәм үзәге тарафыннан 500 дән артык КУЭ субъектына «Кече һәм урта эшкуарлык һәм шәхси эшмәкәрлек инициативасына ярдәм» илкүләм проекты кысаларында ярдәм күрсәтелгән, чит ил базарларына 60тан артык КУЭ субъекты чыкты.

Экспорт эшчәнлеген популярлаштыру максатында Экспортны яклау үзәге тарафыннан 8 түгәрәк өстәл, 20 вебинар һәм 2 конференция үткәрелде, алар барышында экспорт эшчәнлеге инструментлары һәм чит илләр белән экспорт сәүдә мөмкинлекләре каралды (Төркия Республикасы, Кытай Халык Республикасы, Марокко Корольлеге, Көньяк Африка Республикасы, Үзбәкстан Республикасы, Казахстан Республикасы, Әзербайҗан Республикасы).

26 апрельдә «Ел экспортеры» ел саен уздырыла торган төбәк конкурсы булды, анда КУЭ субъектлары арасында иң яхшы экспортерлар бүләкләнде. Конкурска кече һәм урта эшкуарлар арасыннан предприятиеләр-экспортерлардан 70 заявка кергән.

*Эшкуарлыкка ярдәм үзәге*

Эшкуарлыкка ярдәм үзәге тарафыннан 25 меңнән артык КУЭ субъекты һәм үзмәшгуль гражданнар өчен 40 меңнән артык хезмәт күрсәтелде, 40тан артык чара оештырылды, шул исәптән Татарстан Республикасы Эшкуар көне; үз продукциясе күргәзмәләрен оештыру белән үзмәшгуль гражданнар форумнары; үзмәшгуль гражданнар өчен ярминкәләр; «Корпорация «МСП» АҖ эшләгән 23 тренинг, аларда 450дән артык кеше катнашкан; 300 кеше катнашында «Хатын-кыз эшкуарлыгы» укыту программасы; 100 кеше катнашында «Франшиза аша бизнесны масштаблаштыру» программасы; 120 яшь эшкуар катнашында «Мәктәп бизнес-старт» проектының хәйрия ярминкәсе.

Эшкуарлыкка ярдәм үзәге катнашында 1 700дән артык комплекслы хезмәт күрсәтелде, алар кысаларында эшкуарлар Россия Федерациясе территориясендәге күргәзмә-ярминкә чараларында катнаштылар, продукциягә сертификациял алдылар, патент тикшерүләре уздырдылар, маркетплейсыларга чыктылар, электрон документлар әйләнеше өчен сервислар, бухгалтерия алып бару хезмәтләре, КУЭ хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү хезмәтләре, үз продукциясен алга чыгару буенча һәм digital-мохиттә хезмәт күрсәтүләр алдылар. 2 100дән артык үзмәшгуль гражданнар мәгълүмати-консультация хезмәтләре,

күргәзмәләрдә һәм ярминкәләрдә катнашу буенча, маркетплейсларда урнаштыру буенча хезмәтләр алды.

Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасы нигезендә 2022 елда мәктәп компанияләре практикумнарын булдыру аша эшкуарлык күнекмәләрен үстерү буенча өлкән сыйныф укучылары өчен һөнәри юнәлеш проекты гамәлгә ашырылды, анда 12 меңнән артык укучы катнашты.

*Социаль өлкә инновацияләре үзәге*

Социаль өлкә инновацияләре үзәге 157 КУЭ субъекты кергән социаль предприятиеләр реестрын төзүне дәвам итте.

КУЭ субъектлары өчен социаль эшкуарлык өлкәсендә квалификация күтәрү буенча өстәмә һөнәри белем бирү программасы буенча социаль предприятиеләрнең 53 вәкиленә ярдәм күрсәтелгән. Конкурста сайлап алу нәтиҗәләре буенча 48 социаль предприятие 18 млн сумнан артык грант алды.

Социаль эшкуарлык, проектларны үстерү, агымдагы эшчәнлек һәм ярдәм чаралары мәсьәләләре буенча 2 500 консультация уздырылды. Үзәк хезмәткәрләре 40 тан артык чара уздырган, шул исәптән республиканың муниципаль районнарында да.

2022 елдан социаль контракт буенча субсидияләрдән нәтиҗәле файдалану максатларында, социаль контракт төзүгә дәгъва кылучы гражданнар эшкуарлык эшчәнлеген алып бару һәм бизнес-план төзү мәсьәләләре буенча укыту программалары узарга мөмкин. 2022 елда 1 000нән артык граждан укыды һәм сертификаты алды.

Социаль эшкуарлык өлкәсендәге проектларның «Елның иң яхшы социаль проекты – 2021» бөтенроссия конкурсына йомгаклар ясалды. Өлкәннәрне карау өлкәсендәге проблемаларны хәл итүгә юнәлдерелгән Татарстан проекты абсолют җиңүче булды («Содействие» социаль ярдәм үзәге» коммерцияле булмаган автоном оешмасы, Чаллы шәһәре). Конкурска 30 заявка бирелгән иде. Төбәк этабында 6 проект җиңүче булып танылды, алар конкурсның федераль этабында катнашачак. Конкурска йомгаклар 2023 елның III кварталында ясалачак.

***Интернет-сәүдәне үстерү***

Эшкуарларга комплекслы ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 17 ноябрендәге 2363-б номерлы боерыгы белән расланган 2021-2022 елларга Татарстан Республикасында интернет-сәүдәне үстерү программасы (Чаралар планы) гамәлгә ашырылды. Нәтиҗәдә, соңгы ике елда Татарстан Республикасында интернет-сәүдә белән бәйле секторларда, шулай ук ярдәмче тармакларда 100 меңгә якын яңа эш урыны булдырылды. Маркетплейсларда Татарстан сатучылары саны 2022 елда 2 мәртәбә артты – 45 меңгә кадәр, аларның сату күләмнәре 50 млрд сумнан артып китте, Татарстан Республикасы бюджетына керемнәр - 3 млрд сум. Программа түбәндәге блокларны үз эченә ала:

*интернет-сәүдә инфраструктурасын үстерү* - продукция кабул итү пунктларының географиясен киңәйтү, логистика компанияләре белән хезмәттәшлекне оештыру, логистика бүлү үзәкләрен төзегәндә ташламалар һәм

ярдәм чаралары бирү буенча чаралар блогы;

интернет мәйданчыкларга чыкканда эшкуарларны теркәү, даими булышлык *күрсәтеп тору һәм консультация бирү.* Бу блокта финанс ярдәме һәм финанс булмаган ярдәм чараларына аерым игътибар бирелә. Эшкуарлар өчен электрон сәүдә мәйданчыкларына товарлар урнаштыру һәм алга этәрү хезмәтләре күрсәтелде, шулай ук махсус кредит һәм микрофинанс продуктлары бирелде.

Т*ышкы икътисадый эшчәнлек.* Блокның билгеләнеше - халыкара электрон мәйданчыклар һәм транспорт-логистика провайдерлары белән хезмәттәшлекне киңәйтүгә КУЭ соравын канәгатьләндерү. Экспортка ярдәм үзәге Алибаба, Эпиньдо, ЛеснойРесурс.рф, Топфраншиз, Трендиол, Туркишэкспортер кебек халыкара маркетплейсларда продукция урнаштыру хезмәте күрсәтте.

Маркетплейслар белән нәтиҗәле эшләү өчен Татарстан Республикасы эшкуарлыкны яклау фонды аккаунт-менеджер белгечлеге буенча КУЭ субъектлары вәкилләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү буенча укыту программасы уздырды.

2023 елда интернет-сәүдәне үстерү эше 2023-2025 елларга Татарстан Республикасында интернет-сәүдәне үстерү программасы (Чаралар планы) кысаларында дәвам итәчәк (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 27 гыйнварындагы 138-б номерлы боерыгы белән расланган).

***Югары технологияле эшкуарлыкка ярдәм***

«Университет технологик эшкуарлыгы платформасы» федераль проекты кысаларында Инновацияләргә ярдәм фонды тарафыннан 2022 елда беренче тапкыр «Студентлар стартабы» конкурсы уздырылды (конкурсның 2 чираты узды).

Конкурс, студентларның коммерцияләштерү потенциалы булган һәм үсешнең иң иртә стадиясендә торган үз фәнни-техник һәм технологик тикшеренүләр нәтиҗәләрен кулланып, яңа товарлар, эшләнмәләр, технологияләр яки хезмәтләр эшләүгә юнәлтелгән.

Россия Федерациясенең 82 төбәгеннән 4 меңнән артык заявка бирелгән. Бирелгән (745) һәм хупланган (135) заявкалар саны буенча Татарстан 2 нче урынны алды. Ике конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча 135 җиңүче билгеләнде, шул исәптән беренче чиратта 81 җиңүче һәм икенче чиратта 54 җиңүче. Һәр җиңүче үзенең инновацион проектын тормышка ашыру өчен 1 миллион сум акча алды.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан «Студентлар стартабы» грант программасында җиңүчеләр булган проектлар белән идарә итү буенча юл картасы расланды. Инновацияләргә ярдәм фондының төбәк вәкиле буларак Татарстан Республикасы эшкуарлыгын яклау фонды «Студентлар стартабы» грант программасында җиңүчеләрнең проектларын гамәлгә ашыруны мониторинглау өчен җаваплылык үзәге буларак билгеләнде. Җиңүче проектлар тармак министрлыкларына (ведомстволарына), югары белем бирү мәгариф оешмаларына һәм республика предприятиеләренә киләчәктә аларны гамәлгә ашыру өчен беркетелгән.

***Сәнәгать паркларын үстерү***

Республиканың сәнәгать парклары территорияләрендә 1 500 резидент

эшчәнлек алып бара, 55 меңнән артык эш урыны булдырылган. Сәнәгать паркларын үстерү эш урыннарын булдыруга һәм модернизацияләүгә, тотрыклы салым түләүләренә, авылда кече бизнесны эш белән тәэмин итүнең альтернатив төрләрен, социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерүгә, хезмәткә мотивация формалаштыруга, квалификацияле хезмәткәрләрне җәлеп итүгә юнәлдерелгән.

КУЭ ярдәм итү инфраструктурасының төп объектлары түбәндәгеләр:

«Химград» технополисы (2022 ел йомгаклары буенча: эшчеләрнең 10,2 мең гомуми саны белән 367 резидент, табыш – 68,1 млрд сум);

«Мастер» Кама индустриаль паркы (2022 ел йомгаклары буенча: эшчеләрнең 12,3 меңнән артык гомуми саны белән 288 резидент, резидентларның табышы – 148,9 млрд сум).

Инвесторлар өчен инфраструктурасы үсеш алган зур шәһәрләрдә, Казанда һәм Чаллыда сәнәгать парклары җәлеп итүчәнрәк булуын аңлап, эш урыннарын «йорт янында» төзеп, хезмәт миграциясе мәсьәләләрен дә хәл итү өчен авыл сәнәгать парклары белән вәзгыятьне яхшырту чаралары эшләнде.

Татарстан Республикасы Рәис белән Авыл җирлегендә территорияләрне комплекслы үстерү өчен сәнәгать паркларының нәтиҗәлелеген арттыру концепциясе килештерелде, аның кысаларында аккредитацияләнгән сәнәгать паркларының резидентларына һәм идарәче компанияләренә түбәндәге преференцияләрдән файдаланырга мөмкинлек бирә торган закон инициативалары кабул ителде:

салым салуның гадиләштерелгән системасы буенча салым ставкаларын (керемнәргә ставка – 1 процент, керемнәргә минус чыгымнар – 5 процент) киметергә;

транспорт салымы (0 %) һәм оешмалар мөлкәтенә салым (0 %) буенча салым ташламалары алырга.

10 елга кадәр салым ташламаларыннан аккредитацияләнгән, тутырылышы түбән дәрәҗәдә булган сәнәгать парклары территорияләрендә эшчәнлек алып барган һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән Килешү төзегән резидентлар һәм идарәче компанияләр файдаланырга мөмкин.

4 сәнәгать паркының («Түбән Кама», «Промзона-Минзәлә», «Алексеевск», «Арча») инженер һәм юл инфраструктурасы төзелешенә 135,37 млн сум җибәрелгән. Бу сәнәгать паркларының гамәлдәге 44 һәм потенциаль резидентларының җитештерү эшчәнлеге өчен уңай шартлар тәэмин итәчәк.

«Кече һәм урта эшкуарлык һәм индивидуаль эшкуарлык инициативасына ярдәм күрсәтү» илкүләм проекты кысаларында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын «үстерү» буенча «Кече һәм урта эшкуарлык корпорациясе» акционерлык җәмгыяте программасын тормышка ашыру дәвам итә. Программада республиканың 45 предприятиесе катнашты, алар өчен «МСП» корпорациясе» АҖ цифрлы платформасында скоринг бәяләүләре уздырылды, индивидуаль үсеш карталары эшләнде һәм гамәлгә ашырыла. 2020-2022 елларда программада катнашучыларга 3,3 млрд сумнан артык суммага финанс ярдәме чаралары күрсәтелде, шул исәптән «Фәнни-техник өлкәдә кече формадагы предприятиеләр үсешенә ярдәм фонды» ФДБУ һәм «Технологик үсеш агентлыгы» АКБО

грантлары, «Россия технологик үсеш фонды» ФДАУ заемнары, ташламалы кредитлау, ташламалы заемнар һәм башкалар. Бу чорда 350гә якын финанс булмаган ярдәм чарасы күрсәтелгән (продукцияне популярлаштыру, продукцияне сертификацияләү, патент тикшеренүләре, маркетинг тикшеренүләре, товар билгесен теркәү, техник-икътисадый нигезләү эшләү һ.б.).

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан 73 сәнәгать паркы аккредитацияләнгән, шул исәптән 15 - 2022 елда.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 октябрендәге 1119 номерлы карарын гамәлгә ашыру кысаларында индустриаль парклар, сәнәгать технопарклары һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын субсидияләү буенча 2021 елда федераль бюджеттан «Алабуга», «Алабуга-2. Нефть химиясе» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы проектларын гамәлгә ашыруга 9,5 млрд сумнан артык акча җәлеп ителде.

***Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының сатып алулардан файдалану мөмкинлеге.***

Сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасы zakupki.gov.ru мәгълүматлары буенча, 2022 елда КУЭ сатып алулар суммасы 108,8 млрд сум тәшкил иткән, бу 2021 ел дәрәҗәсеннән 21 млрд сумга күбрәк.

КУЭ субъектларыннан сатып алуларны арттыру максатларында планлаштырылган сатып алуларның еллык күләменнән кимендә 25% күләмендә КУЭ сатып алулар башкару предметына республиканың иң эре заказчыларына карата сатып алулар планнарын бәяләү һәм мониторинглау уздырыла (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 19 апрелендәге 717-б номерлы боерыгы, «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон).

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан 31 эре заказчының сатып алулар планының 3 000 проекты каралды һәм килештерелде, алар КУЭ субъектларыннан сатып алуларның яртысыннан артыгын (61,2%) 54,6 млрд сумга тормышка ашырган.

Бизнесның электрон сатуларда катнашуын тәэмин итү максатларында республиканың муниципаль берәмлекләре белән берлектә 2022 елда Республика маркетинг үзәге ресурсларында 4,4 меңгә якын Татарстан эшмәкәре - КУЭ субъектлары 193,5 млрд сум күләмендә табыш алды.

***Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеге процессларын цифрлаштыру***

Россия Икътисадый үсеш министрлыгы контроль (күзәтчелек) эшчәнлеге процессларын цифрлаштыруга зур игътибар бирә.

2022 елда республика контроленең пилот органнары (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе, Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге

инспекциясе, Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау буенча комитеты) үз эшчәнлекләренә бизнес һәм контроль органнары чыгымнарын киметергә мөмкинлек бирә торган дистанцион контроль һәм күзәтчелекнең түбәндәге цифрлы инструментларын керттеләр:

«Инспектор» мобиль кушымтасы (дистанцион тикшерүләргә күчү);

«Төзелеш күзәтчелеге» модуле (төзелеш күзәтчелеге органнарының цифрлы вертикален төзү);

«Административ җитештерү» модуле (административ җаваплылыкка тарту практикасын камилләштерү).

Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеге процессларын цифрлаштыру кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 21 мартындагы 552-б номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән берлектә контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген мониторинглауның аналитик модулен булдыру һәм “Тикшерелгән бизнес” сайтын модернизацияләү эше оештырылды. «Тикшерелгән бизнес» интернет-порталында үткәрелгән эшләр нәтиҗәләре буенча (алга таба - ресурс) түбәндәге функционал кертелгән:

Бердәм контроль (күзәтчелек) чаралары реестрының һәм Бердәм тикшерүләр реестрының (аналитик модуле) ачык белешмәләреннән алына торган мәгълүматлар фабрикасы элементлары базасында контроль органнары (алга таба - КТО) үткәргән тикшерүләрне электрон исәпкә алу;

контрольнең 40 төре буенча интерактив чек-битләр (эшкуарлар тарафыннан үз-үзләрен тикшерү өчен);

стандарт хокук бозулар белешмәлеге (эшчәнлек барышында эшкуарлар тарафыннан рөхсәт ителә торган бертип хокук бозулар);

чаралар нәтиҗәләре буенча сораштырулар (кире элемтә модуле);

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Россия Федерациясе Генераль прокуратурасының интернет-кабул итү бүлмәсе адресына мөрәҗәгать итү мөмкинлеге;

тикшерү яки профилактик визит нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр калдыру мөмкинлеге; тикшерүче органнарның намуссыз гамәлләренә зарлану.

***Контроль-күзәтчелек эшчәнлеге реформасы.***

Республика контроль-күзәтчелек эшчәнлеге реформасы чараларын гамәлгә ашыруда, шул исәптән федераль дәрәҗәдә дә, актив катнаша.

Контроль-күзәтчелек эшчәнлеген 36 контроль (күзәтчелек) төре буенча 18 республика органы башкара, шуларның 29 төбәк һәм 7 федераль дәрәҗәдән тапшырылган.

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 248-ФЗ номерлы закон) чараларын гамәлгә ашыру кысаларында 2022 елда түбәндәге эш башкарылды:

барлык төбәк контроле (күзәтчелеге) төрләре буенча рискка юнәлдерелгән алым кертелде яисә планлы тикшерүләр федераль законнар нигезендә үткәрелми.

248-ФЗ номерлы закон таләпләре нигезендә контрольнең (күзәтчелекнең) барлык төрләре буенча планнан тыш тикшерүләргә карата бәяләү һәм куркынычлар белән идарә итү системасы кертелгән;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 23 мартындагы 256 номерлы карары белән расланган 2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре эшчәнлеге эффективлыгын һәм халыкның тормыш сыйфатын бәяләү индикаторлары нигезендә контроль даирәсендә куркынычсызлыкны арттыру һәм китерелгән зыянны киметү максатларында барлык контроль-күзәтчелек органнарына карата төбәк контроль-күзәтчелек төрен гамәлгә ашыруның контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге күрсәткечләре (төп күрсәткечләр, индикатив күрсәткечләр) билгеләнде;

барлык төбәк контроле (күзәтчелеге) төрләре буенча тикшерү кәгазьләре кулланыла, бу эшкуарларга үз-үзләрен тикшерергә, булган рискларны ачыкларга һәм тикшерүчеләр килгәнгә кадәр бозуларны бетерергә мөмкинлек бирә;

гамәлгә ашырыла торган профилактик чараларның сыйфатын арттыру максатларында контроль-күзәтчелек органнары ел саен закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программаларынраслыйлар, алар шул исәптән хокук куллану практикасы буенча гавами фикер алышу графикларын да үз эченә ала. Бу мәҗбүри таләпләрне бозуларны булдырмау һәм булган хокук куллану практикасын карап тикшерү мәсьәләләре буенча эшкуарлар белән очрашулар үткәрергә мөмкинлек бирә.

Республикада шулай ук дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда эшкуарлык эшчәнлеге субъектларына административ басымны киметүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы гамәлгә ашырыла.

Чираттагы Административ басым индексын исәпләү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы, 60 нчы урыннан 4 нче урынга күтәрелеп, Россия Федерациясе төбәкләре арасында үз позицияләрен кардиналь яхшыртты. Бу бизнес-бергәлек, федераль контроль-күзәтчелек органнары һәм Татарстан Республикасы прокуратурасы үткәргән контроль-күзәтчелек эшчәнлегенең куркынычка йөз тоткан моделенә күчү буенча уртак системалы эш нәтиҗәсе булды. Моннан тыш, Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән 2030 елга кадәр озайтылган планлы контроль чараларга мораторий уңай нәтиҗә бирде.

Мораторий кертүне исәпкә алып, 2022 елда тикшерүләрнең гомуми саны 2021 ел белән чагыштырганда 11 тапкырга диярлек кимегән (2022 елда 170 тикшерү уздырылган, шул исәптән 75 планлы һәм 95 планнан тыш, 2021 елда – 1 810 тикшерү, шул исәптән 859 планлы һәм 951 планнан тыш).

Тикшерүләргә мораторий компанияләргә тикшерүче органнар тарафыннан артык басымсыз, өзлексез, тотрыклы эшне тәэмин итәргә һәм төп басымны физик тикшерүләрдән хокук бозуларны профилактикалауга күчерергә мөмкинлек бирде. 2022 ел нәтиҗәләре буенча контроль һәм профилактик чараларның гомуми санында профилактик чаралар өлеше 98% (2021 елда - 61%) тәшкил итте.

Контроль органнары белән берлектә даими нигездә республика

предприятиеләренә күчмә профилактик визитлар уздырыла. Мондый визитлар вәзгыятьне төзәтергә һәм тикшерүләр уздырганчы җитешсезлекләрне төзәтергә ярдәм итә һәм бу административ җәзадан котылырга мөмкинлек бирә.

**ЦИФРЛЫ ТРАНСФОРМАЦИЯЛӘҮ**

Татарстан – Россиянең ИТ-индустрия үзәкләренең берсе. Республикада югары белем бирүче «Иннополис университеты» коммерциягә карамаган автоном оешмасы, Казан шәһәрендә һәм Яр Чаллы шәһәрендә ике ИТ-парк мәйданчыгы, «Идея» технопаркы, «Мәктәп 21», Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы һ.б. кебек уку йортлары һәм югары технологик җитештерүләр тупланды.

Цифрлы икътисадны алгарышлы алдан үстерү, цифрлы технологияләрне, сервисларны һәм хезмәт күрсәтүләрне нәтиҗәле үстерү өчен уңайлы шартлар тудыру максатларында 2022 ел Татарстанда цифрлаштыру елы дип игълан ителде.

Цифрлаштыру елының иң мөһим чараларыннан берсе - 30 августта Казан шәһәрендә югары технологияләр өлкәсендә технопаркның яңа мәйданчыгын ачу, ул республикада өченче технопаркка әверелде. Мәйданчык күренекле совет галиме, беренче совет ЭВМ оештыручысы, якташыбыз Б.И. Рәмиев исеме белән аталган.

Бүгенге көндә технопаркның потенциаль резидентлар белән тулылануы 77% тәшкил итә. Төп инфраструктурага балалар ИТ-паркы, «Арена» киберпаркы, цифрлы китапханә (коворкинг), Стартап Хаб, конференц-сервис зоналары һәм сөйләшүләр өчен бүлмәләр, криптополигон һәм сервис-резидентлар керә.

Ел дәвамында Цифрлаштыру елына багышланган чараларны гамәлгә ашыру кысаларында мәктәп укучылары өчен айлык Цифра дәресләре үткәрелде.

Хезмәт күрсәтүнең сыйфатын күтәрү өчен дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең 287 төре күрсәтелә торган «Минем документлар» КФҮ 61 үзәге эшли. Әлеге үзәкләргә көн саен 14 меңләп граждан мөрәҗәгать итә. 2022 елда 6,1 млн социаль әһәмиятле хезмәт күрсәтелгән.

Ел йомгаклары буенча «Сколково» Фонды рейтингы буенча Татарстан Республикасы «Цифрлы өлгергәнлек» күрсәткеченә ирешү буенча Россия Федерациясе субъектлары арасында 2 нче урынны алды, шулай ук Россия Федерациясе Президенты каршындагы Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясе тарафыннан Россия Федерациясен цифрлы үстерү, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы белән берлектә әзерләнгән Төбәкләрнең цифрлы трансформациясе җитәкчеләре рейтингы лидеры булды.

2022 елда барлык дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвешкә күчерү процессы тәмамланды. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр төбәк порталында барлыгы 319 дәүләт һәм муниципаль хезмәт чыгарылган.

2021 елда җибәрелгән түбәндәге проактив суперсервислар эшләвен дәвам итә:

«Мин төзим» – халыкка төзелеш өлкәсендә бер тәрәзә режимында хезмәт күрсәтүләрдән файдаланырга һәм барлык мәгълүматларны цифрлы профильдә сакларга мөмкинлек бирә;

«Минем субсидияләр» – аның ярдәмендә эшкуарларга һәм фермерларга берничә минут эчендә кирәкле дәүләт ярдәме чараларын рәсмиләштерергә мөмкинлек бирә. Бөтен процесс «Сакчыл җитештерү» методологиясе буенча оптимальләштерелгән;

«Мин – укучы» – укучыларга цифрлы ярдәмче булып хезмәт итә. Кушымта ярдәмендә укучылар электрон көндәлектән уңайлы форматта файдаланып кына калмыйча, ә шәхси тәкъдимнамәләр һәм искә төшерүләр дә алырга мөмкин;

«Кайгырту» - тәкъдим ителә торган субсидияләр турында проактив мәгълүмат бирә һәм аларны рәсмиләштерүдә ярдәм итә.

**«Россия Федерациясенең цифрлы икътисады» илкүләм программасы**

Татарстанда «Россия Федерациясенең цифрлы икътисады» илкүләм программасының 5 төбәк проекты гамәлгә ашырыла: «Мәгълүмати иминлек», «Цифрлы дәүләт идарәсе», «Цифрлы технологияләр», «Мәгълүмат инфраструктурасы», «Цифрлы икътисад өчен кадрлар».

«Россия Федерациясенең цифрлы икътисады» илкүләм программасының төп максаты – тормышның барлык өлкәләрендә: икътисадта, эшкуарлыкта, дәүләт идарәсендә, социаль өлкәдә һәм шәһәр хуҗалыгында цифрлы технологияләрне системалы үстерүне һәм гамәлгә кертүне оештырырга.

2022 елда «Россия Федерациясенең цифрлы икътисады» илкүләм программасының төбәк проектларын финанслауның гомуми күләме 235,3 млн сум тәшкил итте, шул исәптән 89,1 млн сум - Татарстан Республикасы бюджеты акчалары, 146,2 млн сум - федераль бюджет акчалары. Барлыгы 12 күрсәткеч беркетелгән, алар 2022 елда 100 процентка үтәлгән.

*«Мәгълүмати куркынычсызлык» төбәк проекты*

Проект кысаларында республиканың җирле үзидарә органнарында мәгълүмати куркынычсызлык өчен җаваплы 10 белгеч яңадан һөнәри әзерлек буенча өйрәтелгән (520 аудитор сәгате күләмендә). 2019 елдан бирле барлыгы 40 белгеч укыган.

*«Цифрлы дәүләт идарәсе» төбәк проекты*

Бүген Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы гражданнарның төрле тормыш хәлләрен хәл итү өчен 502 электрон дәүләт хезмәтләрен һәм сервисларны берләштерә. Алар арасында иң таләп ителгәне - табибка кабул итүгә язылу, ТКХ хезмәтләре өчен түләү, газ белән тәэмин итү һәм техник хезмәт күрсәтү хезмәтләре өчен түләү, газ исәпләү приборлары күрсәткечләрен бирү, штрафлар түләү һ.б.

*«Цифрлы технологияләр» төбәк проекты*

«Цифрлы технологияләр» төбәк проектының төп бурычы – цифрлы икътисад өлкәсендә глобаль дәрәҗәдә конкуренциягә сәләтле үтәли цифрлы технологияләр юнәлешләре буенча технологик бәйсезлекне һәм илкүләм иминлекне тәэмин итә торган эзләнү, гамәли тикшеренүләргә ярдәм итү системасын булдыру.

Республика предприятиеләре тарафыннан гамәлгә ашырыла торган проектлар федераль фондлардан ярдәм алды: «Сигма» ҖЧҖ - 20,0 млн сум, «Газ-мотор ягулыгының бердәм платформасы» АҖ - 20,0 млн сум; «Сатори» ҖЧҖ - 19,97 млн сум, «МР Чек» ҖЧҖ - 17 млн сум, «Аныклау» ҖЧҖ - 2,9 млн сум, «АТ» ҖЧҖ - 4 млн сум, «Градиент МРТ» ҖЧҖ - 4 млн сум, «Транспортны цифрлаштыру» ҖЧҖ - 20 млн сум, «Вайб Геймс» ҖЧҖ - 20 млн сум, «Электрояр СК» ҖЧҖ - 20 млн сум, «Синергия Софт» ҖЧҖ - 20 млн сум, «ИБ «Анкор» ҖЧҖ - 6,2 млн сум, «Цифровые эстеты» ҖЧҖ - 4,4 млн сум.

Моннан тыш, илнең һәм Евро-Азиат икътисадый берлеге илләренең ИТ-өлкәсендә бәйсезлекнең технологик нигезе буларак республикада Микропроцессорлар һәм микроэлектроника үзәген үстерү максатыннан «АйСиЭл-КПО ВС» АҖ төп платалар һәм компонентлар җитештерү заводы төзелешенә кереште. Проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча 300дән артык эш урыны булдырылачак, 5 елдан соң чыгару күләме ел саен 1 млн төп платага җитәчәк.

*«Мәгълүмат инфраструктурасы» төбәк проекты*

«Мәгълүмат инфраструктурасы» проектын гамәлгә ашыру кысаларында республика мәктәпләрендә цифрлы белем бирү мохите булдыру каралган.

2022 елда «Ростелеком» ГАҖ элемтә операторы тарафыннан республиканың 124 мәктәбен Wi-Fi үткәргечсез челтәрләре һәм видеокамералар белән җиһазландыру эшләре башкарылды.

*«Цифрлы икътисад өчен кадрлар» төбәк проекты*

«Цифрлы икътисад өчен кадрлар» төбәк проекты кысаларында цифрлы икътисадның төп компетенцияләренә белгечләрне түләүсез укыту каралган.

2019 елдан Россия Федерациясе Президенты каршындагы Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясенең Дәүләт идарәсе югары мәктәбе төбәк башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләр вәкилләрен цифрлы компетенцияләргә укыта. 2019 елдан республиканың 700дән артык дәүләт һәм муниципаль хезмәткәре программалар буенча белем алды.

Татарстанда яшәүче 88 меңнән артык кеше цифрлы технологияләр өлкәсендә компетенция алды.

«Демография» илкүләм проектының «Эш белән тәэмин ителешкә ярдәм» федераль проекты кысаларында өстәмә һөнәри белем бирүнең 9 программасы буенча 258 тыңлаучы укуны уңышлы тәмамладылар.

«Хезмәт җитештерүчәнлеге» илкүләм проекты кысаларында 299 тыңлаучы өстәмә һөнәри белем бирүнең 4 программасы буенча белем алды, «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында 6 яшьтән 18 яшькә кадәрге 800 бала «IT-Куб» ИТ-иҗат үзәгенә өстәмә белем бирү программалары буенча укыды.

**Цифрлы проектларга дәүләт ярдәме чаралары**

«Россия Федерациясенең цифрлы икътисады» илкүләм программасы кысаларында үзебезнең цифрлы продуктларны, сервисларны һәм платформа чишелешләрен эшләү һәм гамәлгә кертү проектларына дәүләт ярдәме чараларының комплекслы системасы эшли.

Инновацияләргә ярдәм фонды «Цифровизация-ЦТ» конкурсын үткәрде, ул Россия цифрлы чишелешләрен, шул исәптән импортны алмаштыру максатыннан, гамәлгә кертүне планлаштыручы кече предприятиеләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән. Татарстан Республикасыннан 13 мөрәҗәгать итүче конкурс сайлап алуларында җиңүче булды. Финанслауның (грантлар) гомуми суммасы 178 млн сумнан артык тәшкил иткән.

Инновацияләргә ярдәм фондыннан грантлар ИТ-компанияләргә ярдәм итүгә дә, программа продуктларын эшләү тәҗрибәсе булган компанияләрне үстерүгә дә юнәлтелгән.

«Старт» программасы буенча конкурс сайлап алуларында грант күләме 4 млн сумга кадәр тәшкил итә, «Үсеш» программасы буенча - 20 млн сумга кадәр. Грантлар НИОКР уздыруны тәэмин итүгә бирелә, аларның нәтиҗәләре булдырыла торган инновацион продукцияне коммерцияләштерүгә күчәргә мөмкинлек бирәчәк. Грант акчаларын хезмәткәрләрнең хезмәт хакына, материалларга, чималга, комплектлау җиһазларына, шулай ук башкаручыларның хезмәт күрсәтүләренә тотарга мөмкин. Проектларны гамәлгә ашыру срогы - 12 ай.

«Старт» программасы буенча конкурс нигезендә сайлап алуда «Кече предприятие» статусы һәм ике елдан артмаган эшчәнлек срогы булган физик һәм юридик затлар, «Үсеш» программасы буенча конкурс нигезендә сайлап алуда - «Кече предприятие» статусы белән юридик затлар катнаша ала. «Старт-1» программасы буенча проектны гамәлгә ашыру тәмамлангач, киләсе баскычка күчәргә мөмкин - «Старт-2» программасы, ул 8 млн сумга кадәр грант бирүне, аннары «Бизнес-старт» программасы - 12 млн сумга кадәр грантны күздә тота.

Россия мәгълүмат технологияләрен үстерү фонды программасы үз цифрлы продуктларын эшләүгә һәм аларны базарга чыгаруга (проект бәясенең 50 процентына кадәр финанслау белән) 6 млрд сумга кадәр грант күздә тота.

2022 елда Россия мәгълүмат технологияләрен үстерү фонды кече һәм урта бизнесны цифрлаштыруны тизләтү өчен программаны яңадан эшләтеп җибәрде. Компанияләр - КУЭ вәкилләре 50 процент ташлама белән программа тәэмин ителешен сатып алырга мөмкин, ә дәүләт аны җитештерүчеләргә лицензия бәясенең яртысын компенсацияли. Әлеге шартларда 58 хокук иясеннән 150дән артык программа продуктлары сатып алырга була. Татарстан Республикасы 50 процент ташлама белән программа белән тәэмин итүне сатып алган КУЭ субъектлары саны буенча төбәкләр арасында 5 урынны алып тора - 6,5 мең компания һәм сатып алынган Россия софты саны буенча 4 урында - 19,6 мең лицензия.

«Сколково» фонды программалары мәгълүмат технологияләре өлкәсендә Россия карарларын гамәлгә кертү буенча пилот проектлары бәясенең 50 процентына кадәр финанслый, шулай ук ясалма интеллект өлкәсендәге проектларга ярдәм итүгә 20 дән 300 млн сумга кадәр күләмдә грантлар бирә.

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы Россия уйлап табучыларының операцион системаларын сынады. Импортны алыштыру программасы кысаларында 10 меңнән артык медицина хезмәткәренең операцион системалары алмаштырылды, гомуми белем бирү оешмалары педагогларына Alt Linux операцион системасы белән «АйСиЭл-КПО ВС» АҖ компаниясенең яңа ноутбуклары бирелде. Укытучылар өчен ноутбукларга «Минем Офис» һәм «Р7-офис» Россия офис программалары урнаштырылган. Офис пакетлар Microsoft Office аналогы булып тора һәм текст, таблица мөхәррирләрен, презентация мөхәррирләрен үз эченә ала. Алынган ноутбукларга Россия Федерациясенең техник экспорт контроле федераль хезмәте тарафыннан сертификацияләнгән «Альт Линукс» Россия операция системасы урнаштырылган.

**Объектларны «Интернет» челтәренә тоташтыру**

Ел нәтиҗәләре буенча Татарстанда 1 173 мең чыбыклы Интернетның

абоненты бар (2021 ел дәрәҗәсенә карата 105,2 %).

2022 елда 127 мең йорт хуҗалыгы оптик элемтә линияләре буенча «Интернет» челтәренә югары тизлектә керә ала. Абонентлар өчен элемтә операторлары тарафыннан «Интернет» челтәренә керүнең иң югары тизлеге тәэмин ителә - секундына 1 Гигабитка кадәр.

Республикада 7 560 мең гамәлдәге сим-карта исәпләнә. Мобиль Интернет абонентлары саны 4 600 меңгә кадәр артты.

Хәзерге вакытта Татарстанда мобиль элемтәнең 30 меңнән артык база станциясе эшли. 2022 елда республикада элемтә сыйфатын алга таба да яхшырту өчен 800дән артык база станциясе урнаштырылды яисә яңартылды.

**Цифрлы тигезсезлекне бетерү буенча федераль программаны гамәлгә ашыру (УЦН 2.0)**

2022 елда 100 дән 500 кешегә кадәр халкы булган авыл торак пунктларын мобиль элемтә һәм Интернет белән тәэмин итү буенча федераль программа гамәлгә ашырыла башлады. 38 торак пункты 4G мобиль элемтәсеннән беренче тапкыр файдалану мөмкинлеге алды. 2023 елда эш дәвам итәчәк, «Ростелеком» ГАЖ »Т2 Мобайл» ҖЧҖ белән берлектә 100дән 500гә кадәр яшәүчесе булган 78 торак пунктны мобиль элемтә белән тәэмин итәчәк.

**Мәгълүмат иминлеге**

Татарстанның мәгълүмат инфраструктурасының тотрыклылыгын тәэмин итү һәм яклангалылыгын арттыру кысаларында «Татарстан Республикасы Мәгълүмат технологияләре үзәге» ДУП базасында Киберянауларны булдырмау үзәге (алга таба - ЦПК) төзелде, бу Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системаларына мәгълүматны яклауның яңа дәрәҗәсенә чыгарга мөмкинлек бирде.

2022 елда Киберянауларны булдырмау үзәге түбәндәгеләрне эшләде:

Татарстан Республикасының 4 меңнән артык мәгълүмат ресурсына инвентаризация ясалды;

Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының 2,4 меңнән артык серверы йомшаклыклар булу-булмауга тикшерелде һәм ачыкланган йомшаклыкларны бетерү буенча 100дән артык тәкъдим бирелде;

мәгълүмат куркынычсызлыгының 380 мең инциденты ачыкланган һәм эшкәртелгән;

15 меңнән артык һөҗүм итү төене ябылган;

Татарстан Республикасы дәүләт ресурсларына юнәлтелгән 12 млрд легаль булмаган запрос фильтрланган;

Татарстан Республикасының рәсми сайтларына юнәлдерелгән 3,5 Гбит/с артык куәтле DDOS-атакалар туктатылды.

Дәүләт хакимияте органнарын һәм җирле үзидарә органнарын мәгълүмат иминлеге буенча квалификацияле белгечләр белән тәэмин итү максатларында ел саен «Мәгълүмат иминлеге» программасы буенча яңадан һөнәри әзерлек курслары оештырыла.

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе мәгълүмати иминлеген тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында» 2022 елның 1 маендагы

250 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары Д.Н.Чернышенконың 2022 елның 6 мартындагы ДЧ-П10-3408кс номерлы йөкләмәләре исемлегенең 1.2 пункты нигезендә Татарстан Республикасында киберкуркынычсызлыкны тәэмин итү буенча штаб төзелде, республика дәүләт хакимияте органнарына мәгълүмат куркынычсызлыгын арттыру чаралары турында мәгълүмат җиткерү оештырылды. Мәгълүмат куркынычсызлыгы өлкәсендәге компьютер инцидентлары турында хисап туплана.

2022 елның 28 июнендә Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы һәм Компьютер инцидентлары буенча милли координация үзәге арасында Россия Федерациясенең мәгълүмат ресурсларына компьютер һөҗүмнәре нәтиҗәләрен ачыклау, кисәтү һәм бетерү дәүләт системасы кысаларында хезмәттәшлек регламенты расланды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 сентябрендәге 1043 номерлы карары белән Татарстан Республикасының мәгълүмат инфраструктурасына максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалуга каршы тору тәртибе расланды.

Республика дәүләт хакимияте органнарында максатчан компьютер һөҗүмнәре уздыруның тиешле дәрәҗәләрен билгеләгәндә чаралар планнары эшләнгән һәм Идел буе федераль округы буенча Техник һәм эксперт контроле буенча федераль хезмәт идарәсе белән килештерелгән.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Иминлек Советының Мәгълүмат куркынычсызлыгы буенча ведомствоара комиссиясе базасында киберһөҗүмнәргә каршы көрәш буенча координация үзәге булдырылды.

## Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында сораулар исемлеге буенча мәгълүмат

### Икътисад, бюджет

**1. Чит ил товарларын алмаштыру шартларында Татарстан Республикасы предприятиеләрендә системалы эш оештыру турында.**

Технологик бәйсезлекне арттыру максатларында Татарстан Республикасы предприятиеләре чит ил товарларын алмаштыру проектларын гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан булган кыенлыкларны ачыклау, продукцияне үз илебездә җитештерелә торган тиңдәш төрләре, дустанә мөнәсәбәттәге илләр территориясендә җитештерелә торган товарлар белән алмаштыру мөмкинлекләрен эзләү, шулай ук яңа җитештерүне оештыру һәм альтернатив логистика схемаларын эшләү юнәлешендә системалы эш алып барыла.

Тармак министрлыклары тәкъдимнәренә таянып һәм Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының Аеруча кирәкле комплектлау эшләнмәләрен җитештерүне үстерү мәсьәләләре комиссиясенең 2022 елның 21 апрелендәге утырышының 68-ОВ/12 номерлы беркетмәсе белән расланган сәнәгать тармаклары өчен аеруча кирәкле комплектлау эшләнмәләре исемлеген исәпкә алып, дошман дәүләтләр һәм халыкара оешмалар тарафыннан чикләү чаралары кертелү шартларында чит ил товарларын алмаштыруны тәэмин итү өчен кирәкле продукция исемлеге (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 1765-р номерлы карары белән расланды) төзелде.

Фән һәм мәгариф учреждениеләре белән эш дәвам иттерелә, инжиниринг компанияләре республикада һәм башка төбәкләрдәге альтернатив товар сатучыларны ачыклый, Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән хезмәттәшлек алып барыла.

«Татнефтехиминвест-холдинг» АҖ белән берлектә нефть химиясен үстерүнең өстенлекле юнәлешләре билгеләнде: этилен, изоцианатлар, СКЭПТ маркалы каучук (этилен, пропилен һәм мономердан җитештерелә торган синтетик эластомер), циклопентан, синтетик сумалалар, малеин ангидридын һәм Россия Федерациясендә чыгарылмый торган башка продуктларны җитештерүне оештыру.

Илебез җитештерү компанияләренең эре заказчылар белән хезмәттәшлеген җайга салу максатларында даими нигездә товар сатучылар көннәре уздырыла, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, «Сибур Холдинг» ГАҖ, «КАМАЗ» ГАҖ, «Ростсельмаш» ДК һәм башка зур компанияләр вәкилләре белән түгәрәк өстәлләр оештырыла.

В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ «ТАНЕКО» акционер җәмгыятендә яңа җиһазларны файдалануга кертүне дәвам иттерде. Ароматика җитештерү комплексы эшли башлады, бу исә нефть химиясе тармагында зур проектларга этәргеч бирәчәк.

«Сибур Холдинг» ГАҖ инвестиция проектларын гамәлгә ашыруны дәвам иттерә.

«Казан оргсинтез» ГАҖ инвестиция программасы кысаларында җитештерүне киңәйтү нияте бар. «Сибур Холдинг» ГАҖ җитештерү циклына хәлиткеч йогынты ясый торган, аларны эшләп чыгару илдә тупланачак компонентлар исемлеген билгеләде. Бу – 18 азтоннажлы химия компоненты һәм 11 катализатор төре (полимерлашу һәм пиролиз).

«Түбән Кама нефтехим» гавами акционер җәмгыятендә полиалкиленгликол майларның (температураның киң диапазонына чыдам) сынау партиясе җитештерелде, алга таба продукция «ТАИФ СМ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең майлар җитештерүе базасында камилләштереп эшләп төгәлләнде.

В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ белән берлектә өченчел додецилмеркаптан (каучук җитештерүдә кулланыла) җитештерүне башлап җибәрү мөмкинлекләре өйрәнелә. Шулай ук катализаторлар җитештерүен туплау мөмкинлекләре карала. Катализаторлар җитештерү, урта һәм азтоннажлы химиягә кагылышлы проектлар гамәлгә ашырыла.

«Татшина» ҖЧҖ җитештерүне яңартып кору һәм продукцияне диверцификацияләү эшен дәвам иттерә. Квадроцикллар шиннары эшләп чыгару башланды.

«Аммоний-2» проектын гамәлгә ашыру дәвам иттерелә.

2022 елда җитештерелә торган продукция төрләрен арттыру һәм чит ил товарларына алмашка даруларны сатуга чыгару максатында «Татхимфармпрепарат» АҖ төймәле өч яңа дару һәм ике төрле күз даруы эшләнә башлады, шулай ук ике актив фармацевтика субстанциясенә теркәү таныклыгы алынды. Предприятие дару төймәләрен махсус тышча белән каплау җайланмасын эшләтеп җибәрде.

Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы башлангычы белән 2022 елның август аенда автомобильләр җитештерүдә технологияләр куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен аеруча кирәкле компонентлар һәм материаллар өлкәсендә 25 эш төркеме булдырылды.

«Резин техник эшләнмәләр» төркемен «Татнефтехиминвест-холдинг» АҖ генераль директоры Р.С. Яруллин җитәкли. Төркем тарафыннан үтә зур ихтыяҗ булган юнәлешләр эшләнде, шулар кысаларында резин техник эшләнмәләрнең аеруча кирәкле 4 төркеме билгеләнде (сальниклар һәм манжетлар, тыгызлагычлар, хәрәкәт каешлары, виброакустик таянычлар). Җитештерүчеләр белән киңәшмәләр уздырылды, кыенлыклар исемлеге билгеләнде, автомобильләр җитештерүчеләрдән ихтыяҗ булган эшләнмәләрнең тәгаен төрләре һәм күләмнәре турында мәгълүмат алынды. Чимал белән тәэмин итү өлешендә автомобиль комплектлары җитештерү өчен кирәкле термоэластопластлар исемлеге булдырылды.

Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан каучукларның дефицит төрләрен җитештерүне башлап җибәрү буенча мөмкин булган инвесторлар белән сөйләшүләр алып барыла.

Машиналар төзү комплексы предприятиеләренең төп эш юнәлеше – чикләүләр нәтиҗәсендә юкка чыккан компонентларны җитештерүне туплау яки башка партнерлар табу.

«КАМАЗ» ГАҖ чит ил товарларын алмаштыруга юнәлтелгән эшен дәвам иттерә. 2023 елның февралендә йөк машиналарының К5 моделе төрләрен җитештерү яңадан башланып китте, модель 70 – 80 процентка тупланды.

«РИАТ» ААҖ манипуляцияләр ясаучы краннарны үзе җитештерергә кереште, аларның төп элементлары Россия корычыннан эшләнә. Комплектлау эшләнмәләренең күпчелеге үз җитештерү предприятиеләрендә тупланды.

«Аурус» автомобильләре җитештерүне туплауда югары дәрәҗәгә ирешелде. Комплектлау эшләнмәләре сатучыларның 70 проценты (автомобильләрнең төп узеллары, көчәнеш җайланмалары, трансмиссия, электроника, интерьер, бизәлештәге чишелешләр) – Россия компанияләре.

«ЕлАЗ» ГҖ» АҖ юл төзелешендә кулланыла торган техника төрләрен чыгаруны киңәйтә, яңа грейдерлар һәм бульдозерлар чыгару үзләштерелде.

Haier компаниясе көнкүреш техникасын һәм комплектлау эшләнмәләрен чыгаруны җайга салды.

«АйСиЭл» компанияләр төркеме Россиядә елына 1 млн төп плата чыгара торган радиоэлектроника продукциясен җитештерү буенча иң эре заводларның берсен төзү эшенә кереште.

Яңа җитештерү объектлары төзү буенча инвестиция проектлары федераль күләмдә ярдәм күрсәтү институтларын җәлеп итү аша да гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасы территориясендә җитештерү предприятиеләрен төзү проектларын гамәлгә ашыру өчен Үсеш фонды биргән акча күләме 24 млрд сум тәшкил итте.

Республикада энергетика объектларының өзлексез эшләве булдырылды һәм кулланучылар тотрыклы төстә электр энергиясе белән тәэмин ителә. Генерацияләү объектларының, электр челтәре хуҗалыкларының тотрыклы эшләве мәсьәләләре Татарстан Республикасы Премьер-министры – Республикада электр тәэминатының тотрыклы эшләвен тәэмин итү штабы җитәкчесе А.С. Песошин тарафыннан расланган Төп чаралар планына һәм Электр тәэминатының куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе (федераль штаб) йөкләмәләренә таянып штаб утырышлары кысаларында даими рәвештә карала.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы чит ил товарларын алмаштыру шартларында предприятиеләр белән системалы эш кысаларында параллель импорт кысаларында илгә чит илләрдә җитештерелгән һәм ихтыяҗ зур булган оригиналь товарлар алып кайту буенча эш алып бара (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 29 мартындагы 506 номерлы карары нигезендә). Өстәмә рәвештә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең эчке базарда товар сатучылар белән хезмәттәшлеген булдыру һәм җайга салу һәм аларга үзебезнең товар җитештерүчеләр белән эшләүгә юнәлеш бирү башкарыла.

Илебез техникасы һәм җиһазлары белән эшләүгә йөз тотуга авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә илдә эшләнгән техниканы сатып алу өчен субсидияләр бирү юлы белән дәүләт ярдәме күрсәтү аша этәргеч бирелә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 31 маендагы 397 номерлы карары нигезендә).

Республиканың машиналар төзү комплексы предприятиеләре авыл хуҗалыгы тармагы өчен чит илләр техникасына 2 меңнән артык атамадагы запас

частьләр җитештерү һәм төзәтүне үзләштерде: «Агровет» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте чит илләрдә чыгарылган савым җайланмалары өчен «Доувак» савым аппараты чыгара, «МТК-АК Барс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте «Ропа» чөгендер алу комбайннары өчен детальләр җитештерә һәм төзәтә, шулай ук чит ил комбайннары өчен шиннарны эшкә яраклы хәлгә китерә, «Агропласт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «ПК Пружина проекты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте чит ил авыл хуҗалыгы техникасы өчен детальләр эшләп чыгара.

**2. Республикада интернет-сәүдә үсеше тизләнеше һәм аның киләчәге турында.**

Республикада интернет-сәүдәне үстерү максатларында 2022 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 17 ноябрендәге 2363-р номерлы карары белән расланган программа (чаралар планы) (алга таба – программа) гамәлгә ашырыла:

Татарстан Республикасында интернет-сәүдә инфраструктурасын үстерү (продукция кабул итү пунктларының урнашу киңлеген җәелдерү, логистика компанияләре белән хезмәттәшлекне оештыру, логистика үзәкләрен төзегәндә ташламалар бирү);

эшкуарларны интернет-мәйданчыкларда теркәү, аларга консультацияләр бирү һәм мәгълүмати ярдәм күрсәтү. Финанс һәм финанс булмаган ярдәм күрсәтү чаралары комплексына аеруча зур игътибар бирелде. Эшкуарлар өчен электрон сәүдә мәйданчыкларында товар урнаштыру һәм тәкъдим итү буенча, шулай ук махсус кредит һәм микрокредит продуктлар каралган;

республика эшкуарларының хәзер халыкара электрон мәйданчыклар һәм транспорт-логистика провайдерлары белән хезмәттәшлекне киңәйтүгә ихтыяҗы булганлыктан, тышкы икътисадый эшчәнлекне үстерү;

Экспортка ярдәм күрсәтү үзәге эшкуарлар продуктларын Alibaba, Epinduo, УрманРесурсы.рф, Topfranchise, Trendyol и Turkishexporter кебек халыкара маркетплейсларда урнаштыру хезмәтен күрсәтә.

Маркетплейслар белән нәтиҗәле эшләү өчен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы карамагындагы «Татарстан Республикасы эшкуарларга ярдәм күрсәтү фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясе кече һәм урта эшкуарлык вәкилләрен «аккуант-менеджер» белгечлеге буенча квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерлек бирү буенча өйрәтү программасын уздыра.

2022 елда республика сәүдә вәкилләренең саны 2 тапкырга артты һәм 45 423 тәшкил итте. Ваклап сатуның гомуми әйләнеше күләмендә интернет-сәүдәнең өлеше 5,6 процент тәшкил итте (2021 елда – 4,2%).

Маркетплейсларны бик нәтиҗәле юл дип бәяләүче сатучылар саны бик тиз арта бара: 64% сатучы 2022 елда маркетплейсларда сәүдәләре күләме үсүен хәбәр итә. 2022 елның март аенда төзелгән «Җиңел маркетплейсы» электрон сәүдә үзәге» акционер коммерциячел булмаган оешмасы тармакның үсешенә зур өлеш кертте. Интернет-сәүдәнең тизләнешле үсеше республикада шулай ук Wildberries, OZON,

KazanExpress компанияләренең инфраструктур проектлары гамәлгә ашырылу белән раслана.

Тупланган тәҗрибәне исәпкә алып, әлеге юнәлешне үстерү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 27 гыйнварындагы 138-р карары белән 2023 – 2025 елларга шундый ук программа расланды.

**3. Татарстан Республикасы бюджетының керем базасын саклау буенча республикада күрелә торган чаралар турында**

2022 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетына 429,4 млрд сумга салым һәм салым булмаган керемнәр тупланды, бу исә 2021 елгы керемнәрдән 93,4 млрд сумга (яисә 27,8 %) артыграк, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетына 366,6 млрд сум (2021 елда – 280,2 млрд сум) алынды.

Керемнәрне арттыру максатларында Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетына салым һәм салым булмаган керемнәрнең арттыруга юнәлтелгән, шул исәптән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 30 апрелендәге 687-р номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының үз керемнәрен арттыруны тәэмин итү ведомствоара комиссиясе эшчәнлеге кысаларында чаралар уздырылды, шул исәптән:

керемгә салым түләүгә ай саен мониторинг уздырылды, нәтиҗәдә 2021 елның шул ук чоры белән чагыштырганда түләүләре кимегән оешмалар ачыкланды. Мондый оешмаларның исемлеге квартал саен тармак министрлыгына җиткерелеп торды, алар баланс комиссияләре эшчәнлеге кысаларында салымнар түләүнең кимүе сәбәпләрен тикшерделәр һәм барлык дәрәҗәдәге бюджетларга түләүләр буенча бурычы булган оешмалар белән бәйләнештә тордылар. Йомгаклар буенча бурычларны бетерү һәм җитештерү рентабельлеген арттыру буенча тәкъдимнәр эшләнде.

физик затларның керемнәренә салым салу өлешендә яшерен хезмәт хакын легальләштерү, конвертта акча түләүне һәм салым түләүдән читләшүнең башка схемаларын ачыклау эшчәнлеге алып барылды, учреждение хезмәткәрләренә хезмәткә түләүнең иң түбән күләменнән азрак булмаган күләмдә хезмәт хакы түләү контрольдә тотылды, шулай ук әлеге салымны түләүне киметкән салым түләүчеләргә мониторинг уздырылды;

акцизлар өлешендә продукция җитештерү һәм сату күләмнәренә, акцизга караган продукцияне төп җитештерүчеләрнең план биремнәренә ирешүенә мониторинг уздырылды;

салым түләүче физик затларның милеккә салым түләүләре үз вакытында һәм тулысынча башкарылуын тәэмин итү максатларында зур предприятиеләр, дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, муниципалитетлар, кредит оешмалары һәм почта бүлекчәләре белән хезмәттәшлектә мәгълүмати кампания киң җәелдерелде;

салым булмаган керемнәр өлешендә Татарстан Республикасы бюджетына һәм муниципаль районнар һәм шәһәр округларының берләштерелгән бюджетларына керә торган керемнәрне анализлау һәм фаразлана торган керемнәрне бәяләү башкарылды, керем базасын арттыру һәм түләүләр буенча

бурычларны киметү максатларында салым булмаган керемнәр администраторлары белән уртак эш алып барылды.

Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына салымнар буенча бурычны киметү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 15 июлендәге 1493-р номерлы карары белән төзелгән Ведомствоара комиссия (штаб) эше кысаларында муниципаль берәмлекләрнең ведомствоара комиссияләре эшенең йомгаклары анализланды (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе вәкилләре катнашында уздырылган киңәшмәләрдә), хакимиятнең муниципаль һәм башкарма органнары, зур предприятиеләр хезмәткәрләренең бурычларын түләүләренә мониторинг уздырылды.

Бюджетның керем өлешенә түләүләрне арттыру максатларында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан республиканың зур күләмдә салым түләүчеләр белән түбәндәге эш уздырылды:

түләнә торган түләүләрне анализлау һәм фаразлана торган түләүләрне бәяләү;

хисап елында эшчәнлекнең йомгаклары буенча ведомствоара киңәшмәләр уздыру, компанияләр эшчәнлегенә бәя бирү, түләүләр кимүе сәбәпләрен ачыклау, шулай ук бюджетка түләүләрне арттыру өчен чаралар һәм тәкъдимнәр эшләү;

эре предприятиеләрнең бергәләп идарә итү органнары утырышларына, кече нефть компанияләре вәкилләре катнашында Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов рәислек итә торган киңәшмәләргә материаллар әзерләү.

**4. Татарстан Республикасы кече шәһәрләренең шәһәр эчендәге юлларын капиталь төзекләндерү чараларын финанслау турында.**

Татарстан Республикасы Юл фондының 2022 елга чыгымнары 78 723,7 млн сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан – 59 148,3 млн сум (шуларның федераль бюджеттан инфраструктур проектларны башкаруга бюджет кредиты – 14 283,0 млн сум), федераль бюджет акчалары хисабыннан – 19 521,8 млн сум, «Моношәһәрләрне үстерү фонды) коммерциячел булмаган оешмасыннан алынган акча хисабыннан – 53,6 млн сум тәшкил итте.

Муниципаль юл фондларын төзүгә, гомуми кулланылыштагы җирле автомобиль юлларын төзекләндерүгә, чокырларны ямауга, җирле автомобиль юлларына вак таш түшәүгә чыгымнар 2022 елда 1 301,9 млн сум тәшкил итте.

2023 елга Татарстан Республикасы бюджетында чаралар күрүгә Татарстан Республикасы Юл фонды акчалары хисабыннан 47 260,8 млн сумлык ассигнованиеләр, шул исәптән акчалары федераль бюджет акчалары хисабыннан – 16 102,5 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетынан – 31 158,3 млн сум каралган.

Объектларның тәгаен исемлеге күрсәтелгән юл эшләре программасы Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан аларны төзүнең, торгызуның һәм капиталь төзекләндерүнең җирле үзидарә органнары белән берлектә төзелә. Муниципаль юл фондларының 2023 елга ассигнованиеләр күләме 1 338,1 млн сум тәшкил итә.

**5. Файдаланылу күрсәткечләре түбән булган сәнәгать паркларын Республиканың муниципаль районнарында сәнәгать парклары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру программасы кысаларында 2023 елда үстерү мөмкинлекләре турында.**

2022 ел йомгаклары буенча республиканың сәнәгать паркларында 1 562 резидент эшли, 55,7 мең эш урыны булдырылды (2021 ел белән чагыштырганда хезмәткәрләр саны уртача 32,5 процентка артты), керем 375,4 млрд сум тәшкил итте. Резидентлар җитештерә торган продукция республика икътисадына сизелерлек өлеш кертә, ул сәнәгать җитештерүе гомуми күләменең 10 процентын тәшкил итә.

Сәнәгать парклары нәтиҗәлелеген, эш урыннары санын арттыру максатларында Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов тарафыннан территорияләрне комплекслы үстерү өчен авыл җирлегендәге сәнәгать парклары нәтиҗәлелеген арттыру концепциясе килештерелде. Моның өчен резидентларга һәм идарә компанияләренә түбәндәге мөмкинлекләр бирә торган берничә закон инициативасы кабул ителде:

салым салуның гадиләштерелгән системасы буенча салым ставкаларын киметү (1 процент – керемнәр салым салу объекты булып торса, 5 процентка кадәр – чыгымнар күләменә киметелгән керемнәр салым салу объекты булып торса);

транспортка салым түләүгә ташламалар (0 %) һәм оешмалар милкенә салым (0 %).

Файдаланылу күрсәткечләре түбән булган аккредитацияләнгән сәнәгать парклары территорияләрендә эшчәнлек алып бара торган һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән килешү төзегән резидентлар һәм идарә компанияләре салымнарга ташламалардан 10 елга кадәр файдалана алчак.

Сәнәгать паркларының резидентлары һәм идарә компанияләре өчен дәүләт ярдәменең төрле чаралары каралган: ташламалы микрозаймнар, электр энергиясе өчен түләүләр чыгымнарының бер өлешен субсидияләү, Гарантия фондының поручительлеге, «үстерү» программасы, җиһазлар лизингы, кредитлауга ташламалы программа, инженерлык инфраструктурасын төзүне финанслау.

«Түбән Кама», «Минзәлә Сәнәгать зонасы», «Алексеевск», «Арча» сәнәгать паркларының юл һәм инженерлык инфраструктурасын төзүгә 2022 елда 135,37 млн сум бүлеп бирелде, бу исә хәзерге вакытта эшли торган һәм эшли башлавы мөмкин булган 44 резидентны җитештерү эшчәнлеге өчен уңай шартлар тәэмин итәчәк. 2023 елда әлеге максатларда 500 млн сум тоту каралган.

Сәнәгать паркларына дәүләт ярдәме күрсәтү 2023 елда да дәвам иттереләчәк.

Кабул ителгән законнар, авыл җирендәге сәнәгать паркларына республика күләмендә дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары аларның конкурентлык өстенлекләрен зур шәһәрләрдәге сәнәгать парклары белән бертигез итәргә һәм файдалану мөмкинлекләрен иң түбән дип саналган 70 процент күрсәткечкә җиткерергә мөмкинлек бирәчәк.

**6. Республикада капитал салу гамәлләренә ярдәм итү һәм саклану чараларын булдыру өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан**

**кабул ителгән чаралар турында. Анда нинди инвестиция проектлары катнашырга тиеш?**

Татарстанда инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен уңай даирә булдыру, шул исәптән проектларны гамәлгә ашыру срогына гарантияләнгән һәм фаразланган шартлар тәэмин итү һәм җайга салу даирәсен тотрыкландыру хисабына, инвестицияләр җәлеп итү өчен зарури шартларның берсе булып тора.

Республика «Россия Федерациясендә капитал салу гамәлләренә ярдәм итү һәм саклану чараларын булдыру турында» 2020 елның 1 апрелендәге 69-ФЗ номерлы федераль законны гамәлгә ашыруда актив катнаша.

Татарстан Республикасы дәрәҗәсендә капитал салу гамәлләренә ярдәм итү һәм саклану чараларын булдыру турында килешүләр механизмын тәэмин итү өчен кирәкле барлык норматив хокукый актлар (алга таба –КСЯСК) расланган. «Капитал салу» дәүләт мәгълүмат системасының беренче чираты сынау өчен эшләтеп җибәрелде (алга таба – «Капитал салу» ДМС), ул кирәкле документлар һәм материаллар теркәлгән КСЯСК төзелү турындагы гаризалар бирүне, шулай ук КСЯСКка электрон документ форматында кул куюны тәэмин итәчәк.

Татарстан Республикасы ил төбәкләре арасында беренчеләрдән буларак капитал салу гамәлләренә ярдәм итү һәм саклану чараларын булдыру буенча түбәндәге проектларга кагылышлы өч килешү төзеде:

«Яшел Үзән» сәнәгать паркы территориясендә омниканал сәүдәне тәэмин итү үзәген төзү («ВБ Восток» ҖЧҖ, Wildberries ярдәмче компаниясе). Инвестицияләр күләме – 5,15 млрд сум. Проект гамәлгә ашырылды;

Каты коммуналь калдыкларны энергетик утильләштерү буенча 550 000 тонна көчәнешле завод төзү («АГК-2» ҖЧҖ). Инвестицияләр күләме – 31,7 млрд сум (төп партнер – Hitachi Zosen Inova Швейцария-Япония компаниясенең катнашудан – җиһазлар китертүдән һәм алдан төзелгән килешү буенча эшләр башкарудан берьяклы баш тартуы сәбәпле проект яңадан каралды. Әлеге хәл проектны, җитештерү җиһазларын 90 проценттан артык дәрәҗәдә туплауны һәм чит ил компанияләреннән төп технологияләрне сатып алудан тулысынча баш тартуны күздә тотып, үзгәртүгә китерде. Проект алга таба «РТ-Инвест» АҖ һәм «Росатом» ДК белән уртак предприятие эшчәнлеге кысаларында гамәлгә ашырылачак. Җиһазларны эшләүне һәм аларны монтажлау хезмәтен «Росатом» ДК «Махсус энергия» ҖЧҖ башкарачак);

Зәй ГРЭСда («Татэнерго» АҖ) 850 МВт көчәнешле пар-газ җайланмасын төзү. Инвестицияләр күләме – 40,83 млрд сум (General Electric компаниясенең инде түләнгән һәм төяп озатуга әзер җиһазларны Россиягә китертүдән баш тартуы нәтиҗәсендә проект үзгәртелә).

Хәзерге вакытта ВЭБ.РФ дәүләт корпорациясе белән берлектә яңа проектлар эшләнә. Килешүләр төзүдә кызыксынган предприятиеләр «Капитал салу» ДМСта теркәләләр. Механизмны популярлаштыру максатларында даими төстә бизнес вәкилләре (инвесторлар) катнаша торган чаралар уздырыла.

**7. Татарстан Республикасында энергетиканы яңартып коруга юнәлтелгән һәм чит илләр керткән тыюлар һәм технологик чикләүләргә бәйле рәвештә туктатылып торган проектларны гамәлгә ашыру мөмкинлекләре.**

2022 елда Зәй ГРЭСда («Татэнерго» АҖ) 850 МВт көчәнешле пар-газ җайланмасын төзү дәвам иттерелде. Әмма чит илләр тарафыннан тыюлар кертелү (Россия Федерациясенә җиһазлар җибәрү белән бәйле кыенлыклар) сәбәпле проектны гамәлгә ашыру туктатылды, ЭНКА компаниясе белән проектны төзү турындагы килешү өзелде (ENKA Иншаат ве Санайи А.Ш., Төркия). Хәзерге вакытта бу мәсьәләне хәл итү вариантлары карала. Проект Татарстан Республикасы Хөкүмәте күзәтчелегендә тора. Станция хәзерге вакытта эшләвен дәвам итә, кулланучылар электр энергиясе белән тәэмин ителә.

**8. Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елының йомгаклары турында.**

Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елында 100дән артык чара уздырылды, аларда төрле яшьтәге 500 меңнән артык кеше катнашты.

Тармакның төп юнәлешләренә кагылышлы 3,5 млрд сумлык инфраструктура проектлары гамәлгә ашырылды. Халык хезмәтләрдән файдалана алсын өчен уңайлы шартлар тудыру буенча мәгълүмати системаны эшләү дәвам иттерелә.

2022 ел йомгакларына нигезләнеп Татарстан Россия Федерациясе субъектлары арасында цифрлы технологияләргә күчү буенча 1 нче урынга чыкты. Татарстан төбәкләр арасында беренче булып барлык аеруча кирәкле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне тулысынча электрон рәвешкә күчерүне төгәлләде (319 хезмәт күрсәтү төре). Бу эштән 16 млрд сумлык икътисадый файда алынды.

Татарстан Республикасында «Цифрлы технологияләргә күчү өчен өлгергәнлек» күрсәткече 95 % тәшкил итте (Россия Федерациясе субъектлары арасында 2 нче урын), шул исәптән тармаклар буенча:

шәһәр хуҗалыгы һәм төзелеш – 100 %;
җәмәгать транспорты – 95 %;
мәгариф (гомуми) – 96 %;
сәламәтлек саклау – 93 %;
дәүләт идарәсе – 90 %.

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә HIMSS стандартларын кертү проекты гамәлгә ашырылды. HIMSS стандарты – сәламәтлек саклау өлкәсен мәгълүматлаштыру һәм нәтиҗәле идарә итү стандартлары. Медицина хезмәтләре күрсәтү процессларын уңайлырак итү өчен чаралар уздырылды, хастаханәнең ИТ- һәм инженерлык инфраструктурасы яңартылды, пациентларга медицина ярдәмен күрсәтүнең куркынычсызлыгын һәм сыйфатын, шулай ук медицина персоналының цифрлы сервислардан файдалануын уңайлырак итүне тәэмин итә торган цифрлы нигезгә корылган яңа чишелешләр табылды.

Күпфатирлы йортларда фатир милекчеләренең читтән торып тавыш бирүе рәвешендә гомуми җыелышларын уздыру өчен Татарстан Республикасының «Локоло» мәгълүмати системсы булдырылды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 4 августындагы 758 номерлы карары).

Система физик һәм юридик затларның, идарәче оешмаларның, дәүләт хакимияте башкарма органнарының, җирле үзидарә органнарының күпфатирлы йортлар белән нәтиҗәле идарә итүдә хезмәттәшлеге, шул исәптән зарури мәгълүмат белән алмашуда цифрлы нигезгә корылган нәтиҗәле корал булдыру процессларын автоматлаштыруга юнәлтелгән.

Цифрлы нигезгә корылган инфраструктураны тәэмин итү чараларына куелган бердәй функциональ-техник таләпләрне үтәүгә кагылышлы рәвештә 190 җәмәгать судьясы суд участокларында берләштерелгән исәпләү челтәре яңартып корылды. Федераль таләпләргә туры китереп белешмәләрне урнаштыру юнәлешендә «Гадел хөкем» дәүләт автоматлаштырылган системасына тоташтыру эше башкарылды.

Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә RPA роботы (Robotic process automation) файдаланыла башлады, шуның нәтиҗәсендә белешмәләрне төбәк платформасыннан Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасына күчерү процессы автоматлаштырылды һәм белешмәләрнең ике системада да кертелүе сәбәпле кабатлануы туктатылды, платформаларда белешмәләрнең бәйләнгәнлеге һәм тикшерүләр тарихының бердәм базасы булдырылды.

«АК БАРС» БАНК ГАҖ укытучыларга 24 мең ноутбук алып бирде. Бу исә республика һәм федераль электрон мәгариф системалары белән эшләү, электрон рәвештә укыту методологиясеннән, edu.tatar.ru.республика мәгариф системаларыннан файдалану, мәгълүматны элек сатып алынган интернет панельләргә чыгарырга мөмкинлек бирәчәк.

2022 елда оптик элемтә линияләре буенча югары тизлектәге «Интернет» челтәренә 127 мең йорт хуҗалыгы тоташтырылды. Элемтә операторлары абонентларны зур тизлектәге «Интернет» челтәренә тоташтыруны тәэмин итә (секундына 1 Гигабит).

Цифрлаштыру өлкәсендә тигезсезлекне бетерү федераль программасы гамәлгә ашырылды. 2022 елда республиканың 100 дән 500 кә кадәр кеше яши торган 38 торак пункты өчен 4G мобиль элемтәсеннән куллану мөмкинлеге булдырылды. 2023 елда мондый эшне дәвам иттерәчәкбез. «Ростелеком» ГАҖ «Т2 Мобайл» ҖЧҖ белән берлектә республиканың 100 дән 500 кә кадәр кеше яши торган 78 торак пунктын мобиль элемтә белән тәэмин итүне ниятли.

Йөздән артык мәдәният, авыл һәм урман объектларын Цифрлаштыру елында зур тизлектәге «Интернет» челтәренә тоташтыру оештырылды. «Ростелеком» ГАҖ федераль челтәр аша мәгълүмат тапшыру буенча бердәм челтәргә 1 718 мәгариф оешмасын (мәктәп, техникум, көллият) тоташтырды.

ИТ-секторда илнең һәм Европа-Азия икътисадый бердәмлеге илләренең бәйсезлегенең технологик нигезе буларак Микропроцессорлар һәм микроэлектроника үзәге төзелде. «АйСиЭл» компанияләр төркеме тарафыннан төп платалар һәм компонентлар җитештерү заводын төзү проектына (2022–2023 елларда төзеләчәк) инвестицияләр күләме 2,0 млрд сум дип бәяләнә (шул исәптән1,5 млрд сум – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары, 0,5 млрд сум – предприятиенең үз акчасы). 300 дән артык эш урыны булдыру планлаштырыла, 5 елдан продукция эшләп чыгару күләме елына 1 млн берәмлеккә җитәчәк.

2022 елның 30 августында Казан шәһәрендә югары технологияләр өлкәсендә яңа технопарк мәйданчыгы ачылу Цифрлаштыру елының иң әһәмиятле чараларының берсе булды. Аңа күренекле Совет галиме, беренче совет электрон исәпләү машиналарын уйлап табучы Б.И. Рәмиев исеме бирелде. Технопарк Татарстандагы өченче ИТ-парк булды. 2023 елның 20 февраленә аның катнашуы мөмкин булган резидентлар белән тәэмин ителеше 74 % тәшкил итте. Төп инфраструктурага балалар ИТ-паркы, «Арена» киберпаркы, цифрлы китапханә (коворкинг), «Хаб» стартапы, конференц-сервис мәйданчыгы һәм сөйләшүләр алып бару бүлмәләре, криптополигон һәм сервис-резидентлар керә.

Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә 2022 ел дәвамында мәктәп укучылары өчен ЦИФР ДӘРЕСЛӘРЕ уздырылды. Аларда республика хакимияте органнарының цифрлы нигезгә күчү өчен җаваплы җитәкчеләре, шулай ук Татарстанның иң зур ИТ-компанияләре җитәкчеләре катнашты. Ел йомгаклары буенча барлык муниципаль районнарда 12 мең укучы өчен 600 дәрес уздырылды. Проектта республиканың якынча 1 400 мәктәбе катнашты.

Моннан тыш, Цифрлаштыру елында түбәндәге киң колачлы чаралар уздырылды:

цифрлы чишелешләр эшләү буенча республиканың район үзәкләрендә һәм шәһәрләрендә уздырыла торган TATAR HACK республика конкурсы. Аның төп максаты – урта һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләре укучыларын һәм студентларын ИТ-чишелешләр эшләүгә тарту. Конкурс 24 муниципаль районда узды, анда 1 500 дән артык кеше катнашты;

2022 елның 23 июлендә «Урам» экстрим-паркында республика ИТ-компанияләре арасында «Цифровиада» дигән спорт-күңел ачу спартакиадасы узды. Чараларда 5 меңнән артык шәһәр кешесе, 1 100 дән артык бала осталык дәресләрендә катнашты;

2022 елның 30 августында TATFUTURE фестивале («ТатарстанКиләчәк») узды, аны мәйданчыгында 60 мең кеше тамаша кылды. Фестиваль командасында төрле юнәлештәге 300 белгеч катнашты. Бу Татарстанның ИТ-индустриясендә аеруча киңколачлы чара булды. Анда ИТ өлкәсендә үз эшләнмәләрен «АК БАРС» БАНК ГАЖ, «КазанЭкспресс» маркетплейсы, «АйСиЭл – КПО ВС» АЖ, «Сколково» инновация үзәге тәкъдим итте.

**9. Күпфатирлы йортларда уртак милекне капиталь төзекләндерү төбәк программасын үтәү тизлеген саклау өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан күрелә торган чаралар турында.**

Күпфатирлы йортларда уртак милекне капиталь төзекләндерү Күпфатирлы йортларда уртак милекне капиталь төзекләндерү төбәк программасы нигезендә башкарыла (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары, алга таба – Төбәк программасы).

Максатларында Төбәк программасы үтәү, хезмәтләр һәм (яисә) эшләрнең планлаштырыла торган төрләренә төгәллек кертү, дәүләт һәм муниципаль ярдәмнең төрләрен һәм күләмен билгеләү өчен аны гамәлгә ашыруның кыска вакыт аралыгына планнары раслана.

Татарстан Республикасы бюджетында Төбәк программасын башкару өчен ел саен 1 364,3 млн сум бүлеп бирелә.

2022 елда 742 күпфатирлы йортта уртак милек капиталь төзекләндерелде, 2023 елда мондый эшләрне 716 күпфатирлы йортта уздыру каралган.

**10. Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең 2023 елда инфраструктур бюджет кредитларын кулланып инфраструктур проектлар гамәлгә ашыру планнары турында (төзелеш объектлары турындагы мәгълүматны кертеп).**

Инфраструктур бюджет кредитлары кысаларында 2023 елның февралендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына инфраструктур бюджет кредитларының өстәмә акчалары хисабына гамәлгә ашыру өчен 5 объектны кертүне сорап гариза бирде:

Казан – Яшел Үзән трассасы янындагы территориядә су белән тәэмин итү системасын төзү (Зур Яшел Үзән);

«Салават Күпере» торак районы өчен инженер-техник тәэминат челтәрләрен төзү. Хуҗалык-көнкүреш канализациясе челтәрләре. 6 этап: Зеленодольск муниципаль районының Васильево шәһәр тибындагы поселогында җитештерү күләмен тәүлегенә 32 мең куб. метрлык биологик чистарту корылмалары (БЧК) төзү (икенче чираты);

Зеленодольск муниципаль районының Васильево шәһәр тибындагы поселогында чистарту корылмалары территориясендә инженерлык челтәрләре һәм корылмалары төзү;

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында (Столбище, Усад авыллары, «Ак Барс» ТК, «Ак Барс Девелопмент» ТК районында. 2 нче этап Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында БожраД630, «Каенлык» су алу-насос станциясе җитештерүчәнлеген тәүлеккә 62 мең куб. метрга җиткерү) («Лаеш узелы»);

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районындагы «Иннополис» махсус икътисадый зонасы мәйданчыгыннан «Каенлык» канализация насос станциясенә кадәр басымлы хуҗалык-көнкүреш канализациясе төзү – 2 нче этап («Иннополис» МИЗ дан КНС-2) («Лаеш узелы»).

Объектларны программага кертү турындагы карарны федераль хакимият органнары хәл итә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Урынбасары М.Ш. Хөснуллин рәислегендә Россия Федерациясе төбәк үсеше хөкүмәт комиссиясе Президиумы утырышларында раслана.

## Социаль сәясәт

**11.** Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү буенча Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары тарафыннан алып барыла торган эш турында.

2022 елда Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары тарафыннан 81 558 граждан мөрәҗәгате карап тикшерелде (2021 елда – 99 510 мөрәҗәгать), 61 245 мөрәҗәгать контрольгә алынды. 1 717 мөрәҗәгать

урыннарга барып тикшерелде. Интернет-кабул итү бүлмәләре аша электрон рәвештә 24 945 мөрәҗәгать кабул ителде. Шәхсән кабул итү вакытында 8 344 кеше, шулардан 857 граждан – министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләре тарафыннан шәхсән кабул ителде.

Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү рәвешләрен һәм ысулларын камилләштерү максатларында 2022 елда министрлыклар һәм ведомстволар видеоконференция системасы ярдәмендә сакланыла торган каналлар буенча гражданнарны кабул итүне оештыру мөмкинлегеннән файдалануны дәвам итте. Ел дәвамында 263 видео-кабул итү оештырылды.

Республика дәүләт хакимияте башкарма органнары җитәкчеләре тарафыннан гражданнарны кабул итүнең бердәм көне билгеләнде – һәр сишәмбе көнне 14 сәгатьтән соң. Әлеге көнне министрлыкларга һәм ведомстволарга 2 419 кеше мөрәҗәгать итте, шуларның 826 сы – җитәкчеләр тарафыннан кабул ителде.

Мөрәҗәгатьләрнең эчтәлеге һәм саны халык ихтыяҗларын, аларны борчыган мәсьәләләрне һәм аларның рухи халәтен билгеләүче индикатор булып тора һәм шул ук вакытта күптөрле мәсьәләләр буенча җәмәгатьчелекнең фикерен күрсәтә. Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшне нәтиҗәле итеп оештыру халык ихтыяҗларын канәгатьләндерергә, социаль киеренкелекне киметергә, дәүләт органнарының абруен арттырырга мөмкинлек бирә.

Дәүләт органнары «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтларында гражданнардан кабул ителгән мөрәҗәгатьләрне анализлый, шулай ук билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагылышлы аеруча актуаль мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирә.

**12. Татарстан Республикасында газ кертү буенча социаль программаны гамәлгә ашыруга юнәлтелгән чаралар турында.**

«Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан 2021 елның октябрендә муниципаль берәмлекләрнең йорт хуҗалыкларына уздырган инвентаризация нәтиҗәләре нигезендә газ кертүнең план-графигы формалаштырылды һәм расланды, 2021–2023 елларга капитал кертү лимитлары билгеләнде. Хәзерге вакытта 12 700 йорт хуҗалыгы чикләренә кадәр газүткәргечләр уздырылды, шулардан 6 942 йортка газ кертелде.

2022 ел йомгаклары буенча газ кертү турында мөрәҗәгать белән йорт хуҗалыкларыннан 17 меңнән артык гариза кабул ителде. Шул исәптән, аларның күбесе газ кертү план-графигына кертелмәгән.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 13 сентябрендәге 1547 номерлы карары белән расланган Газдан куллану җиһазларын һәм капиталь төзекләндерү объектларын газ бүлү челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру) кагыйдәләренең (алга таба – Газ бүлү челтәрләренә тоташтыру кагыйдәләре) 121 пункты нигезендә газ кертү программасы кысаларында газ бүлү челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру) буенча чараларны үтәү срогы газлаштыру программасы нигезендә билгеләнә, ул газ бүлү челтәрләренә тоташтыру эшләрен башкару өчен газ бүлү һәм (яисә) газ-транспорт системаларының газ үткәрүчәнлеген арттыру эшләрен башкару таләп ителгән

очракны да кертеп, газ бүлү челтәрләре һәм (яисә) газ-транспорт системалары төзүне һәм (яисә) үзгәртеп коруны үз эченә ала.

Йорт хуҗалыгы-гариза бирүче газлаштыру программасына кертелмәгән очракта, газ бүлү челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру) буенча чараларны үтәү срогы Газ бүлү челтәрләренә тоташтыру кагыйдәләренең 122 пункты нигезендә билгеләнә һәм 100 көннән 1 елга кадәр вакытны тәшкил итә.

Аерым йорт хуҗалыкларының план-графикка кертелмәве сәбәпле, «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте Газ бүлү челтәрләренә тоташтыру кагыйдәләренең 122 пункты нигезендә газ бүлү челтәрләренә тоташтыру турында шартнамәләр төзергә тиеш иде. Әлеге сәбәпләр буенча берничә объект буенча срокларны озайту турында өстәмә шартнамәләр төзергә туры килде. Шуның белән бәйле рәвештә, муниципаль берәмлекләргә киләчәктә торак пунктларда йортлар төзеләчәк икәнен күздә тотып, газ кертелергә тиешле йорт хуҗалыкларына кабаттан инвентаризация уздырырга кирәк булачак.

Газ бүлү челтәрләренә тулысынча тоташтырылмаган газ казаннарына хезмәт күрсәтү өлешендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 21 июлендәге 549 номерлы карары белән расланган Гражданнарның коммуналь-көнкүреш ихтыяҗлары өчен газ белән тәэмин итү кагыйдәләре нигезендә йорт эчендә һәм (яисә) фатир эчендә газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм аларны төзекләндерү турында шартнамәнең булуы газ белән тәэмин итү шартнамәсен төзү өчен мәҗбүри шарт булып тора. Шуның белән бәйле рәвештә, йорт эчендә һәм (яисә) фатир эчендә газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм аларны төзекләндерү турында шартнамә бары тик газны тоташтыру вакытына гына кирәк була. Газдан куллану җиһазларына гарантия эшләп чыгаручы завод тарафыннан билгеләнгән шартларда бирелә.

**13. ТКХ, җәмәгать транспортында йөрүгә тарифларның артуын туктатып торуга һәм халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын яхшыртуга юнәлтелгән чаралар турында.**

Россия Федерациясе Торак кодексының 157.1 статьясы нигезендә Россия Федерациясе субъектлары буенча гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләменең үзгәрү индексларын (алга таба – индекслар) һәм муниципаль берәмлекләрдә гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләменең чик (максималь) үзгәрү индексларын (алга таба – чик индекслар) раслап, гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен түләүне арттыруга чикләүләр кертелде.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карары нигезендә гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләменең үзгәрү индекслары Россия Федерациясенең барлык субъектлары буенча 2022 елның декабренә – 9 процент, 2023 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр 0 процент күләмендә билгеләнде.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 15 ноябрендәге 2490-р номерлы боерыгы нигезендә билгеләнгән индекстан республика буенча мөмкин булган тайпылыш дәрәҗәсе уртача 3 процент күләмендә расланды, аны аерым муниципаль берәмлекләргә карата да кулланырга мөмкин.

2022 елның 1 декабреннән 31 декабренә кадәр гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен түләү 883 муниципаль берәмлек буенча 9 проценттан, ә 29 муниципаль берәмлек буенча 12 проценттан (3 процент күләмендә мөмкин булган тайпылышны исәпкә алып) артмады. Кулланучының чик индекс күләме коммуналь хезмәтләр җыелмасына (торак фондының төзекләндерелү дәрәҗәсенә) һәм ресурслар белән тәэмин итү оешмалар өчен билгеләнгән хосусый тарифларга (салкын һәм кайнар су белән тәэмин итү, юынтык суларны агызу, җылылык белән тәэмин итү) бәйле.

Республикада коммуналь хезмәтләр (җылылык энергиясе, салкын һәм кайнар су белән тәэмин итү, юынтык суларны агызу, электр һәм газ белән тәэмин итү, каты коммуналь калдыклар белән эш итү) өчен тарифлар билгеләү, шулай ук аларның кулланылышын контрольдә тоту өлкәсендә вәкаләтле дәүләт хакимияте органы булып Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты тора.

Аз керемле гражданнарга торак-коммуналь хезмәтләр (алга таба – ТКХ) өчен түләүгә адреслы субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме каралган. Субсидияләр алуга хокукы булган гражданнарга федераль законнар нигезендә республика гражданнарының ТКХ өчен түләүгә тотарга мөмкин булган шәхси чыгымнарының төбәк стандартын, шулай ук муниципаль берәмлекләр өчен аз керемлелек буенча субсидия бирелә торган торакның уңайлылык дәрәҗәсен һәм файдаланыла торган хезмәтләр җыелмасын исәпкә алып, бер кешегә исәпләгәндә ТКХ бәясенең төбәк стандартлары күләмнәрен исәпкә алып, гаиләнең уртак кеременең 21 проценты күләмендә ТКХ өчен түләүгә субсидия бирелә, ул федераль законнарда билгеләнгән дәрәҗәдән түбәнрәк (22 %).

Моннан тыш, алардан файдалануга хокукы булган гражданнарга федераль һәм республика законнарында каралган барлык төр ташламалар да бирелә.

ТКХ өчен түләүгә халыкка социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында карар территориаль социаль яклау органнары яисә Матди ярдәм күрсәтү (компенсация түләүләре) республика үзәгенең даими яшәү урыны буенча филиаллары тарафыннан кабул ителә.

Шул ук вакытта Россия Федерациясе Торак кодексының 159 статьясы 3 кисәге нигезендә субсидияләр Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимият органы тарафыннан гражданнар гаризалары нигезендә, аларның даими рәвештә бергә яшәүче гаилә әгъзаларын исәпкә алып, бирелә.

2022 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 28 ноябрендәге «Россия Федерациясе Торак кодексының 159 һәм 160 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 442-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнарның үзенең законлы көченә кергән суд акты нигезендә расланган соңгы өч елдан да артык булмаган чорда ТКХ өчен түләүләр буенча бурычлары булган очракта, әлеге гражданнарга субсидияләр бирелми.

Халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын арттыру, транспортта пассажирлар йөртүне тәэмин итү һәм тарифлар үсешен туктатып тору

максатларында 2022 елда түбәндәгеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бүлеп бирелде:

ташламалы категориягә кергән гражданнарга транспорт хезмәте күрсәтүче автотранспорт предприятиеләренең, тимер юл, һава һәм су транспортының алынмаган керемнәрен каплау;

финанс арендасы шартнамәләре буенча лизинг түләүләрен өлешчә түләүгә чыгымнарны каплау (Казан шәһәре, Лаеш муниципаль районы);

шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча авылларга пассажирлар йөртүгә субсидияләр бирү.

Регуляр муниципаль маршрутларда автомобиль транспорты ярдәмендә транспорт хезмәте күрсәтүгә, пассажирлар йөртү һәм багаж ташуга чик максималь тарифларны муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларыннан килгән гаризалар нигезендә Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты билгели. Дифференцияләнгән тарифлар өлешендә җайга салу икътисадый яктан дифференцияләүнең һәм халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын арттыруга юнәлтелгән шартларның максатка ярашлыгы принцибына нигезләнә. Дифференцияләнгән тарифлар транспортта йөрү өчен түләү ысулларына, шулай ук пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хезмәтләре күрсәтү шартларына бәйле рәвештә билгеләнә ала.

**14. Күпбалалы гаиләләргә өченче бала туу белән бәйле рәвештә бирелгән җир кишәрлекләрен үзләштерү мәсьәләләрен хәл итүдә булышлык күрсәтү турында.**

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарга милек хокукында бушлай җир кишәрлекләре бүлеп бирү (тапшыру) тәртибе билгеләнгән.

Күпбалалы гаиләләргә бирү өчен каралган җир кишәрлекләре исемлекләре аларны бирүнең максатлары (муниципаль берәмлекнең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш) һәм гариза бирүче гражданнар исемлегеннән чыгып, җирле үзидарә органнары тарафыннан аерым формалаштырыла һәм раслана.

Җирле үзидарә органнары җир кишәрлекләрен сайлау процедурасын уздыру урынын, датасын, вакытын һәм чиратта торучыларның, формалаштырылган җир кишәрлекләре санын исәпкә алып, әлеге процедурада катнашучы гражданнарны билгели. Гражданнар җир кишәрлеген чират нигезендә җир кишәрлекләре исемлегеннән сайлап ала.

Җир төзү оешмасы белгечләре җир төзү турында документлар, координатлар каталогы нигезендә җир кишәрлегенең борылыш нокталарын таба һәм гражданнарга үзләренә мөстәкыйль рәвештә межа билгеләре кую өчен билгеләп җибәрә (межа билгеләре гражданнар тарафыннан мөстәкыйль сатып алына, шуның белән бәйле рәвештә граждан межа билгесен әзерләү өчен материалны һәм аның зурлыгын сайлау хокукына ия). Кабаттан межа билгесе кую өчен җир кишәрлегенең борылыш нокталарын билгеләү процедурасы түләүле була.

Дәүләт һәм муниципаль милектә булган җирләрдән Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, өч һәм аннан да күбрәк баласы булган

гражданнарга җир кишәрлекләрен бушлай бирүгә мониторингны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы уздыра.

Җирле үзидарә органнары мәгълүматлары буенча Казан һәм Чаллы шәһәрләрен исәпкә алып, 2023 елның 1 гыйнварына (барлык чорга үсә баручы нәтиҗә белән):

җир кишәрлекләре алуга исемлекләргә 71 344 гаилә кертелгән;

48 508 җир кишәрлеге кадастр исәбенә куелган;

44 810 җир кишәрлеге бирелгән.

Күпбалалы гаиләләргә бирелә торган җир кишәрлекләрен инженерлык инфраструктура объектлары белән тәэмин итүгә мониторингны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы уздыра.

Проектлаштыруга норматив документлар нигезендә махсуслаштырылган проектлау оешмасы тарафыннан җирле үзидарә органнары раслый торган планлаштыру проектлары эшләнә. Торак йөзү проектын эшләгәндә барлык шәһәр төзү нормалары исәпкә алына һәм тиешле социаль һәм транспорт инфраструктурасын урнаштыру өчен урыннар карала, шулай ук кулланылырга мөмкин булган егәрлекне исәпкә алып, коммуникацияләргә тоташтыру өчен техник шартлар билгеләнә.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә халыкны электр энергиясе, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итүне оештыру җирле үзидарә мәсьәләләренә карый.

Муниципаль берәмлекләр мәгълүматлары буенча күпбалалы гаиләләргә бирелә торган җир кишәрлекләре түбәндәге инженерлык инфраструктурасы белән тәэмин ителгән (ярдәм чарасын тормышка ашыруның барлык чорына үсә баручы нәтиҗә белән):

электр энергиясе тапшыру линияләре – 23 132;

су белән тәэмин итү – 11 037;

газ белән тәэмин итү – 11 392;

асфальт түшәлгән юллар – 3 021;

таш түшәлмәгән юллар – 30 144.

**15. Демографик хәлне яхшыртуга, шул исәптән үлүчеләр санын киметү юлы белән, юнәлтелгән чаралар турында.**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 28 декабрендәге 2924-б номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасында 2022–2025 елларга гаилә һәм демография сәясәтен тормышка ашыру буенча чаралар планы расланды.

«Балалары булган гаиләләргә айлык түләүләр турында» 2017 елның 28 декабрендәге 418-ФЗ номерлы Федераль закон кысаларында 2018 елның 1 гыйнварыннан соң туган (тәрбиягә алынган) беренче балага айлык түләү билгеләнә. 2020 елның 1 гыйнварыннан әлеге түләү баласына өч яшь тулганчы, җан башына уртача кереме эшкә яраклы халыкның яшәү минимумыннан ике тапкыр

кимрәк булган гаиләләргә бирелә. 2022 елда түләүне 35 мең кеше алды, федераль бюджеттан 3,68 млрд сум акча бүлеп бирелде.

2018 елдан Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл җирлекләрендә даими яшәүче хатын-кызларда бер һәм аннан күбрәк балалар табуга кызыксындыру уяту өчен өстәмә акча бүлеп бирелде. Әлеге түләү түбәндәгечә бирелә: 25 яшькә кадәрге хатын-кызларга беренче баласын тапкач – 50 мең сум, 29 яшькә кадәрге хатын-кызларга өченче һәм аннан соңгы һәр баласын тапкач – 100 мең сум. 2018–2022 елларда әлеге акчалата түләүне республикада 10,8 мең кеше алды, 2022 елда – 1,9 мең кеше (1 604 кешегә – беренче баласын тапкач, 359 кеше – өченче һәм аннан соңгы балаларын тапкач). 2022 елда финанслау күләме 115,9 млн сум тәшкил итте.

2020 елда балалары булган гаиләләрне социаль яклауның өстәмә чаралары кертелде:

җан башына уртача кереме яшәү минимумыннан түбән булган өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләләргә балалар бакчасы өчен түләүгә компенсация күләме 100 процентка кадәр җитте. 2022 елда 6,2 мең гражданга түләүләр күчерелде;

җан башына уртача кереме яшәү минимумыннан түбән булган гаиләләрдәге 3 яшькә кадәр балаларга дарулар сатып алуга 10,0 мең сум күләмендә түләү бирелә. 2022 елда әлеге түләүләрне 23,8 мең граждан алды;

җан башына уртача кереме яшәү минимумыннан артмаган яңа туган баласы булган гаиләләргә бала кирәк-яракларыннан торган бүләкләү комплектлары бирелә. 2022 елда 3,1 мең бүләкләү комплекты бирелде;

ата-аналарының берсе яисә икесе дә инвалидлар һәм (яисә) балаларның берсе инвалид булган 18 яшькә кадәрле биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие түләнә. 2022 елда 1,2 мең гаилә әгъзасына түләү бирелде.

Россия Федерациясе Президентының «Балалары булган гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» 2020 елның 10 мартындагы 199 номерлы Указын үтәү йөзеннән 2020 елның 1 гыйнварыннан җан башына уртача кереме яшәү минимумыннан артмаган гаиләләргә 3 яшьтән алып 7 яшьлек балалары өчен айлык түләү бирелә. Балалар өчен түләү күләме дифференцияләнгән: төбәк яшәү минимумының 50 проценты (5 738 сум), 75 проценты (8 607 сум) яисә 100 проценты (11 476 сум). 2022 елда гомуми суммасы 6,4 млрд сум күләмендә 79,7 мең балага түләү күчерелде.

2000 елдан дәүләт бүләге – «Ана даны – Материнская слава» медале –биш һәм күбрәк бала тудырган һәм аларны лаеклы тәрбияләп үстерүче (тәрбияләп үстергән) хатын-кызларга ана булуның югары дәрәҗәдәге билгесе гамәлгә куелды. Соңгы 10 елда «Ана даны – Материнская слава» медале белән 1,5 мең ана бүләкләнде, аларга 50 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк тапшырылды. Алты һәм күбрәк бала тәрбияләгән аналар өчен акчалата бүләк күләме аннан соңгы һәр бала өчен, аларга бүләкләү көненә 3 яшь тулган булу шарты белән, һәр балага 10 мең сумга арттырыла. 2022 елда «Ана даны – Материнская слава» медале белән 22 кеше бүләкләнде.

2022 елда республикада гаиләнең һәм ата-ана хезмәтенең абруен арттыру максатларында яңа дәүләт бүләге – «Ата-ана фидакарьлеге» медале гамәлгә

куелды, аның белән җиде һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче яисә тәрбияләгән, кимендә бер балигъ булмаган балалары булган гаиләләр бүләкләнә. «Ата-ана фидакарьлеге» медале белән бүләкләнгән ата-аналарның берсенә (уллыкка алучының) 100 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк бирелә. Әлеге медаль белән 2022 елда 9 ата-ана бүләкләнде.

Кабул ителгән чаралар күпбалалы ата-аналарның саны артуга этәргеч бирә. 10 ел дәвамында аларның саны 70 процентка артты: 24,8 мең гаиләдән (2012 елның 1 гыйнварына) 42,2 мең гаиләгә (2023 елның 1 гыйнварына) җитте.

Республикада бала табучыларның саны кимү, кешеләрнең яше арту, COVID-19 белән бәйле вазгыятьнең саклануы сәбәпле демографик хәлнең катлаулы булуына карамастан, республика 2022 елның гыйнвары – ноябре нәтиҗәләре буенча Россиянең үлүчеләр саны буенча иң түбән күрсәткечкә ия төбәкләренең егерме лидеры арасында (Идел буе федераль округында – 1 нче урында). Үлүчеләр саны 2021 елның шушы чоры белән чагыштырганда 25,8 процентка кимеде һәм 1 000 кешегә 11,5 очрак тәшкил итте.

Үлүчеләр саны әлеге күрсәткеч структурасында беренче урынны алып торган төп сәбәпләр нигезендә кимеде (2021 елның шушы чоры белән чагыштырганда): кан әйләнеше авыруларыннан – 6,2 процентка, шешләрдән – 1,5 процентка, сулыш органнары авыруларыннан – 36,9 процентка, аш кайнату органнары авыруларыннан – 7,1 процентка, COVID-19 дан – 5,4 тапкырга.

Республикада төп авырулардан үлүчеләр санын киметү буенча план тормышка ашырыла. Төп чара булып өлкән яшьтәге кешеләрнең билгеле бер төркеменә профилактик һәм диспанцер тикшерүләр уздыру тора. «Үлүчеләр саны» һәм «Өлкән яшьтәге кешеләрнең билгеле бер төркеменә профилактик һәм диспанцер тикшерүләр уздыру» күрсәткечләре муниципаль дәрәҗәгә җәелдерелде һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында республика муниципаль районнары (шәһәр округлары) җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган дәрәҗәсенә ирешү турында килешүгә кертелде. Муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыклары белән берлектә аларның үтәлешенә мониторинг уздырыла.

Үлүчеләр саны югары булган сәламәтлек саклау учреждениеләре эшчәнлеген оператив контрольдә тоту һәм аларга методик яктан җитәкчелек итү максатларында югары технологияле үзәкләргә («Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Төбәкара клиника-диагностика үзәге», Казан шәһәренең «7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе», Чаллы шәһәренең «Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү хастаханәсе», «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Медицина-санитария часте, «В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте һәм Әлмәт шәһәренең медицина-санитария часте» дәвалау-профилактика учреждениесе) районнарга җитәкчелек итү бурычы куелды.

Татарстан Республикасында үлем очраклары сәбәпләрен анализлау буенча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы комиссиясе төзелде, аның эш барышы кысаларында һәр атна саен күчмә контроль чаралары, шулай ук 45 муниципаль берәмлек вәкилләре катнашында киңәшмәләр уздырыла, анда районнардагы демография хәлгә анализ ясала, үлүчеләр санын киметүгә юнәлтелгән беренчел әһәмияттәге чараларны тормышка ашыру турында фикер алышалар, медицина оешмалары җитәкчеләре һәм штаттан тыш баш белгечләр чыгыш ясый.

2023 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетында туучылар санын арттыру белән бәйле чараларны гамәлгә ашыруга 18,7 млрд сум күләмендә чыгымнар каралган, шул исәптән федераль бюджет акчалары хисабыннан – 1,7 млрд сум, Татарстан Республикасы һәм җирле бюджетлардан – 17 млрд сум.

## Сәламәтлек саклау

**16. Санкцияләр кертелү шартларында дәвалау учреждениеләрен медицина җиһазлары һәм медикаментлар белән тәэмин итү буенча республикада алып барыла торган эш турында.**

2022 елда гомуми суммасы 2,8 млрд сумга медицина җиһазлары сатып алынды: шулардан түбәндәге программалар һәм проектлар кысаларында:

«Сәламәтлек саклауның беренчел буынын модернизацияләү» федераль проекты – 2 835 берәмлек, шул исәптән 63 берәмлек авыр җиһазлар (13 компьютер томографы, 18 флюорограф, 16 маммограф, 16 стационар рентген-аппараты);

«Йөрәк-кан тамыры авыруларына каршы көрәшү» федераль проекты – беренчел кан тамыры авыруларын дәвалау үзәкләренең неврология бүлекчәләрендәге баш миендә кан әйләнеше кискен бозылган авырулар өчен 357 берәмлек (шул исәптән 6 компьютер томографы);

өлкән яшьтәге авыруларга һәм балаларга паллиатив медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмалары җиһазландыруга – 187 берәмлек;

«Сәламәтлекне торгызу өчен оптималь медицина тернәкләндерүе» федераль проекты – 176 берәмлек;

«Онкология авыруларына каршы көрәшү» федераль проекты –19 берәмлек, шул исәптән 7 берәмлек авыр җиһаз (1 бер фотонлы эмиссия компьютер томографы һәм компьютер томографының берләштерелгән катнаш системасы, 2 якын фокуслы рентгенотерапия аппараты, 1 ангиограф, 2 компьютер томографы, 1 позитрон-эмиссия томографы/компьютер томографы);

«Инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы тернәкләндерү һәм абилитацияләү системасын формалаштыру» төбәк ярдәмче программасы – 7 берәмлек;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым боерыклары нигезендә – 3 компьютер томографы, 161 берәмлек медицина суыткыч җиһазлары, 4 йөрү күнекмәләрен торгызу роботлаштырылган системасы, мобиль медицина комплексы һәм микроавтобус, Б һәм В класслы медицина калдыкларын аппарат ярдәмендә йогышсызландыру/зарарсызландыру өчен 34 җайланма, шулай ук үпкәләрне ясалма вентиляцияләү аппаратлары һәм һава агымын кушу генераторы

булган һавадымландыргычлар, гематологик анализатор, стерилизаторлар, ультратавыш тикшеренүләре аппараты, суыткычлы лаборатория центрифугасы, хромато-масс-спектрометр, гастроскопия ясау өчен эндоскоп кую стойка, ясалма кан әйләнешен тикшерү аппараты, хирургия микромотор аппараты, цифрлы күчмә рентген-аппарат, басымы җайга салына торган һава тутырылган матрас өсте җәймәләре булган авыруларның тәнендә озак ятудан җәрәхәтләр булдырмау системалары сатып алынды.

Татарстан Республикасы  Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан көн саен даруларны ваклап сатып алуга, бюджет учреждениеләре өчен сатып алулар буенча медицина эшләнмәләре китертүгә, ассортиментның төрлелегенә һәм бәяләрнең һәркем сатып алырлык булуына, бюджет учреждениеләре өчен сатып алулар кысаларында эшләнмәләрнең җитмәвенә мониторинг уздырыла, чит ил даруларын илебездә җитештерелгән даруларга алмаштыру буенча эш алып барыла.

Муниципаль берәмлекләрдә даруларны ваклап сатып алуга оператив мониторинг уздырыла, ул даруларның иң аз төрләренең булуын (51 төрле) тикшерү максатларында даруханә челтәрләрендә яшәү өчен иң кирәкле булган 50 төр даруның һәм башка категория 50 төр даруның булуына, шулай ук әлеге даруларга бәяләргә мониторинг уздырыла. Әлеге вакытта тиешле ассортимент сатуда бар.

«Таттехмедфарм» дәүләт унитар предприятиесе тарафыннан 2023 елга сәламәтлек саклау учреждениеләре, ташламага ия гражданнарны тәэмин итү өчен дарулар һәм медицина эшләнмәләре сатып алуга 6,25 млрд сумлык 1 400 контракт төзелде. Дарулар һәм медицина эшләнмәләре контракт нигезендә китерелә, 2,1 айдан 7,8 айга кадәр запаслар бар.

**17. Республиканың зур шәһәрләрендәге яңа микрорайоннар территорияләрендә яңа сәламәтлек саклау учреждениеләре (хастаханәләр, поликлиникалар) төзү (ачу) барышы, Казан шәһәре күппрофильле балалар хастаханәсенең яңа бинасын төзү перспективалары турында.**

2022 елда республика программасы кысаларында 25 сәламәтлек саклау объекты төзелде, шул исәптән:

гомуми финанслау күләме 1466 млн сум булган 23 фельдшерлык-акушерлык пункты;

гомуми финанслау күләме 16,5 млн сум булган 1 патологоанатомия бүлекчәсе;

гомуми финанслау күләме 62,2 млн сум булган 1 гомуми практика табибы офисы.

«Стационарлар төзү һәм аларны капиталь төзекләндерү» республика программасы кысаларында 2 объект төзелде:

«Чистай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең авыруларны кабул итү-диагностика бүлекчәсе, Чистай муниципаль районының Чистай шәһәре;

«Татарстан Республикасы  Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бинасына янкорма (А дәвалау корпусы), Казан шәһәре (магнит-резонанс томографиясе җайланмасы өчен).

2022 елда сәламәтлек саклауның беренче буынын яңартып кору федераль программасын гамәлгә ашыру кысаларында 34 объектта төзелеш эшләре башкарылды, шулардан:

32 объектта төзелеш эшләре тәмамланды (29 фельдшерлык-акушерлык пункты, Әлмәт шәһәрендә гомуми практика табибы һәм педиатр үзәге, «Лениногорск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Иске Куак табиблык амбулаториясе, «Питрәч үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе табиблык амбулаториясе);

2 объект 2023 елга күчте («Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең күппрофильле поликлиникасы (өлкәннәр һәм балалар өчен), Казан шәһәренең «6 номерлы шәһәр балалар поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе балалар поликлиникасы филиалы).

2022 елда берничә программадан тыш объект төзелде:

Казан шәһәренең «7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе базасында дәвалау-тернәкләндерү үзәге;

Түбән Кама шәһәрендәге «Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең авыруларны кабул итү-диагностика бүлекчәсе бинасы;

Казан шәһәре Рауис Гәрәев урамында урнашкан Россия Федерациясе Оборона министрлыгының хәрби госпитале;

Буа муниципаль районының Күшке авылындагы фельдшерлык-акушерлык пункты.

«Профессор А.Ф. Агафонов исемендәге Республика йогышлы авырулар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бинасы яңартып корылды, территория төзекләндерелде, җиһазлар, мебель һәм кирәк-яраклар сатып алынды.

2023 елда 2022 елдан күчкән программадан тыш объектлар төзелеше дәвам иттерелә:

Казан шәһәренең «7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең перинаталь үзәге;

«Әлмәт үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең икеләтә билгеләнештәге йогышлы авырулар өчен бокслары булган махсуслаштырылган авыруларны кабул итү-диагностика бүлекчәсе.

2023 елда түбәндәгеләрне төзү каралган:

«Стационарлар төзү һәм аларны капиталь төзекләндерү» республика программасы кысаларында 22 фельдшерлык-акушерлык пункты, 1 гомуми практика табибы офисы;

«Салават Күпере» торак комплексында бер сменага 750 авыру, шул исәптән 250 бала кабул итү каралган поликлиника бинасы (Казан шәһәренең сәламәтлекне саклауны үстерү программасы);

Дербышки поселогында бер сменага 200 кеше кабул итү каралган Казан шәһәренең «6 номерлы шәһәр балалар поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе филиалы;

Казан шәһәренең «Чебакса» торак массивында табиб-терапевт һәм педиатр үзәге (әлеге үзәк өлкән яшьтәге кешеләргә амбулатория-поликлиника ярдәме күрсәтүне оештыру өчен «20 номерлы шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе филиалы һәм балаларга хезмәт күрсәтү өчен Казан шәһәренең «6 номерлы шәһәр балалар поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе филиалы булачак дип планлаштырыла);

Зеленодольск муниципаль районының Осиново авылында өлкән яшьтәге кешеләр һәм балалар өчен күпфункцияле поликлиника.

Казан шәһәренең «1 номерлы шәһәр балалар хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бинасы төзү» объектына проект-смета документлары эшләнә, төзелешнең бәясе проектлаштыру нәтиҗәләре буенча билгеләнәчәк. Объектны Казан шәһәренең Хөсәен Ямашев проспектында урнашкан 3,5 га мәйдандагы җир кишәрлегендә төзү күздә тотыла.

**18. Татарстан Республикасы халкына республиканың санаторий-курорт учреждениеләрендә дәвалануын тәмамлауга (тернәкләндерүгә) финанс чыгымнары нормаларын арттыру планлаштырыламы?**

Эшләүче гражданнарга стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры санаторий-курорт учреждениесендә (дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе) дәвалануын тәмамлау (тернәкләндерү) таләп итәлә торган авырулар исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 28 мартындагы 233 номерлы карары белән расланды.

2022 елда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «2022 елда эшләүче гражданнарның стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры санаторий-курорт оешмаларында, дәүләт медицина оешмаларында медицина тернәкләндерүе узуның 3 этабын оештыру турында» 2021 елның 28 декабрендәге 2963 номерлы карары нигезендә санаторий-курорт оешмалары белән 5 588 эшләүче гражданны тернәкләндерү өчен 165,2 млн сумга шартнамәләр төзелде.

Татарстан Республикасы бюджетында 2023 елга әлеге максатларга 174,8 млн сум каралган, бу исә 2022 ел белән чагыштырганда 6,1 процентка артыграк. Әлеге акча 5 592 эшләүче гражданга дәвалануын тәмамлау (тернәкләндерү) мөмкинлеге бирә.

Хәзерге вакытта эшләүче гражданнарга дәвалануын тәмамлау (тернәкләндерү) өчен норма чыгымнарын арттыру мәсьәләсен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карап тикшерә.

**19. Шәһәр гомуми белем бирү оешмаларында физик культура белән шөгыльләнү өчен шартлар булдыру мәсьәләсен хәл итү перспективалары турында (шул исәптән спорт заллары төзү, шәһәр мәктәпләренең иске биналарда урнашкан спорт залларын капиталь төзекләндерү турында).**

2022 елда универсаль спорт мәйданчыклары һәм аз бюджетлы спорт корылмалары төзү буенча республика программасы кысаларында гомуми финанслау күләме 500,0 млн сумга 10 объект төзү эшләре тәмамланды, шул исәптән:

20х40 зурлыгында каркас-тент капламлы футбол кыры һәм административ бинасы булган 6 ябык футбол манежы;

3 универсаль спорт мәйданчыгы;

1 блоклы модульле чаңгы базасы, ул мебель һәм кирәк-яраклар белән җиһазландырылган.

«Демография» илкүләм проектының «Спорт – тормыш нормасы» проектын тормышка ашыру кысаларында Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр тибындагы поселогында ясалма боз түшәлгән ябык шугалак төзелде.

2022 елда программадан тыш чаралар кысаларында түбәндәгеләр төзелде:

Зеленодольск муниципаль районының Васильево шәһәр тибындагы поселогында бассейн;

Тәтеш муниципаль районында универсаль спорт мәйданчыгы булган 8 спорт комплексы;

Менделеевск муниципаль районының Менделеевск шәһәрендә стадион (1 000 урынга исәпләнгән);

Казан шәһәре Мәскәү районының «Россия Федерациясе герое майор С.А. Ашихмин исемендәге 130 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе территориясендә ачык типтагы физкультура-сәламәтләндерү комплексы;

«Актүбәнең сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен мәктәп-интернат» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе территориясендә универсаль спорт мәйданчыгы, Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы.

2022 елда спорт объектларын капиталь төзекләндерү республика программасы кысаларында гомуми суммасы 500,0 млн сумга 23 спорт объекты капиталь төзекләндерелде.

Авылларда һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру максатларында «Мәгариф» илкүләм проектының «Һәр баланың уңышы» федераль проекты кысаларында ел саен республиканың авылларда һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында спорт заллар капиталь төзекләндерелә. 2023 елда түбәндәге ике гомуми белем бирү мәктәбенең спорт залларын капиталь төзекләндерү планлаштырыла:

Чүпрәле муниципаль районының «Дементьев Василий Степанович исемендәге Алешкин-Саплык урта гомуми белем бирү мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

Теләче муниципаль районының «Теләче урта гомуми белем бирү мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе.

Гомуми белем бирү оешмалары биналарын капиталь төзекләндерү федераль программасы кысаларында спорт залларын капиталь төзекләндерү планлаштырылган. Объектлар исемлеге, эшнең төрләре һәм күләме муниципаль берәмлекләр тарафыннан билгеләнә.

2023 елда 2022 елдан күчкән объектлар төзү эшләре дәвам иттерелә:

Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәрендәге боз аренасы;

Зәй муниципаль районының Зәй шәһәрендәге ябык йөзү бассейны;

Казан шәһәре Яңа Савиново районындагы «49 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе территориясендә «акыллы» спорт мәйданчыгы («Бизнес-спринт (Мин спортны сайлыйм)» федераль проекты кысаларында);

Түбән Кама муниципаль районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 27 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе территориясендә «акыллы» спорт мәйданчыгы («Бизнес-спринт (Мин спортны сайлыйм)» федераль проекты кысаларында);

Зеленодольск муниципаль районының Васильево шәһәр тибындагы поселогында модульле спорт залы.

2023 елда республика программасы кысаларында 8 объект төзү планлаштырылган, шул исәптән:

4 универсаль спорт мәйданчыгы;

20х40 зурлыгында каркас-тент капламлы футбол кыры һәм административ бинасы булган 4 ябык футбол манежы.

Моннан тыш, «Бизнес-спринт (Мин спортны сайлыйм)» федераль проектын тормышка ашыру кысаларында Әлмәт һәм Чаллы шәһәрләрендә дәүләт-хосусый партнерлыгы механизмын кулланып, ябык футбол манежлары төзү планлаштырыла.

Спорт объектларын капиталь төзекләндерү республика программасы кысаларында 15 объект төзекләндерү планлаштырыла.

**20. Татарстан Республикасында мәктәп медицинасын үстерү өчен шартлар тудыру турында.**

Мәгариф оешмалары укучыларына медицина хезмәте күрсәтү «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларында белем бирү һәм тәрбия бирү чорында балигъ булмаганнарга беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүне оештыру медицина оешмасының мәгариф оешмасы адресы буенча медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булганда медицина оешмасының медицина хезмәткәрләре тарафыннан, мәгариф оешмасының медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия булганда мәгариф оешмасының медицина хезмәткәрләре тарафыннан мәгариф оешмалары биналарында; мәгариф оешмасында медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартларын булдыру (тиешле бүлмәләр бирү, шул исәптән гомуми белем бирү оешмаларының бүлмәләрен реконструкцияләү һәм үзгәртеп кору юлы белән бирү) өчен техник мөмкинлекләр булмаганда медицина оешмасының медицина хезмәткәрләре тарафыннан (территориаль принцип буенча) медицина оешмасы бүлмәләрендә гамәлгә ашырыла.

2012 елның ноябреннән Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән

министрлыгы белән берлектә, республика гомуми белем бирү оешмаларында, «АРМИС» аппарат-программа комплексын (алга таба – «АРМИС» АПК) файдаланып, табибка кадәрге скрининг диагностикасын үткәрүгә юнәлдерелгән проект гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасының гомуми белем бирү һәм медицина оешмаларында 264 «АРМИС» АПК урнаштырылды. 2022 елда гомуми белем бирү оешмалары базасында «АРМИС» АПК белән 9 968 укучыга тикшерү үткәрелде. Аның нәтиҗәләре буенча поликлиникага өстәмә тикшеренү өчен профильле белгечләргә 3 070 кеше җибәрелде, аларның йогышлы булмаган хроник авырулар үсү рискы факторлары ачыкланды.

## Мәгариф һәм мәдәният

### 21. Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү эше турында.

«Россия балалар һәм яшьләр хәрәкәте турында» 2022 елның 14 июлендәге 261-ФЗ номерлы Федераль законда гражданлык җәмгыятенең һәм дәүләтнең барлык институтлары катнашында яшьләргә тәрбия бирү процессын камилләштерүгә юнәлдерелгән хәрәкәт максатлары билгеләнде.

2022 елда Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан, кызыксынучы министрлыклар һәм ведомстволар, муниципалитетлар, иҗтимагый берләшмәләр белән берлектә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартындагы 158 номерлы карары белән расланган «2019–2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасының «2019–2025 елларга Татарстан Республикасы яшьләренә патриотик тәрбия бирү» ярдәмче программасын (алга таба – Ярдәмче программа) гамәлгә ашыру кысаларында яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча эш алып барды. 2023 елга Татарстан Республикасы бюджетында Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру өчен 10,05 млн сум күләмендә акча каралды.

Ярдәмче программаның төп максатлары – республикада иҗтимагый һәм икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итә торган патриотик тәрбия бирү системасын үстерү һәм модернизацияләү, Татарстан Республикасы балаларында һәм яшьләрендә гражданлык тиңдәшлеген, югары патриотик аң, Ватанга тугрылык, конституциячел вазыйфаларны башкаруга әзерлек, толерантлык, этнослар һәм конфессияләр арасындагы мөнәсәбәтләр культурасын формалаштыру.

2022 елда Татарстанда Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру кысаларында гомумән 14 яшьтән 35 яшькә кадәрге 184 меңнән артык кеше җәлеп итеп 42 зур чара, шул исәптән «Аҗаган» хәрби-спорт уены (41 мең катнашучы), «Мин – Россия гражданы!» акциясе (3 меңнән артык катнашучы), җәйге хәрби-патриотик палатка лагерьлары (3 мең кеше, шул исәптән тормышта авыр хәлдә калган 357 бала), «Җиңү» хәрби-спорт уенының республика этабы (12 мең катнашучы) үткәрелде.

Татарстан Республикасында яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирүне тәэмин итү өлкәсендә бурычларны гамәлгә ашыру кысаларында гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары өчен хәрби-укыту җыеннарын оештыру максатларында өч яшьләр сәясәте учреждениесе («Патриот» яшьләрне спорт-

патриотик һәм хәрби хезмәткә кадәрге әзерләү буенча республика үзәге» ДАУ, Чистай муниципаль районының «Ватан» хәрби-патриотик эш һәм хәрби хезмәткә кадәрге әзерләү үзәге» МБУ, Түбән Кама муниципаль районының «Патриот» хәрби-патриотик эш һәм хәрби хезмәткә кадәрге әзерләү үзәге» МБУ) базасында «Авангард» үзәкләре төзелде.

2023 елга Татарстан Республикасы бюджетында гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары өчен хәрби-укыту җыеннарын үткәрүгә 25,7 млн сум күләмендә акча каралды.

Хәзерге вакытта 38 муниципаль берәмлектә 153 хәрби-патриотик клуб оештырылды, аларда 10 яшьтән 16 яшькә кадәрге 14 083 яшүсмер катнаша.

Татарстан Республикасы территориясендә һәм аннан читтә эзләү эшчәнлеге «Татарстан Республикасының «Ватан» берләшмәсе» төбәк иҗтимагый яшьләр оешмасы тарафыннан гамәлгә ашырыла, ул 67 эзләү отрядыннан тора, анда гомумән 1 200дән артык кеше катнаша. 31 муниципаль берәмлектә, 67 торак пунктта Бөек Ватан сугышы чорының 79 хәрби каберлеге исәпкә алынган. 2022 елда республика эзләү отрядларының Бөек Ватан сугышы барган хәрби урыннар буенча 30 экспедициядә катнашуы оештырылды. Экспедицияләр барышында 311 сугышчының мәетләре алынды.

2022 елның апрелендә «Җиңү» бөтенроссия хәрби-спорт уенының республика этабы уздырылды.

2022 елның маенда кадетлар арасында Ватанны саклаучы көненә багышланган «Татарстан Республикасы ветераннары берлеге» сугыш ветераннары (инвалидлары) республика иҗтимагый оешмасы Кубогына күчә торган хәрби-гамәли спорт төрләре буенча республика спартакиадасы үткәрелде.

2022 елның сентябрендә югары белем бирү һәм урта һөнәри белем бирү мәгариф оешмалары студентлары арасында «Яшь армиячеләр алга!» республика хәрби-спорт уенының зона этаплары һәм Спортның хәрби-тактик һәм экстремаль төрләре буенча республика спартакиадасы үткәрелде.

2022 елның 3 сентябрендә «Единая Россия» бөтенроссия сәяси партиясе тарафыннан, иҗтимагый оешмалар белән берлектә, Бөек Ватан сугышы тарихын өйрәнүгә киң җәмәгатьчелекне җәлеп итү, яшьләрнең тарихи грамоталыгын һәм аларга патриотик тәрбия бирүне арттыру максатларында Бөек Ватан сугышы вакыйгалары темасына Халыкара тарихи диктант – Җиңү диктанты уздырылды. Җиңү диктантында Татарстан Республикасының 9 меңнән артык укучысы катнашты.

2022 елның ноябрендә хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле ир-егетләр арасында спортның хәрби-гамәли төрләре буенча республика спартакиадасы узды. Ярышлар, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты белән берлектә, «Патриот» яшьләрнең спорт-патриотик һәм хәрби хезмәткә алынганчы әзерлеге республика үзәгендә үткәрелде.

Республикада «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр формированиеләре үзәгенең «Свои» проекты гамәлгә ашырыла, әлеге проект социаль тотрыклылыкны арттыру һәм аңлы рәвештә тормыш юлын сайлау аша бүгенге көндәге хәлен үзгәртү максаты белән тормышта авыр хәлдә калган яшьләргә ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелә. Хәзерге вакытта үзәк үз эшен

40 муниципаль берәмлектә алып барыла, аларда 15 135 кеше катнашында 1 163 җәмәгать тәртибен саклау формированиесе эшли.

Ел саен балалар өчен палаткалы лагерьлар оештыруга юнәлдерелгән республика җәйге профильле сменалары проекты гамәлгә ашырыла, аларның төп максаты – яшьләргә гражданлык-әхлакый тәрбия бирү, яшүсмерләрне тискәре мохит йогынтысыннан читләштерү өчен шартлар тудыру. 2022 елда «Яшь десантник» дигән 8 хәрби-палаткалы патриотик лагерь (Апас, Минзәлә, Чистай, Биектау, Түбән Кама, Азнакай, Питрәч, Мамадыш муниципаль районнарында) ачылды.

«Җиңү хаты», «Хәтер чемпионы», «Георгий тасмасы», «Җиңү агачы», «Җиңү көне» флешмобы, «Җиңү Вальсы», «Хәтер шәме» һ.б. кебек бөтенроссия форматыннан халыкара форматка күчкән акцияләр һәм чаралар традициягә әйләнде.

Республикада «Җиңү волонтерлары» бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан төбәк бүлеге булдырылды, ул яшьләрне волонтерлык практикасына җәлеп итү юлы белән аларда Бөек Ватан сугышында җиңүгә бәйле хисләр тәрбияләүгә юнәлдерелде.

2022 елда «Җиңү волонтерлары» хәрәкәтенең Татарстан бүлеге тарафыннан 2 590 чара, шул исәптән «Блокада икмәге» бөтенроссия акциясе, Ленинград шәһәре блокадасын бетерүгә багышланган «Кинога тәнәфес» бөтенроссия яшьләр фестивале кысаларында фильмнар күрсәтү, «РИСК. Ленинград блокадасы» республика интеллектуаль уены оештырылды һәм уздырылды.

Ел саен республика гомуми белем бирү оешмаларында мәктәп укучыларының рухи-әхлакый үсешенә һәм аларны патриотик тәрбияләүгә юнәлдерелгән түбәндәге традицион чаралар уздырыла: кадетлар арасында Ватанны саклаучы көненә багышланган «Татарстан Республикасы ветераннары берлеге» сугыш ветераннары (инвалидлары) республика иҗтимагый оешмасы Кубогына күчә торган хәрби-гамәли спорт төрләре буенча республика спартакиадасы, «Алга» республика хәрби һәм спорт уены, «Ватанга хезмәт итәм! Халыкка хезмәт итәм!» төрле предметлар олимпиадасы.

Республикада «ЯШЬ АРМИЯ» хәрәкәтенең җирле бүлекләренең 49 штабы, 1 211 яшь армиячеләр отряды эшли, аларның гомуми саны 37 861 яшь армияче тәшкил итә. Муниципаль берәмлекләрдә ЯШЬ АРМИЯ йортларын төзү буенча юл карталары эшләнә.

Махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы гамәлгә ашырыла. Мәктәп укучылары «Солдатка видеооткрытка», «Үзебезнекеләрне ташламыйбыз», «Яшь армияче посылкасы», «Ватанны якларга дигән һөнәр бар!», «Фронт открыткасы», «Билгесез солдат көне», «Ватан Геройлары көне» кебек акцияләр һәм чараларда актив катнашалар.

2023 ел башында «#МыВместе» проекты кысаларында Россия мәктәп укучылары хәрәкәте һәм ЯШЬ АРМИЯ төбәк бүлеге активистлары Луганск һәм Донецк халык республикаларыннан күченеп килергә мәҗбүр булган кешеләргә гуманитар ярдәм җыюны оештырдылар.

## 22. Педагогик хезмәткәрләргә ярдәм итү һәм кызыксындыру чаралары

**турында.**

Тәрбиячеләрнең (кече педагогик хезмәткәрләрнең) хезмәт хакын, шул исәптән премиаль түләүләрен исәпләп чыгару Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә таянып гамәлгә ашырыла һәм хезмәткәрнең белем дәрәҗәсенә, квалификациясенә, башкарыла торган эшнең катлаулылыгына, күләменә, сыйфатына һәм шартларына бәйле.

Сыйныф җитәкчесе функцияләрен гамәлгә ашырган өчен педагогик хезмәткәрләргә аена бер сыйныф өчен 550 сум һәм бер укучыга 80 сум күләмендә түләүләр башкарыла. Моннан тыш, сыйныф җитәкчелеге өчен мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә федераль бюджет акчасы исәбеннән бер сыйныф җитәкчесенә аена 5 000 сум күләмендә ай саен бирелә торган акчалата түләү өстәмә каралган.

Яшь белгечләргә дәүләт ярдәме күрсәтү һәм республикада педагогик кадрларны беркетү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 29 декабрь, 1270 нче карары нигезендә яшь педагогларга педагог вазыйфасында өзлексез эшләгән беренче өч ел эчендә уку-укыту буенча алып барыла торган эш күләменә, эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә ай саен бирелә торган кызыксындыру характерында 2 510 сум күләмендә өстәмә түләү билгеләнде. Яшь педагогларга ай саен бирелә торган кызыксындыру характерында өстәмә түләү билгеләү хокукы түбәндәге оешмаларда бирелә: мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, гомуми белем бирү оешмалары, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалар, өстәмә белем бирү оешмалары.

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы буенча хезмәт өчен түләү җайга салына торган республика муниципаль учреждениеләренең кайбер педагогик хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру характерындагы түләүләр учреждение җитәкчесенең боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла һәм бары тик мәгариф өлкәсендәге төп педагогик хезмәткәрләргә карала.

Барлык кызыксындыру характерындагы түләүләрне һәм компенсация характерындагы түләүләрне исәпкә алып, гомуми белем бирү мәгариф оешмаларындагы педагогик хезмәткәрләрнең якынча бәяләнгән уртача эш хакы 2022 елда 44 157,4 сум, укытучыларның – 44 689,2 сум тәшкил итте.

2022 елда педагогик хезмәткәрләр өчен ярдәм чаралары буларак 12 мең берәмлек ноутбук сатып алынды һәм укытучыларга тапшырылды.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында 2022 елны Цифрлаштыру елы дип игълан итү турында» 2021 елның 8 октябрендәге ПУ-800 номерлы Указы нигезендә, шулай ук 2022 елгы мәгариф һәм фән хезмәткәрләренең «Цифрлаштыру эпохасында тәрбияләү һәм укыту: традицияләрне саклап, киләчәкне булдырабыз» дигән республика август

киңәшмәсе резолюциясен үтәү йөзеннән 2022 елда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, «Иннополис» университеты» югары белем бирү автоном коммерциягә карамаган оешмасы һәм «АйСиЭл Техно» ААҖ ярдәмендә башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын гамәлгә ашыручы республика педагогик хезмәткәрләре арасында «Цифрлы белем бирү контенты» онлайн платформасыннан иң яхшы файдаланучы» конкурсы үткәрелде. Аның нәтиҗәләре буенча 50 иң яхшы педагогик хезмәткәргә «АйСиЭл Техно» ААҖ акчасы исәбеннән сатып алынган ноутбуклар тапшырылды.

2020 елдан башлап, республикада «Земство укытучысы» программасы эшли, аның нигезендә авыл торак пунктларына, йә шәһәр тибындагы поселокларга, йә халкы 50 меңгә кадәр булган шәһәрләргә эшкә килгән (күченеп килгән) укытучыларга 1 млн сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирелә, аны билгеләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 26 февраль, 149 нчы карарында расланган. Әлеге түләү теләсә нинди максатларга (торак, автомобиль, дача һ.б. сатып алуга) тотылырга мөмкин. 2020–2022 елларда әлеге түләү 32 укытучыга, шуларның 24е Россия Федерациясенең башка төбәкләреннән авыл торак пунктларына, йә шәһәр тибындагы поселокларга, йә халкы 50 меңгә кадәр булган шәһәрләргә эшкә килгән (күченеп килгән) укытучыларга бирелде.

Республика муниципаль районнары тарафыннан, мөмкинлеккә карап, укытучыларга эш урынында кулланыла торган торак (аренда торагы) бирелә.

Моннан тыш, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә авыл торак пунктларында, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) яшәүче һәм эшләүче мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләре, җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары, мәгариф оешмаларының структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары, коммуналь хезмәтләрне куллану нормативларын исәпкә алып, Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән торак мәйданының социаль нормасы чикләрен чикләмичә, 100 процент күләмендә торак урыннар, җылылык һәм яктырту өчен түләүгә чыгымнарны компенсацияләү хокукына ия.

Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә яшь белгечләргә ярдәм итү мәсьәләсен хәл итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 20 декабрь, 1199 нчы карарында мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һөнәри белем бирү оешмасын яисә югары белем бирү мәгариф оешмасын тәмамлаган елда бирелгән квалификация нигезендә республика авыл торак пунктларында урнашкан дәүләт яисә муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларына эшкә кергән 35 яшькә кадәрге (35 яшьне кертеп) белгечләргә бер тапкыр бирелә торган пособие каралган. Пособиенең күләме һөнәри белем бирү оешмасын тәмамлаган белгечләргә 50 мең сум, югары белем бирү мәгариф оешмасын тәмамлаган белгечләргә 100 мең сум тәшкил итә.

2019 елдан башлап, әлеге пособие барлыгы 1 150 мең сумга 20 мәдәният белгеченә, шулардан 2022 елда 5 кешегә бирелде.

Республика шәһәрләре һәм районнарындагы яшьләр сәясәте учреждениеләренең яшь белгечләренә, яшьләр берләшмәләре активистларына ярдәм итү механизмы – республикада 2012 елдан башлап «Социаль ипотека» торак бирү программасы буенча үткәрелә торган «Яшьләр торак конкурсы». 2022 елда республиканың 10 муниципаль берәмлегеннән яшьләр сәясәте учреждениеләренең 49 яшь белгече фатирлар алды.

**23. Татарстан Республикасында халык сәнгать һөнәрләрен һәм кәсепләрен үстерүгә ярдәм итү һәм стимул бирү чаралары турында.**

Халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 25 маендагы 368 номерлы карары нигезендә республикада ел саен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алуга тиешле конкурс уздырыла.

Дәүләт ярдәме халык сәнгать һөнәрләре эшләнмәләрен җитештерү өчен кирәкле җиһазлар, кораллар һәм чыгым материаллары сатып алуга бәйле проектларны гамәлгә ашыруны максатчан финанслау өчен эшкуарлык субъектларына һәм физик затларга (үзмәшгуль гражданнарга) грантлар бирү юлы белән күрсәтелә.

2022 елда гомуми суммасы 5 млн сум тәшкил иткән 12 грант, шулардан 5 грант – 500 мең сум, 4 грант – 400 мең сум, 3 грант 300 мең сум күләмендә бирелде.

Хәзерге вакытта 2023–2028 елларга Татарстан Республикасында халык сәнгать һөнәрләрен һәм кәсепләрен, декоратив-гамәли сәнгатьне үстерү концепциясе эшләнде һәм килештерү процедурасын уза; республиканың социаль-икътисадый үсешендә халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре ролен арттыруга юнәлдерелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлегендә чаралар, максат юнәлешләре, принциплар һәм приоритетлар комплексыннан гыйбарәт.

**24. Татарстан Республикасында «Пушкин картасы» проектын гамәлгә ашыру турында.**

Татарстанда «Пушкин картасы» программасы буенча 14 яшьтән 22 яшькә кадәрге 337 мең потенциаль катнашучы бар, шулардан 2022 елның 31 декабренә карата Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы мәгълүматлары буенча 230 101 кеше «Мәдәният дәүләт хезмәтләре» мобиль кушымтасы ярдәмендә «Пушкин картасын» алды. 2022 елның 1 гыйнварыннан «Пушкин картасы» номиналы 5 000 сум тәшкил итә.

Россия Федерациясе төбәкләре арасында Татарстан «Пушкин картасы» белән сатып алынган билетлар саны буенча 3 нче урында тора (Мәскәү шәһәреннән һәм

Санкт-Петербург шәһәреннән кала).

«PRO.Культура.РФ» порталында «Пушкин картасы» программасында катнашучылар буларак Татарстан Республикасының 511 оешмасы теркәлгән, бу 2022 ел башы белән чагыштырганда 2 тапкырга артыграк (2022 елның 1 гыйнварына – 243 оешма).

2022 ел йомгаклары буенча республика мәдәният учреждениеләре тарафыннан театр, кино, күргәзмә, музей һәм концерт залларына барлыгы 413,8 млн сум күләмендә билетлар сатылды.

«Пушкин картасы» федераль проекты кысаларында республикада төрле юнәлештәге (вокал, хореография, халык һөнәре, актерлар осталыгы буенча) мастер-класслар, шулай ук төрле эшчәнлек тармаклары (мәдәният, медицина, саклау һәм хокук тәртибе органнары) вәкилләре белән тематик очрашулар уздырыла.

**25. Республиканың зур шәһәрләрендә яңа торак микрорайоннары территориясендә мәгариф учреждениеләре төзү перспективалары турында.**

«Мәгариф» һәм «Демография» илкүләм проектларын гамәлгә ашыру кысаларында республика муниципаль берәмлекләре заявкалары нигезендә гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмалары төзелә.

2023 елда түбәндәгеләрне төзү каралды:

9 329 урынга исәпләнгән 8 гомуми белем бирү оешмасы, шул исәптән:

Тукай муниципаль районының Шилнәбаш авылында 100 урынлык мәктәп;

Яр Чаллы шәһәрендә 2 мәктәп («Притяжение» торак комплексында – 1 501 урынлык, 34 нче микрорайонда – 1 501 урынлык);

Арча муниципаль районының Түбән Мәтәскә авылында 500 урынлык мәктәп;

Казан шәһәрендә 4 мәктәп (Сибгат Хәким урамы буенча – 1 224 урынлык, Гәрәев урамы буенча – 1 501 урынлык, «Светлая долина» торак комплексында – 1 501 урынлык, «Салават Күпере» торак комплексында – 1 501 урынлык);

1 000 урынга исәпләнгән 4 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы, шул исәптән:

Казан шәһәрендә 2 балалар бакчасы (59 нчы кварталда – 220 урынлык, 59 нчы кварталда, 2 позиция – 220 урынлык);

Тукай муниципаль районының Яңа Троицкий авылында 220 урынлык балалар бакчасы;

Яр Чаллы шәһәренең «Яшьлек» торак комплексындагы 69 нчы микрорайонында 340 урынлык балалар бакчасы;

345/165 урынлык 3 мәктәп-бакча, шул исәптән:

Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәрендә 240/120 урынлык мәктәп-бакча;

Әлки муниципаль районының Түбән Колчурино авылында 25/25 урынлык мәктәп;

Биектау муниципаль районының Коркачык авылында 80/20 урынлык мәктәп.

**26. Казан шәһәрендә Абдулла Алиш исемендәге Балалар иҗат сараена капиталь ремонт ясау перспективалары турында.**

Казан шәһәре, Галактионов урамы, 24 нче йорт адресы буенча урнашкан

«А.Алиш исемендәге Шәһәр балалар иҗат сарае» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе бинасы «Пионерлар һәм мәктәп укучылары сарае» төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты булып тора һәм Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2019 елның 9 декабрендәге 246-П номерлы боерыгы нигезендә дәүләт саклавына куелды.

2020 елның мартында Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты хезмәткәрләре тарафыннан үткәрелгән әлеге объектны тикшерү нәтиҗәләре буенча бинаның гомуми техник торышы бәяләнде, акт төзелде һәм аны саклау буенча кирәкле эшләр төрләре һәм күләмнәре билгеләнде.

Ачыкланган җимерек урыннарны, җитешсезлекләрне бетерү максатларында 2020 елда объектка карата лицензияләнгән проект оешмасы – «Татарстан махсус фәнни-реставрация идарәсе» АҖ тарафыннан аны саклау буенча эшләр башкаруга фәнни-проект документациясе эшләнде. Документациягә барлык кирәкле экспертиза уздырылды һәм килештерелде, дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсе алынды. Проект карарларында бинаны реставрацияләү, киләчәктә аны заманча файдалануга җайлаштыру каралды.

Төп бурыч – объектны саклау буенча килештерелгән проект карарларын гамәлгә ашыруга финанслар табу.

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законның 47.2 һәм 47.3 статьялары нигезендә мәдәни мирас объектын саклау эшләрен оештыру, аны карап тоту һәм тиешле техник, санитар һәм янгынга каршы хәлдә тоту чыгымнарын гамәлгә ашыру, мәдәни мирас объектын алга таба җимерүне булдырмау, шул исәптән һәлакәткә каршы эшләр башкару буенча кичектергесез чаралар күрү объект милекчесенең яки башка законлы хуҗасының бурычы булып тора.

Мәсәлән, мәдәни мирас объектын саклау эшләрен башкаруга рөхсәт алу өчен объектның хокукка иясе тарафыннан вәкаләт бирелгән, лицензияләнгән подряд оешмасына тиешле рөхсәт алу өчен административ регламент нигезендә документлар белән Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетына мөрәҗәгать итү таләп ителә.

Хәзерге вакытта мәдәни мирас объектларын саклау эшләрен башкаруга рөхсәт бирү турында гаризалар Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты адресына кермәде.

**27. Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары һәм муниципаль мәгариф оешмалары тарафыннан укулары өйдә оештырылган сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны ике тапкыр бушлай ашатуны тәэмин итү турында.**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 7 пункты нигезендә сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучылар ике тапкыр бушлай ашату белән тәэмин ителергә тиеш. Укучыларны тукландыруны оештыру мәсьәләсе белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга йөкләнә. Россия

Федерациясе субъектлары бюджетларының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән туклану белән тәэмин итү тәртибе Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан, җирле бюджетларның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән белем алучыларның – җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

Республикада дәүләт мәгариф оешмаларына карата югарыда күрсәтеп үтелгән тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 26 сентябрендәге 682 номерлы карары белән расланды.

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 1 декабрендәге Татарстан Республикасы Законы нигезендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда яшәмәгән сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучылар мондый оешмаларның гамәлгә куючылары тарафыннан ике тапкыр бушлай ашату белән тәэмин ителә. Муниципаль мәгариф оешмалары тарафыннан укулары өйдә оештырылган сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны ике тапкыр бушлай ашату белән тәэмин итү тәртибе, шул исәптән ике тапкыр бушлай ашатуны акчалата компенсация белән алмаштыру мөмкинлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә. Әлеге яңалыклар 2022 елның 12 декабрендә үз көченә керде.

Татарстан Республикасы территориясендә сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 55 учреждение (шул исәптән 2 шифаханә тибындагы учреждение) эшли, аларда 7,5 меңнән артык бала укый. Мәгариф оешмасында яшәүче балалар көненә 5 тапкыр, әлеге оешмада яшәми торган балалар 2 тапкыр ашыйлар.

Муниципаль мәгариф оешмалары тарафыннан укулары оештырылган сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучыларның туклануын оештыру һәм Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны ике тапкыр бушлай ашату белән тәэмин итү тәртибен эшләү җирле үзидарә органнары компетенциясендә булып тора.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары тарафыннан укулары оештырылган сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны ике тапкыр бушлай ашату белән тәэмин итү тәртибе проекты эшләнде. Теркәлү процедурасы тәмамланганнан соң, документ Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтында «Мәктәпләрдә сәламәтлекне саклау эшчәнлеге һәм кайнар ризык белән туклануны оештыру» бүлегенең «Норматив-хокукый актлар» блогында бастырып чыгарылачак.

## Иҗтимагый иминлек

### 28. Татарстан Республикасында, шул исәптән Казан шәһәрендә гражданнарны, шулай ук аларның берләшмәләрен җәмәгать тәртибен саклауда катнашуга җәлеп итү буенча күрелә торган чаралар турында.

Республика муниципаль берәмлекләре территориясендә җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә эчке эшләр органнарына ирекле халык дружиналары актив ярдәм

күрсәтә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 18 апрель, б-702 нче боерыгы белән Татарстанда халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча республика штабы төзелде. Республиканың барлык муниципаль берәмлекләрендә дә шундый ук штаблар булдырылды, аларның башлыклары итеп башкарма комитетлар җитәкчеләре яки аларның урынбасарлары билгеләнде.

«2014–2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында халык дружиналары эшен оештыруга ел саен 8 040,4 мең сум акча каралды (эшчәнлекне матди-техник тәэмин итүгә, халык дружиначыларын шәхси иминләштерүгә, матди стимул бирүгә).

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 17 август, 603 нче карары белән «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» республика премиясе турында нигезләмә расланды (3 категория: 5әр мең сумнан 30 премия, 20шәр мең сумнан 10 премия, 50шәр мең сумнан 3 премия каралды).

2023 елның 1 гыйнварына республикада җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итүгә 1 459 халык дружинасы һәм хокук саклау юнәлешендәге бер иҗтимагый берләшмә җәлеп ителә, аларда катнашучыларның гомуми саны 20 180 кеше тәшкил итә. Казан шәһәрендә 268 халык дружинасы һәм хокук саклау юнәлешендәге бер иҗтимагый берләшмә эшли, катнашучыларның гомуми саны – 1 700 кеше.

2022 ел йомгаклары буенча тәүлеккә уртача 340 дружиначы кизү торуга чыкты, алар тарафыннан 101 җинаятьне ачуда һәм 3 754 административ хокук бозуны ачыклауда полициягә ярдәм күрсәтелде. Казан шәһәрендә полициягә 12 җинаятьне ачуда һәм 90 административ хокук бозуны ачыклауда булышлык ителде.

Иҗтимагый иминлекне тәэмин итүдә полициягә ишегалды һәм авыл дружиналары әгъзалары зур ярдәм күрсәтә. 2022 елда алар эчке эшләр органнары белән берлектә үткәрелә торган 3 996 рейдта катнашты, полициянең участок вәкаләтле вәкилләре белән профилактик тикшерү кысаларында 11 800 дән артык адреста булды, эчке эшләр органнарында профилактик исәптә торучы 6 914 кешене тикшерде, 63 җинаятьне ачуда, 2 459 административ закон бозуны ачыклауда һәм туктатуда катнашты.

2023 елның 1 гыйнварына республика территориясендә хокук саклау юнәлешендәге 1 163 яшьләр берләшмәсе үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра, аларда катнашучыларның гомуми саны 14 яшьтән 30 яшькә кадәр 15 135 кеше тәшкил итә. Яшьләр берләшмәләре эшчәнлегенең координаторы – «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр формированиеләре республика үзәге» ДБУ. Хәрәкәттә катнашучылар белән үткәрелә торган дәресләрнең төп юнәлешләре – хокук һәм хәрби әзерлек нигезләренә тарту, коллективта үз-үзеңне тоту нормалары, лидерлык сыйфатларын тәрбияләү, иҗади сәләтләрне үстерү, укучылар арасында хокук бозуларны профилактикалау чараларын үткәрүдә катнашу. Хәрәкәттә катнашучы балигъ булган затлар, санап үтелгән чаралардан башка, җәмәгать

тәртибен саклауда һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итүдә катнаша, хокук саклау органнарына административ хокук бозуларны һәм җинаятьләрне ачыклауда ярдәм күрсәтә.

2022 елда «Форпост» яшьләр берләшмәләре әгъзалары тарафыннан полициягә 112 җинаятьне ачуда һәм 861 административ хокук бозуны ачыклауда ярдәм күрсәтелде.

**29. Татарстан Республикасында юл-транспорт һәлакәтләрен һәм юлларда үлүчеләр санын киметү буенча күрелә торган чаралар турында.**

Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән финанслана торган юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «2014–2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасының «2014–2025 елларга юл хәрәкәте иминлеген арттыру» ярдәмче программасы кысаларында гамәлгә ашырыла. Аның гомуми финанслау күләме 2022 елда 2 547,3 млн сум тәшкил итте (акча тулы күләмдә үзләштерелде). Программаны гамәлгә ашыру барышында түбәндәге чаралар үткәрелде:

Казан шәһәре һәм Яр Чаллы шәһәренең юл хәрәкәте белән идарә итүнең адаптив автоматлаштырылган системасы (АСУД) эшләве һәм аны үстерү тәэмин ителде;

Казан шәһәренең урам-юл челтәрендә 1 800 дән артык юл билгесе урнаштырылды;

11 светофор объекты урнаштырылды;

18 җәяүлеләр юл аша чыгу урыны өстәмә яктырту, ясалма юл тигезсезлекләре, Т.7 светофорлары, эчтән яктыртыла торган һәм светодиодлы индикация белән юл билгеләре белән җиһазландырылды.

Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуны фотога һәм видеога төшерү системаларын үстерү дәвам итә. Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуны фотога һәм видеога төшерә торган 57 стационар комплекс сатып алынды һәм файдалануга тапшырылды. 2023 елның 1 февраленә барлыгы юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуны фотога һәм видеога төшерә һәм автомат режимда эшли торган 927 комплекс кулланыла, шулардан 734е – стационар, 166сы – күчмә һәм 27се – мобиль.

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (алга таба – ЭЭМ ЮХИДИ ТР буенча идарәсе) белән берлектә, юл-транспорт һәлакәтләренә анализ ясала, аларны килеп чыгу сәбәпләре ачыклана, Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында ачыкланган һәлакәтләр була торган куркыныч участокларны бетерү чаралары эшләнә.

Әйтик, 2021 елда булган юл-транспорт һәлакәтләре сәбәпләрен анализлау нәтиҗәләре буенча, республиканың гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында 167 куркыныч участок, шул исәптән: юл-транспорт һәлакәтләре тупланган 68 урын, 22 потенциаль куркыныч участок, 17 авария зонасы, бер генә тапкыр юл-транспорт һәлакәте булган һәм авыр зыян салынган 60 участок

билгеләнде.

Шул ук вакытта төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларында юл-транспорт һәлакәтләре тупланган 6 урын, 1 авария зонасы, 1 потенциаль куркыныч участок, бер генә тапкыр юл-транспорт һәлакәте булган 14 участок ачыкланды.

2022 елда һәлакәтләр була торган куркыныч участокларны бетерү буенча эшләнгән һәм расланган чаралар тулы күләмдә гамәлгә ашырылды.

2022 елга юл эшләре планын гамәлгә ашыру кысаларында төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларында юл хәрәкәте иминлеге дәрәҗәсен арттыру максатларында түбәндәге чаралар эшләнде һәм гамәлгә ашырылды:

30 муниципаль берәмлек территориясендә 91 ясалма тигезсезлек ясалды;

транспорт чараларының каршыга килә торган хәрәкәт полосасына чыгуына бәйле һәлакәтләрне булдырмау максатларында, шулай ук җәяүлеләрнең машиналар йөри торган юл өлешенә чыгуын чикләү өчен барьер тибындагы 31,4 км металл киртә, шул исәптән транспорт чаралары хәрәкәтенең капма-каршы агымнарын аера торган 27,6 км киртә урнаштырылды һәм алыштырылды;

торак пунктлар аша уза торган юлларның 78,8 км гомуми озынлыктагы 50 участогында ясалма яктырткычлар куелды.

Моннан тыш, юл эшләре программасы кысаларында 45 мәктәп автобусы маршрутында машиналар йөри торган юл өлеше норматив хәлгә китерелде.

Юл хәрәкәте иминлеген пропагандалау Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе эшчәнлегенең төп юнәлешләреннән берсе булып тора. Транспорт мохитендә халыкның барлык яшь төркемнәрен үз эченә алган имин тәртип кагыйдәләрен өйрәтү буенча системалы эш алып барыла.

Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан 2022 елда «Татарстан - Яңа Гасыр» сәүдә-күңел ачу комплексы редакциясе белән үзара хезмәттәшлектә «Сырлы зебра» юл хәрәкәте иминлеге буенча балалар өчен танып-белү телепрограммасының 24 чыгарылышы булды. Беренче медицина ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасының белем бирү учреждениеләренә 4 робот-тренажер, 5 автосыйныф, 2 база автошәһәрчеге сатып алынган һәм тапшырылган. 80 меңнән артык яктылык кайтаргыч җайланмалар таратылган. Картинг хәрәкәтен үстерү хезмәтләре күрсәтелде. KazanDigitalWeek-2022 халыкара форумы, «Игътибар - Балалар», «Имин Зебра», «Бала - төп пассажир», «Күзгә ташланучан бул» акцияләре үткәрелде.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе хезмәткәрләре планлы тәртиптә куркынычсызлык минутлыгын уздыруда һәм «Кышкы каникуллар», «Язгы каникуллар», «Игътибар - балалар!», «Көзге каникуллар» дигән профилактик чараларда актив катнаштылар.

Республика юлларында закон тыңлаучан тәртип формалаштыру һәм юл йөрү кагыйдәләрен тупас бозуларга гражданнарның түземсезлеген булдыру кысаларында республиканың һәр муниципаль берәмлегендә төзелгән Telegram-каналлар ярдәмендә гражданнардан аноним мәгълүмат алуның яңа форматы гамәлгә ашырылды. Бүгенге көндә Telegram-каналларның 10 391 язылучысы бар. 2022 елда Telegram-канал ярдәмендә республикада исерек хәлдә транспорт чаралары белән идарә итүче 95 машина йөртүче тоткарланган.

Telegram-каналлардан тыш, юл хәрәкәте куркынычсызлыгы линиясе буенча

140 кешедән торган халык дружинасы бар.

Республикада гражданнар тарафыннан «Халык инспекторы» мәгълүмат системасы актив кулланыла. Ул эшли башлаганнан бирле 23 меңнән артык кулланучы теркәлгән һәм 195 меңнән артык тапкыр мобиль кушымта йөкләнгән. Хәзерге вакытта система юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуның 17 категориясе буенча мөрәҗәгатьләр кабул итә. 2022 елда юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозу турында ТР буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсенең вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлдәге законнар нигезендә административ хокук бозулар турында 20 901 эш кузгатылган.

Планлы эш нәтиҗәсендә юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булучылар санының исәп-хисап максатчан күрсәткече 2022 ел нәтиҗәләре буенча (321 кеше) арттырылмаган (фактта 306 кеше булган). Социаль һәм транспорт куркынычы күрсәткечләре артмаган.

**30. Торак йортларда һәм гражданнар күпләп була торган урыннарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча Татарстан Республикасында күрелә торган чаралар турында.**

Торак йортларда һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү кысаларында Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча Баш идарәсе тарафыннан көн саен 944 профилактик төркем эше оештырылды, аларның вәкилләре 2022 елда 569 782 тапкыр шәхси йорт биләмәләрендә булды, 33 708 тапкыр - күпфатирлы торак йортларда булды.

1 036 меңнән артык граждан янгын куркынычсызлыгы чаралары турында кисәтелгән, янгын куркынычсызлыгы һәм көнкүрештә үз-үзеңне тоту чаралары турында 1 036 меңнән артык белешмәлек һәм листовка таратылды, 294 меңнән артык кеше катнашында 12 829 халык җыены уздырылды. Радиода 1 557 чыгыш оештырылган, 279 - телевидениедә, басма массакүләм мәгълүмат чараларында 1 688 профилактик мәкалә һәм язмалар бастырылган.

Янгынның иртә стадиясендә аны вакытында ачыклауны тәэмин итү, янучы йорттан (фатирдан) анды яшәүчеләрне эвакуацияләү өчен аларга янгын турында хәбәр итү максатларында Россия Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе тарафыннан социаль ярдәмгә мохтаҗ гражданнар (4 һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче күпбалалы гаиләләр, балигъ булмаган балалары булган социаль куркыныч хәлдәге гаиләләр, 70 һәм аннан да күбрәк яшьтәге ялгыз яшәүче гражданнар) яши торган йортларга (фатирларга) автоном янгын сүндерү хәбәрчеләре белән тәэмин итү эше оештырылды.

2022 елда төрле финанслау чыганаклары хисабына 19 067 йорт биләмәсендә 52 220 автоном янгын сүндерү хәбәрчесе урнаштырылган. 2016 елдан 2022 елга кадәр барлыгы 131 969 йорт биләмәсендә 397 024 автоном янгын сүндерү хәбәрчесе урнаштырылган.

Әлеге автоном янгын хәбәрчеләре үзләренең нәтиҗәлелеген исбатлады. Әйтик, 2016 – 2022 елларда торак йортларда (фатирларда) булган 101 янгын очрагында янгын хәбәрчеләре эшләве аркасында йортта яшәүчеләргә янгын чыгу турында үз вакытында хәбәр ителгән, бу 262 кешенең (шул исәптән 85 бала)

гомерен коткарган. 2022 елда 16 очрак теркәлгән, 91 кеше коткарылган (шул исәптән 20 бала).

**31. Татарстан Республикасында мәгариф учреждениеләрендә балаларның куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны киметү буенча көрәлә торган чаралар турында.**

Хәзерге вакытта мәгариф объектларында террорчылыктан сакланышны тәэмин итү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы объектларының (территорияләренең) һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы эшчәнлеге өлкәсенә караган объектларның (территорияләрнең) террорчылыктан сакланышына карата таләпләрне һәм әлеге объектларның (территорияләрнең) иминлек паспорты формасын раслау турында» 2019 елның 2 августындагы 1006 номерлы карары (алга таба – 1006 номерлы карар) белән регламентлана.

Татарстанда 3 317 белем бирү оешмасы эшли, алар 1006 номерлы карар нигезендә үз эченә куркынычсызлык паспорты булган 3 678 объектны.

Республика җитәкчелеге карары буенча муниципаль, дәүләт мәгариф оешмалары биналарын ремонтлау һәм террорчылыктан саклану системалары белән җиһазлау мәгариф оешмалары биналарын капиталь ремонтлау буенча республика программасын гамәлгә ашыру кысаларында аерым йөкләмәләр һәм бюджеттан тыш финанслау буенча республика финанславы исәбеннән, шулай ук муниципаль берәмлекләр бюджетлары исәбеннән гамәлгә ашырыла. Программага кертү өчен объектлар исемлеге муниципаль берәмлекләр тәкъдимнәре нигезендә төзелә. Эшләрнең төрләре һәм күләмнәре мәгариф оешмаларын гамәлгә куючылар тарафыннан билгеләнә.

2022 елда мәгариф оешмаларын капиталь ремонтлау программасына ведомствога караган 18 дәүләт мәгариф оешмасы кертелгән (гомуми суммасы 65 900,79 мең сум), аларның биналарында террорчылыкка каршы саклануның техник чаралары белән тәэмин итү эшләре башкарылган.

2022 елда мәгариф учреждениеләрен террорчылыкка каршы яклауга түбәндәге акчалар бүлеп бирелде:

Казан шәһәрендә: 1 катта саклык урыны урнаштыру, анда видеокүзәтү системалары, саклау сигнализациясе һәм тревога хәбәрләрен тапшыру чараларын урнаштыру өчен - 33 544,9 мең сум, учреждение территориясенә керү юлында контроль-үткәрү пунктын урнаштыру өчен - 68 036,2 мең сум, территория киртәләрен, капка, коймаларны урнаштыру, ремонтлау өчен - 996 624,2 мең сум;

Чаллыда: 18 мәгариф оешмасында киртәләрне алмаштыруга - 46 млн сум, өстәмә видеокамералар урнаштыруга - 1 881 мең сум, 18 урта гомуми белем бирү мәктәбендә сак постлары урнаштыруга - 3 577 мең сум;

Чистай шәһәрендә видеокүзәтү системаларын, контроль-үткәрү пункты, коймалар, тышкы яктырту, металл эзләү системаларын урнаштыруга - 10 млн сум;

Әлки районында сөйләм хәбәр итү җайланмасы монтажына - 894 мең сум;

Әтнә районында видеокүзәтү, домофоннар, коймалар урнаштыру, периметр буенча яктырту җайланмасына - 1 150 мең сум;

Югары Ослан авылында киртәләр урнаштыруга, тревога сигнализациясе

төймәләрен монтажлауга (алга таба - ТСТ) - 3 565 мең сум;

Яңа Чишмә районында тышкы яктырту җиһазлары монтажына - 360 мең сум;

Сарман районында видеокүзәтү системасын урнаштыруга - 360 мең сум;

Чирмешән районында видеокүзәтү, контроль-үткәрү пункты, киртәләр, тышкы яктырту урнаштыру, металл детекторлары сатып алу өчен - 1 173 мең сум;

Спас районында сак сигнализациясен, керү мөмкинлеген контрольдә тоту системасын монтажлауга - 5 500 мең сум;

Питрәч районында хәбәр итү һәм керү мөмкинлеге белән идарә итү системаларын, видеокүзәтү системаларын урнаштыруга - 3 754 мең сум;

Алабуга районында хәбәр итү һәм керү мөмкинлеге белән идарә итү системаларын урнаштыруга, киртәләрне ремонтлауга - 508 мең сум;

Әтнә районында видеокүзәтү системасын, тышкы яктырту, коймалар урнаштыруга - 661 мең сум;

Нурлат районында контроль-үткәрү пункты системасын модернизацияләүгә, коймалар, видеокүзәтү урнаштыруга - 2 055 мең сум.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 23 ноябрь, 1112 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмалары объектларының (территорияләренең) террорчылыктан сакланышын тәэмин итүгә бәйле хезмәт күрсәтүләрне хосусый каравыл оешмаларыннан сатып алуны гамәлгә ашырганда, әлеге хезмәт күрсәтүләр кыйммәте нормативларын билгеләү тәртибе турындагы методик тәкъдимнамәләргә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 ел, 7 май, 423 нче карары нигезендә сак объектларының даими саклау хезмәтләренең бер сәгатенә норматив бәясе Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында һәм Татарстан Республикасы муниципаль мәгариф оешмаларында финанслауның башка чыганаклары булганда арттырылырга мөмкин.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Объектларның (территорияләрнең) террорчылыкка каршы якланганлыгын тәэмин итү өлкәсендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 5 мартындагы 289 номерлы карары нигезендә, күп кенә мәгариф оешмалары объектларны яңадан коралландыру эшләрен башкарды - сак постларын куюны таләп итми торган түбәнрәк дәрәҗәдә куркыныч категориясенә үзгәрттеләр, бу үз чиратында бюджет акчаларының шактый янга калуына китерә.

Шул ук вакытта экономия суммасы кысаларында мәгариф объектларының террорчылыкка каршы якланганлыгын көчәйтү буенча башка чаралар уздыру өчен кирәкле финанс чараларына ихтыяҗ анализланды: саклау сигнализациясе, видеокүзәтү, сөйләм хәбәр итү системалары, керү мөмкинлеген контрольдә тоту һәм идарә итү системалары, периметраль киртә урнаштыру һәм башкалар.

Муниципаль берәмлекләрдән һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының ведомство оешмаларыннан кергән тәкъдимнәр нигезендә, күрсәтелгән максатларга финанслау ихтыяҗы 259 613,3 мең сум тәшкил итә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан инструктив һәм методик тәкъдимнәр, террорчылыкка каршы куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча бертип документлар үрнәкләре эшләнә һәм мәгариф белән

идарә итүнең муниципаль органнары һәм мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренә җиткерелә, күрсәтелгән материаллар Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

**32. Гадәттән тыш хәлләр очрагында халыкны яклауга юнәлдерелгән чаралар турында. Локаль хәбәр итү системаларын торгызуга юнәлдерелгән чаралар турында.**

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә республикада гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль өстәмә системасы (алга таба - ГТХТС) төзелде һәм нәтиҗәле эшли, ул гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының состав өлеше булып тора.

ГТХТС федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарының, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның идарә органнарын, көчләрен һәм чараларын берләштерә, алар вәкаләтләренә халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, шул исәптән су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре керә. ГТХТСның барлык дәрәҗәләрендә, шул исәптән җирле звенолар дәрәҗәсендә, тиешле идарә органнары булдырылган:

координацияләү органнары - гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссияләре;

көндәлек идарә органнары - Россия Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының ТР буенча Баш идарәсенең Кризислы хәлләрдә идарә итү үзәге, муниципаль берәмлекләрнең бердәм кизү-диспетчерлык хезмәтләре.

Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 8 сентябрендәге ПУ-511 номерлы Указы белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, республика оешмалары һәм иҗтимагый берләшмәләре гамәлләренең килештерелүен тәэмин итү өчен гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасының Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе (алга таба - ГТХһЯК) төзелде. Әлеге комиссия рәисе - Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н.Миңнеханов, даими эшләүче оператив штаб җитәкчесе - Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе башлыгы Р.З.Хәбибуллин. 2022 елда комиссиянең 20 утырышы уздырылды, 7 карар һәм 30 боерык кабул ителде. Уздырыла торган чаралар һәм беркетмә карарлары республикада кирәкле иминлек дәрәҗәсен сакларга мөмкинлек бирә. Мондый комиссияләр Татарстан Республикасының барлык муниципаль берәмлекләрендә дә төзелде.

Штат нигезендә 45 бердәм кизү-диспетчерлык хезмәте (алга таба - БКДХ)

булдырылган һәм эшли. БКДХ диспетчерлык составы Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча укыту-методика үзәге базасында белем ала. БКДХ техник җиһазлау Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы таләпләренә туры китереп башкарылды, ул аларга йөкләнгән бурычларны һәм функцияләрне үтәү өчен куела. БКДХ кирәкле оргтехника, видео-конференц-элемтә системалары һәм телефон аша сөйләшүләр яздыру аппаратурасы белән җиһазландырылган. Муниципаль берәмлекләрнең барлык БКДХ заманча элемтә каналлары белән җиһазландырылган, алар шулай ук «Имин шәһәр» АПК системасы эшендә кулланыла. Муниципаль берәмлекләрнең БКДХ гомуми җитәкчелеген Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча Баш идарәсенең Кризис ситуацияләрендә идарә үзәге ярдәме белән җирле үзидарә органнары җитәкчеләре башкара.

Гадәттән тыш хәлләргә һәм һәлакәтләргә оператив җавап бирүне оештыру өчен «Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасының эзләү-коткару хезмәте» ДКУ төзелде, гомуми саны 270 кеше тәшкил итә.

Республика эзләү-коткару хезмәте (алга таба - ЭКХ) 7 зональ отряд аша территориаль принцип буенча үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра. Хезмәтне матди-техник яктан тәэмин итү аңа куелган бурычларны тулы күләмдә башкарырга мөмкинлек бирә. Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасының ЭКХ карап тотуга 2023 елга бирелгән финанс чараларының гомуми күләме 222 млн. сумнан артык тәшкил итә.

Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен республикада финанс һәм матди ресурсларның резервлары булдырылды. Финанс резервы күләме (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондын исәпкә алып) 6 678,8 млн сум тәшкил итә, материаль ресурслар резервы күләме - 150 221мең сум.

Республикада 112 бердәм номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләрне чакыру системасын үстерү эше дәвам итте. 2014 елдан бу максатларда «Ашыгыч чакырулар хезмәте – 112» Татарстан Республикасы ДБУ эшли. Республиканың бөтен территориясендә барлык мобиль һәм билгеләп куелган элемтә операторлары абонентларыннан 112 номеры буенча чакыруларны кабул итү ике чакыруларны эшкәртү үзәгендә – Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләрендә алып барыла. Ике үзәккә йөкләнеш тигез бүленә. Шул ук вакытта бер үзәк сафтан чыккан очракта, икенчесе үз өстенә тулы йөкләнешне алырга мөмкин. 112 хезмәтенең штат саны 113 кеше тәшкил итә, шул исәптән 94 экстрен чакыруларны кабул итү һәм эшкәртү белгече (шул исәптән, ишетү һәм сөйләм бозылган абонентлардан керә торган чакыруларны кабул итү һәм эшкәртү өчен рус ым телен белүче 6 белгеч) һәм 6 психолог.

Система-112гә Татарстанның бөтен территориясен 100% колачлаган барлык муниципаль берәмлекләр дә тоташтырылган. Муниципаль районнарның гамәлдәге барлык ашыгыч оператив хезмәтләр һәм БКДХ «ГЛОНАСС+112» БДИС (400 АРМ) автоматлаштырылган эш урыннары белән җиһазландырылган. Система Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүмати системалары белән интеграцияләнгән.

Закон таләпләре нигезендә һәм бирелгән вәкаләтләр кысаларында Татарстан

Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы тарафыннан халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру эше оештырылды.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 10 мартындагы 336 номерлы карары белән билгеләнгән мораторий кысаларында контроль буенча планлы чаралар башкарылмый. Планнан тыш тикшерүләр бары тик прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырыла. Шул ук вакытта 2022 елга расланган профилактика программасы нигезендә профилактика визитлары планлаштырылган һәм хәзерге вакытта гамәлгә ашырыла, аларның төп максаты - халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге законнарның мәҗбүри таләпләрен үтәгәндә юридик затлар тарафыннан хокук бозуларны кисәтү һәм булдырмау.

Гамәлдәге хәбәр итү системасын модернизацияләү өчен 2022 елда аны реконструкцияләү проектын эшләү буенча проект-тикшерү эшләре башкарылды. 2022 елның 27 декабрендә «Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр проблемалары буенча бөтенроссия фәнни-тикшеренү институты, федераль фән һәм югары технологияләр үзәге» ФДБУ 2022 елның 23 декабрендәге уңай эксперт бәяләмәсе белән Үзәкләштерелгән хәбәр итүнең төбәк автоматлаштырылган системасын реконструкцияләү проекты алынды.

Хәзерге вакытта проектны үтәүгә әзерлек эшләре алып барыла, ул республика территориясендә урнашкан локаль хәбәр итү системаларын (алга таба - ЛХС) кертеп Үзәкләштерелгән хәбәр итүнең төбәк автоматлаштырылган системасы (алга таба - ҮХТАС) һәм үзәкләштерелгән хәбәр итүнең муниципаль автоматлаштырылган системалары (алга таба - ҮХМАС) белән идарәнең үзәкләштерелмәгән системасын гамәлгә ашыруны күздә тота, бу тулаем алганда халыкка автомат режимда гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы һәм фактлары турында үз вакытында хәбәр итәргә һәм мәгълүмат бирергә мөмкинлек бирәчәк.

Татарстанда 662 куркыныч җитештерү объекты теркәлгән, аларда локаль хәбәр итү системалары булдырырга кирәк, шуларның 227 се - I классны куркыныч объекты, 433 е II классны куркыныч объекты һәм 2 гадәттән тыш югары куркыныч һәм югары куркыныч гидротехник корылма.

Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы тарафыннан Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча Баш идарәсе белән хезмәттәшлектә Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсеннән алынган мәгълүматларга нигезләнеп, ҮХТАС һәм ҮХМАС белән мәҗбүри интеграцияләү өчен ГТХһЯКда әлеге объектлар исемлеген актуальләштерү эше алып барыла.

Хәзерге вакытта 147 локаль хәбәр итү системасы булдырылган, шуларның 87 - I классны куркыныч, 58 - II классны куркыныч, 2 гадәттән тыш югары куркыныч һәм югары куркыныч гидротехник корылма.

Моннан тыш, ҮХТАС һәм ҮХМАСка 53 ЛХС интеграцияләнгән, бу булдырылганнарның гомуми санының 36,1% ын тәшкил итә. Хәзерге вакытта магистраль нефть үткәргечләр участокларында («Транснефть - Прикамье» АҖ),

промысел торбаүткәргечләр системасында, насос станцияләре мәйданчыкларында (В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАЖ) һәм башка линия объектларында ЛХС интеграцияләнмәгән.

## Экология

**33. «Терлекләр белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законны хайваннар өчен приютлар булдыру өлешендә үтәү барышы турында.**

Хуҗасыз хайваннарны тоту өчен республикада 18 приют бар, шуларның 16 сы - шәхси һәм 2 се - муниципаль. Хайваннарны тоту урыннарының гомуми саны 3,5 мең башка җитә.

Татарстан Республикасы Рәисенең 2021 елның 3 ноябрендәге 54990-МР йөкләмәсе нигезендә, хайваннар өчен 250 урынлык (400 урынга кадәр киңәйтү мөмкинлеге белән) бертип муниципальара приют төзелешенә 2,3 млн сумлык проект-смета документациясе эшләнде.

«Чаллы шәһәрендә хайваннар өчен муниципальара приют төзү» капиталь төзелеш объектын проектлауга эшләнгән техник бирем нигезендә «Татинвестгражданпроект» баш территориаль проект-эзләнү, фәнни-җитештерү фирмасы» ДУП югарыда күрсәтелгән объектны проектлауны тәмамлый.

Алга таба проект экспертиза уздыру өчен «Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәяләр билгеләү идарәсенә» җибәреләчәк.

## Җирле үзидарә мәсьәләләре

**34. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән инициатив проектларны гамәлгә ашыру перспективалары турында.**

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча гражданнарның инициативаларына дәүләт ярдәме гражданнарның үзара салым механизмын гамәлгә ашыру кысаларында гамәлгә ашырыла. Гражданнар үзара салым кертү мәсьәләләре буенча җыеннарда (референдумнарда) шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә туры килә торган чаралар кысаларында акчаларны тоту юнәлешләрен үзләре билгели.

Муниципаль берәмлекләрне социаль-икътисадый үсеш дәрәҗәсен һәм халыкның тормыш сыйфатын күтәрүгә стимуллаштыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе расланды.

Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган башка бюджетара трансфертларның түбәндәге күләмнәре билгеләнде:

4 сум (муниципаль берәмлек бюджетына кергән гражданнарның үзара салым акчасының 1 сумына) - республика муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән авыл җирлекләре һәм шәһәр җирлекләре өчен;

3 сум - республика муниципаль районнарының административ үзәкләре булган шәһәр җирлекләре өчен («Әлмәт шәһәре», «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлекләреннән тыш), шулай ук «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге өчен;

2 сум - Түбән Кама муниципаль районының «Әлмәт шәһәре», «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлекләре, Казан һәм Чаллы шәһәр округлары өчен.

2014 - 2022 елларда Татарстан Республикасы бюджетыннан гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп башкарыла торган чыгымнарны уртак финанслау максатларында 7 812,9 млн сум (2022 елда - 1 352,1 млн сум) бюджетара трансфертлар бүлеп бирелде. 2013 елда гражданнар тарафыннан җыелган үзара салым чаралары күләме - 2022 елның 9 аена 1 972,43 млн сум тәшкил иткән, шул исәптән 2022 елның 9 аена - 345,66 млн сум.

Акчалар нигездә юл эшләренә, күмү урыннарын карап тотуга, җирлекләрнең территорияләрен төзекләндерүгә, урамнарны яктырту һәм карап тотуга, җирлекләр чикләрендә су белән тәэмин итүне оештыруга, һәйкәлләр төзүгә һәм ремонтлауга, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә гражданнарның үзара салымын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган бюджетара трансфертлар бирү өчен ел саен 1 352 млн сум күләмендә акча каралган.

**35. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне цифрлаштыру турында.**

Бүген Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы гражданнарның төрле тормыш хәлләрен хәл итү өчен электрон дәүләт хезмәтләрен һәм сервисларны берләштерә. Алар арасында иң таләп ителгәне - табибка кабул итүгә язылу, ТКХ хезмәтләре өчен түләү, газ белән тәэмин итү һәм техник хезмәт күрсәтү хезмәтләре өчен түләү, газ исәпләү приборлары күрсәткечләрен бирү, штрафлар түләү һ.б.

2022 елда Татарстан Республикасы 7 критерий нигезендә төзелә торган цифрлы трансформация рейтингы лидеры булды, алар арасында социаль әһәмияткә ия хезмәтләрне электрон рәвешкә күчерү дә бар.

Россия субъектларыннан беренче булып республика 2022 елда барлык кирәкле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвешкә күчерүне тулысынча тәгәлләде. Дәүләт хезмәтләре төбәк порталында барлыгы 319 дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтелгән, шуларның 114е - дәүләт хезмәтләре порталында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә - 132, бу исә кәгазь документациясен курьер белән китерүдән баш тартырга мөмкинлек бирде.

Хезмәт күрсәтүләрне электрон рәвештә эшләүне һәм аларны күрсәтүне оптимальләштерү өчен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең гамәли платформасы

эшләнде һәм файдалануга кертелде. Хезмәтне электрон рәвешкә күчерү вакытын өч айдан 5-7 көнгә кадәр кыскарттылар. Дәүләт хезмәтләре гражданнар өчен аңлаешлырак булды, ә аларны күрсәтү процессын порталдагы шәхси кабинетта күзәтергә мөмкин. Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар җитәкчеләре хезмәтләр күрсәтү сыйфатын һәм эшкәртелә торган гаризалар санын күзәтә ала. Бүгенге көндә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең гамәли платформасында 140 меңнән артык гариза бирелгән, 3 800 кулланучы - хезмәт күрсәтүләр буенча башкаручы теркәлгән.

Татарстанда һәр муниципаль районда һәм шәһәр округында «Минем документлар» 61 КФҮ эшли, шул исәптән:

Казан шәһәрендә күпфункцияле үзәк кабул итүнең 12 офисы;

Чаллы шәһәрендә 3 офис;

Түбән Кама муниципаль районындагы 4 офис.

Күпфункцияле үзәкләр үсешләрен дәвам итә, шул ук вакытта гражданнар дәүләт белән максималь уңайлы форматта үзара хезмәттәшлекнең бердәнбер пункты булып тора. Барлык күпфункцияле үзәкләр дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең 287 төрен тәкъдим итә, шул исәптән хезмәтләр күрсәтү мәсьәләләре буенча консультацияләр дә. Көн саен «Минем документлар» күпфункцияле үзәктә республика буенча 14 меңгә якын граждан була. 2022 елда күпфункцияле үзәктә 6 055 меңнән артык хезмәт күрсәтелгән.

2022 елда Татарстан Республикасы бюджетына кергән дәүләт пошлинасы суммасы (50 %), федераль хакимият органнарының күпфункцияле үзәк аша хезмәт күрсәтүенә бәйле рәвештә, 594,3 млн сум тәшкил итте.

2022 елда «КФҮ» ДБУ Татарстан Республикасының барлык муниципаль районнары белән муниципаль хезмәтләрнең бертип төрләрен документларны кәгазь чыганакларда муниципаль органнарга тапшырмыйча, күпфункцияле үзәкләрнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең гамәли платформасын күрү аша электрон рәвештә күрсәтү максатларында үзара хезмәттәшлек турында килешүләр төзелде.

## 36. Муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү чаралары турында.

Республикада укытуның заманча ысулларын кулланып һәм республика һәм Россия экспертларын җәлеп итеп, дәүләт граждан хезмәткәрләрен һәм муниципаль хезмәткәрләрне һөнәри үстерүне оештыру буенча системалы эш алып барыла. Һөнәри үстерү чараларын гамәлгә ашыру «2014–2024 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасы кысаларында гамәлгә ашырыла, анда тиешле финанслау каралган.

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре белән беррәттән, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һөнәри үсеше системалы нигездә гамәлгә ашырыла. Уку контурына муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыклары, аларның урынбасарлары, башкарма комитетлар җитәкчеләре, аларның тармак мәсьәләләре буенча урынбасарлары, муниципаль берәмлекләр советлары аппаратлары җитәкчеләре, авыл җирлекләре башлыклары һәм

секретарьлары, линия җитәкчеләре, белгечләр кертелгән.

Цифрлы трансформация өчен җаваплы барлык муниципаль идарәчеләр (муниципаль районнар башлыклары, башкарма комитетлар җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары) «Сбербанк корпоратив университеты» өстәмә һөнәри белем бирү оешмасы (СБЕР Университет) әзерләгән «Цифрлы трансформация идарәсе» махсус белем бирү программасы буенча укулар узды.

Уртача звено җитәкчеләре һәм җирле үзидарә органнары белгечләре өчен ел саен җирле үзидарә органнары тәкъдимнәре нигезендә, шулай ук «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе Съезды йомгаклары буенча кабул ителә торган карарлар нәтиҗәләре буенча һөнәри үсешнең календарь планы төзелә, ул «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе белән килештерелә һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан раслана.

Укытуның төп мәйданчыгы - Казан (Идел буе) федераль университетының Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе.

2022 елда дәүләт заказы кысаларында хезмәткәрләрне һөнәри үстерү чараларында 3 602 муниципаль хезмәткәр һәм 417 муниципаль учреждение хезмәткәре катнашты.

Квалификация күтәрү программалары буенча 2 172 кеше укыды, шул исәптән 252 муниципаль учреждение хезмәткәре.

Универсаль (сыгылмалы) күнекмәләрне (командалылыкны, клиент күзәтүчәнлеген, стresска чыдамлыгын, аралашучанлыкны, аналитик, креатив фикерләүне һ.б.) үстерүгә юнәлтелгән тренингларда 1 029 муниципаль хезмәткәр, шул исәптән 129 муниципаль учреждение хезмәткәре укый.

Муниципаль берәмлекләрдән 700 дән артык кеше (муниципаль учреждениеләрнең 709 муниципаль хезмәткәре һәм 36 хезмәткәре) тармак юнәлеше буенча кыска сроклы семинарларда (милли максатлар һәм милли проектлар, ТКХ идарәсе, халыкны социаль яклау һәм социаль тәэмин итү, цифрлы мәгълүмат куркынычсызлыгы, террорчылыкны профилактикалау, хуҗалык кенәгәләрен алып бару, электрон хезмәт кенәгәләрен алып бару һ.б.) катнашты, алар күбесенчә Казан шәһәренә килмичә, дистанцион форматта оештырылды.

2022 елда беренче тапкыр муниципаль хезмәткә килгән 69 муниципаль хезмәткәр “Яшь хезмәткәр мәктәбе” программасы буенча укулар узды.

Республиканың кайбер министрлыклары, ведомстволары һәм муниципалитетларының стажировка программаларында (барлыгы 20 стажировка программасы) 73 муниципаль хезмәткәр катнашты.

Идарә составында кадрлар үзгәрү сәбәпле, муниципаль дәрәҗәдә махсус укыту программалары буенча укыту оештырылды:

306 авыл җирлеге башлыгы «Авыл җирлекләре белән идарә итүгә заманча якын килү» программасы буенча квалификация күтәрү узды, шулай ук «Татарстан Республикасы җирлекләрен үстерүнең актуаль мәсьәләләре: милли һәм дини аспектлар» семинарында катнашты;

авыл җирлекләре башкарма комитетларының 300 секретаре «Татарстан Республикасы авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләре урынбасарларының төп эшчәнлек юнәлешләре» программасы буенча квалификация күтәрү узды;

Җитәкче һәм урта звено 113 муниципаль хезмәткәр “Эчке һәм миграция сәясәтенең актуаль мәсьәләләре: сәяси, милли һәм дини аспектлар” программасы буенча квалификациясе күтәрде, шул исәптән Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру өлкәсендәге эш өчен җаваплы 47 башлык урынбасары, башкарма комитетлары җитәкчеләре урынбасарлары.

Моннан тыш, муниципаль районнарның башкарма комитетларының 11 җитәкчесе (урынбасарлары) һәм җирле үзидарә органнарының җитәкче звеносы вәкилләре «Татарстан командасы өчен идарә лидеры» дигән стажировка форматының махсус программасы буенча укулар узды.

2022 ел дәвамында республиканың муниципаль районнарында түбәндәге күчмә тренинг стратегик сессияләре үткәрелде:

Әлки, Лаеш, Балык Бистәсе, Биектау, Зеленодольск, Менделеевск, Югары Ослан, Апас районнарында «Минем Татарстан - минем команда»;

Баулы, Әгерҗе, Чирмешән һәм Мөслим районнарында «Клиент үзәгендә команда көче»;

«Бурычлар кую. Мотивация. Контроль һәм кире элемтә» һәм «Шәхси нәтиҗәлелек. Үзанализт һәм үзменеджмент” - Актаныш районында.

Муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль буйсынудагы учреждениеләрнең һөнәри үсеше процессында «PROслужба.Татарстан» мәгълүмати-белем бирү платформасы (мобиль кушымтасы) актив кулланыла, аның 13 000нән артык актив язылучысы бар.

Әлеге кушымта ярдәмендә курсларга теркәлү, катнашучыларның өлгерешенә мәгълүмат бирү һәм мониторинг ясау, тестлаштыру, сертификатлар бирү башкарыла. Мобиль кушымтада мәгълүмати һәм уку материаллары, китапханә, укуның шәхси траекториясен мониторинглау, цифрлы компетенцияләрне бәяләү өчен симулятор бар.